Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

№ 30 (1395) 5 август 2022 ел

Татарстанда язылу индексы – П2355.

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga madani_zhomga

2

Тормыш-көнкүрешебездәге бик күп бәлаләр, житешсезлекләр адәм баласының, бигрәк тә түрәләрнең чик-чама хисен онытып жибәрүе белән бәйле.

6

Буа районындагы Бәбки авылы тарихында да халкыбыз кичергән күпме авыр сынау-газапларны күрергә була.

12

Казан филармониясе солисты Рөстәм Насыйбуллин ватанпәрвәр рухтагы, Бөек Ватан сугышында җиңүгә багышланган җырларга өстенлек бирә.

Гел ипекәй тәме килә бүген Туган җирнең һавасыннан да!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- «Пенза өлкәсенең татар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасына Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы 1585 данә татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре тапшырды.
- «Татмедиа» бинасында фотограф Фәрит Гобәевнең «Искусство присутствия» дип аталган, ике йөздән артык аклы-каралы сурәтне туплаган фотоальбомы тәкъдим ителде.
- Барнаул шәһәренең Алтай тарихы, әдәбияты, сәнгате һәм мәдәнияте дәүләт музее утарында кинорежиссер Илдар Ягъфәров һәм аның «Исәнмесез?!» кинокартинасына багышланган истәлек билгесе куелды.
- Милләтпәрвәр шәхес, Татарстанда дин ирегә өчен күп көч куйган Әлмирә Әдиятуллина турында китап дөнья күрде.
- Пенза өлкәсенең Наровчат шәһәрендә «Россия татарлары: милли үзенчәлек һәм дин» форумы узды.
- Казанда татар телендә белем бирә торган 18 нче гимназиянең яңа уку корпусы ачылачак.
- Лаеш районының Урта Девятово авылында Чишмә көнен бәйрәм иттеләр.
- Татарстанның атказанган юристы, СССР һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, рәссам Фәнил Галиев соңгы елларда иҗат иткән йортта истәлек тактасы куелды.
- Алабугада «Созвездие-Йолдызлык» мәдәни үсеш үзәге тиздән кулланугa тапшырылачак.
- 83 яшендә Россиянең атказанган, Татарстанның халык рәссамы Валерий Скобеев вафат булды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Марат ӘХМӘТОВ, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары:

«Мин, гомумән, район җитәкчеләрен дә үгетләп, әйтеп торам: «Ничек инде син үзеңнең район тормышың белән район халкыңны мөмкин кадәр күбрәк таныштыру эше белән шөгыльләнмисең?» Хакимият бит ул үзенең идарә бинасында гына утыра торган урын түгел, ул халык белән бер организм булырга тиеш».

СЫНАМЫШЛАР

7 августта җылы һәм аяз булса, кыш салкын киләчәк, яңгыр яуса – җылы һәм карлы булачак ● 11 августта иртән кырау төшмәсә, 5 сентябрьдә дә төшмәячәк әле ● Августта каенда сары яфрак күп булса, көз иртә килә ● Коеп яуган яңгыр тиз туктый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 55 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 42 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 47 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **29 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **12 августта 15 сәгать 18 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

5 август – дирижер, педагог, профессор, педагогика фәннәре докторы Илгизәр Миргасыйм улы Миргалимовның тууына 80 ел (1942–2019).

8 август – Халыкара мәчеләр көне;

– Җинаять һәм канунсызлыктан җәфа чиккән нотариусларны искә алу көне.

9 август – Дөньяның җирле халыкларының халыкара көне.

11 август – җырчы, педагог, Татарстанның халык артисты Илсур Кариб улы Сафинга 60 яшь (1962);

– Халыкара логософия көне.

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Августның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 10, 11 август.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(5-12 август)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **27 июльдән 13 августка кадәр** ашказаны асты бизе, талак һәм ашказаны актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген мөхәррәм аеның 7 нче көне

ҖАН АВАЗЫ



Рүзәл ЮСУПОВ, академик

НӘФЕС һәм ЧАМА хисе

Имин, бәхетле яшәү өчен, ашау-эчү, кием-салым, йорт-җир кебек ихтыяҗларны канәгатьләндерү эшләре кебек үк әһәмиятле гамәл ул – туганнан алып үлгәнчегә кадәр башкарыла торган тәрбия кылу, үзеңне һәм башкаларны тәрбияләү. Тәрбия – киң мәгънәле төшенчә. Бу юлы сүзем – нәфесне тыю һәм чама белү хисенә ия булу сыйфатларын тәрбияләү.

Тормыштагы күптөрле бала-казаларның нигезендә адәм балаларының чама хисенә ия булмаулары һәм шушы төшенчәгә якын торган сыйфат – нәфесләрен тыя белмәүләре тора. Бу тискәре күренешләр, социаль төркемнәрнең һәм кайбер кешеләрнең холык-фигыльләрендә чагылыш табып, аларның сау-сәламәт, шатлыклы яшәвенә зур зыян китерергә мөмкин һәм китерә дә.

Бу фикеребезне тормыштагы кайбер хәлләр, вакыйгалар белән расларга тырышып карыйк.

Кайсыдыр ризыкны чикләп кенә кулланырга кирәклек һәм чамасыз күп ашауның сәламәтлек өчен зыянлы икәнлеге һәркемгә аңлашылырга тиеш кебек. Фикерле ата-аналар балаларын баллы-татлы ашамлыклар ашау белән мавыкмаска өйрәтергә тырышалар, һәм бу кагыйдәне сакларга күнеккән кешеләрнең сәламәтлеге тәртипсез ашарга гадәтләнгәннәрнекенә караганда ныграк була. Артык ачы һәм тозлы ризыклар кулланырга ярамаганлык турында врачлар да даими кисәтеп торалар. Алкогольле эчемлекләрне чамасыз күп эчү күренешенең күпмеңләгән кешеләрнең сәламәтлеген какшатуын, вакытыннан иртә гомерләрен алып китүен һәм чиксез күп санлы бәла-казаларга китерүен һәрвакыт күреп, ишетеп торабыз.

Үзеңне тота белү кагыйдәләреннән ашау-эчү культурасы иң әһәмиятлеләрдән санала, шунлыктан акыллы, тәрбияле ата-аналар, гадәттә, балаларына кечкенәдән үк ашау-эчүгә караган әдәп кагыйдәләрен өйрәтергә тырыша. Ләкин безнең җәмгыятьтә балаларына дөрес тәрбия бирә белмәгән, шул исәптән аларны туклану әдәбенә өйрәтә алмаган кешеләр күп. Бу тискәре күренешнең төп сәбәбе ата-аналарның үзләренең дә вакытында тиешле тәрбия алмаган булуындадыр. Аларның кайберләре бала тәрбияләү гыйлеменең һәркемгә билгеле булырга тиешле, иң кирәкле мәгълүматларыннан да хәбәрдар түгел. Мәсәлән, кайбер аналар балага аның нәни чагында берничә дә чикләү булырга тиеш түгел дигән фәлсәфәгә таянып эш итә. Нәтиҗәдә, бала, тәпи йөри башлап, шактый күп нәрсәләрне аңларлык яшькә җиткәнче, чамасыз, тәртипсез иректә була: үзенә ошаган һәртөрле ризыкны, авызына күпме сыйдыра ала, шуның кадәр тутыра, чәчә-түгә, пычрата, теләсә нәрсәне алып уйный, вата-җимерә, һәм мондый хәл кайбер гаиләдә бала шактый зурайганчы дәвам итә, еш кына аның бу чикләнмәгән иреге киләчәк тормышындагы юньсезлек галәмәтләренең нигезенә салына.

Үзеңне җәмгыятьтә тота белү, теләгән нәрсәләрне, гамәлләреңне, шәхси мәнфәгатьләреңне, омтылышларыңны үз мохитеңдәге башка кешеләргә дә, ахыргы исәптә үзеңә дә зыян китерерлек очракларда чикли белү, икенче төрле әйткәндә, нәфесеңне тыя алу ихтыяҗы тәрбияле кешенең хисапсыз күптөрле гамәлләрендә чагылыш таба, һәм бу гаять мөһим сыйфат аңа гомере буе кирәк була. Әмма кешеләрнең күбесе әле бу сыйфатка, мондый сәләткә ия була алмый, һәм шуның аркасында җәмгыять тормышында тәртипсезлек, гаделсезлек күренешләре зур урын алып тора.

Дөнья тарихын күз алдыбыздан үткәрсәк, шул нәрсә ачык мәгълүм булыр: хаким сыйныф шәхесләренең үзләренә буйсынудагы кешеләрне җәберләве, кимсетүе, ирекләрен чикләве, аларның ихтыяҗлары, теләкләре белән исәпләшмәве ул хаким шәхесләрнең үз мәнфәгатьләренә, омтылышларына чик куя белмичә, эш итүләре аркасында килеп чыккан. Империалистик дәүләтләрнең барлыкка килүе тарихы да кайбер дәүләтләрнең башка бер дәүләтнең яки дәүләтләрнең үзләре теләгәнчә, ирекле яшәргә теләүләре белән исәпләшмичә, үз нәфесләренә чиксез ирек куеп, ул дәүләтләрне көч кулланып басып алу тарихы икәнлекне күрсәтә. Нәфесләрен тыя алмыйча, башка илләрнең җирләрен басып алырга омтылуы күренеше, ни гаҗәп, цивилизацияле булып саналган XXI гасырда да чагылыш таба.

Нәфесне чикли белмәгәндәге кебек, җәмгыять тормышында ниндидер җитди, глобаль яңалыклар, үзгәрешләр керткәндә, чама хисен югалтып эш итүләр аркасында оешма-коллективларга, бөтен дәүләткә зур зарар килү хәлләре булып тора. 1917 елгы Бөек Октябрь социалистик революциясен карыйк. Гомумән алганда, ул революция хезмәт халкының тормышын яхшырту өчен башкарылган зур үзгәреш булган. Шуңа күрә исеме дә – социалистик революция. Ләкин аны оештыручылар, кайбер мәсьәләләрдә чама хисен югалтып, мавыгып китеп, җитди ялгышлар да җибәргән. Мәсәлән, хосусый милекне бетерәбез, авылдагы барлык шәхси хуҗалыкларны күмәкләштерәбез дип, хезмәтчән, иң тырыш хәлле крестьянны (кулаклар дип атап) сафтан чыгарганнар: йортсыз-җирсез, мал-туарсыз калдырып, Себергә сөргәннәр. Үз көче белән халыкка кирәкле төрле продукция җитештерүче эшмәкәрләргә карата да шундыйрак сәясәт үткәрелгән.

Илебездә узган гасырның 90 нчы елларыннан башланган үзгәртеп корулар чорында да, хакимият әһелләренең, чама хисен югалтып, мавыгып, төптән уйламыйча эш итүләре аркасында, зур ялгышлар булды, гаделсезлек кылынды. Шуларның аеруча гыйбрәтлеләрен, халыкның иминлегенә, илнең алга китүенә зур зыян китергән берничәсен искәртеп китәбез.

Дәүләт милкен, сәнәгать предприятиеләрен, колхоз-совхоз хуҗалыкларын приватизацияләү дип аталган хосусыйлаштыру процессын, аның системасын, механизмын һәм технологиясен ныклап уйлап, чама белән гамәлгә ашыру булмады. Нәтиҗәдә, халык байлыгының күбесе хәйләле, астыртын, мәкерле алымнар, методлар белән эш иткән кешеләр кулына эләкте, биш-ун елда зур миллионерлар һәм миллиардерлар барлыкка килде. Авыл хуҗалыгында да, чын-чынлап алдынгы фермер хуҗалыкларын оештырып, аларга нәтиҗәле эшләргә юл куелмады: төрлечә алдау, хәйлә юллары белән крестьяннарның пай җирләрен инвесторлар дип аталган бәндәләр үз кулларына төшерделәр, ә хәзер аңнарына килгән, үз җирләрендә үзләре эшләргә теләгән крестьяннар пай җирләрен кире кайтарып ала алмыйча тилмерә.

Ни уйлап, 90 нчы еллар башыннан бөтен илдә күп меңнәрчә промышленность предприятиеләре юк ителде икән? Безнең Казан шәһәрендә генә дә халык өчен кирәкле товарлар җитештерә торган берничә дистә гөрләп эшләп торган зур завод-фабрикалар юкка чыгарылды. Россия халкы кием-салымны, самолет, автомобильләрне, барлык аудио-видео техникасын, хәтта солы ярмасы, кадак кебек җиңел җитештерелә торган меңнәрчә төрле әйберләрне чит илләрдән алып яшәде. Бу акыллы гамәл булган дип кем әйтә алыр? Хәзер Россиягә каршы глобаль икътисади санкцияләр игълан ителгәч, халыкка ни эшләргә кала? Бөтен кирәкле товарларны кирәгенчә һәм югары сыйфатлы итеп үзебезнең промышленность җитештерә башлаганчы, ничә ел узар икән?

Хезмәт өчен түләү, салым салу, пенсия билгеләү системаларында һәм башка кайбер өлкәләрдә чамасыз үзгәрешләр кертү, төптән уйланылмаган чаралар күрү аркасында, халыкның тормышы авырая бара, социаль гаделсезлек арта. Сәламәтлек саклау, мәгариф өлкәләрендә дә соңгы берничә дистә елда, чама хисен югалтып үзгәрешләр кертү аркасында, зур проблемалар килеп чыкты һәм чыга тора.

Ил буенча уртача хезмәт хакы аена 25 мең сум (15-20 мең сум алып эшләүчеләр дә күп, авыл почтальоннары 6 мең сум алып эшли), уртача пенсия 14 мең сум булганда, кайбер җитәкчеләр ничек итеп миллионнарча сум алырга җөрьәт итә икән?! Аларда нинди чама хисе һәм нәфес чиге булсын? Патша Россиясендә эшмәкәрлек юлы белән капитал туплаган татар кешеләре, мәдрәсәләр ачып, анда укыту чыгымнарын үз өсләренә алганнар. Безнең хәзерге күп миллионлы татар байларының, миллиардерларының берсе дә ни өчен, бик кирәкле абруйлы татар мәктәпләре салдырып, балаларны үз телләрендә укыту ихтыяҗын канәгатьләндерү турында уйламыйлар икән?

90нчы еллардан башлап күп авыл-поселокларда халык өчен гаять кирәкле фельдшерлык-акушерлык пунктлары бетерелде. Хакимият җитәкчеләре мондый җимерү эшенә ничек ризалык бирде икән? Бу мәсьәләдә дә аларның чама хисе бер дә чагылыш тапмаган, күрәсең.

Ныклап уйламыйча, чама хисен югалтып кылган гамәлләр, шулар аркасында барлыкка килгән зур кыенлыклар һәм гаделсезлекләр хәвефле нәтиҗәләргә китерә. Җитешле, имин, бәхетле яшәүгә ирешү балаларны, яшь буынны һәм хәтта күпмедер дәрәҗәдә урта һәм өлкән буын кешеләрен дә дөрес тәрбияләүгә, шул исәптән җәмгыять әгъзаларында нәфесне тыя алу, чама хисенә ия булу сыйфатларын булдыру һәм ныгыту нигезләнгән. Бу әһәмиятле, гаять игелекле эш дәүләт органнарының, уку йортларының, матбугат, радиотелевидениенең һәм мәдәният учреждениеләренең даими игътибар үзәгендә торырга, иң мөһим бурычларының берсе булырга тиеш.

Җидеген
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

КОРЫ КАЛГАН КОРЫЛТАЙ

30 июль-2 август көннәрендә Казан каласында Бөтендөнья татар конгрессының (БТК) VIII корылтае эшләде. Делегатлар анда, Россия төбәкләреннән генә түгел, татарлар яшәгән 35 чит илдән (Алмания, Франция, Балтыйк буе дәүләтләре, Урта Азия илләре, Әфганстан һ.б.) дә килгән. АКШ, Канада кебек илләрдәге татарлардан вәкилләр ул чарада онлайн-режимда катнашкан. Җыен БТКның – 30, ә «Милли шура»ның 5 еллыгына туры китереп үткәрелгән. Бу уңайдан, корылтай делегатларына котлауларын РФ президенты В.Путин, тышкы эшләр министры С.Лавров һ.б. юллаган. Аларда БТК эшчәнлегенә югары бәя бирелгән. Юбилей адыннан, гадәттәгечә, башкарылган эшләргә йомгак та ясалган. Ә алар бу чорда шактый булган. «Милли шура» рәисе В.Шәйхразиев сүзләренә караганда, бу 30 ел эчендә бөтен дөнья буйлап сибелеп яшәгән татарларны барлау һәм берләштерү, шулай ук оешманың абруен һәм дәрәҗәсен күтәрү буенча да зур эшләр башкарылган. Җитешсезлекләргә килгәндә, ул алар рәтендә татар телен өйрәнү буенча классларның Россия төбәкләренең барысында да ачылмавын, милли университет булдырылмавын һәм, милли рухны күтәрү өчен, һәр татар гаиләсенә таратырдай идеологик документ кабул ителмәвен атаган. Милли эшләрдә финанс кыенлыкларының зур булуын да искәрткән.

Алай да, техник һәм матди уңайлыклары ягыннан VIII корылтай шактый ук югары дәрәҗәдә оештырылган. Әчтәлеге буенча да милләт өчен мөһим мәсьәләләр күтәрелгән. Һәрхәлдә, моның хаклыгы уртак утырышка кадәр оештырылган бәхәс мәйданчыкларына чыгарылган темаларда гына түгел, төп программага кертелгән башка чараларда да күренә. Татарстан Президенты Р.Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе М.Шәймиев катнашында үткән пленар утырышта да житди фикерләр булган һәм берише йомгаклау резолюциясенә дә кертелгән. Җыенда исә «Милли шура» да яңартылган һәм яңа составның тәүге утырышы үткәрелгән. Әмма төп сорау күпләр өчен анда үзгәрешсез кала: делегатлар бу җыеннан, чор янауларына җавап бирердәй алдынгы идея вә карарлар белән коралланып һәм аларны урыннарда гамәлгә ашыруга да рухланып таралыша алганмы соң? Бу сорауга җавап табу өчен, милләт алдында торган янауларга инде башка яктан да якын килик.

Мәгълүм булганча, БТК һәм аның Башкарма комитеты 1992 елның июнендә (татар милли хәрәкәтенең көчле чорында) Татарстан Президенты карары белән җыелган корылтайда оешты. Аның максатлары итеп татар халкын берләштерү, аның милли-мәдәни, социаль-икътисади һәм рухи үсешенә ярдәм күрсәтү, мәдәниятне, телне, традицияләрне торгызу һәм саклау игълан ителде. БТК эшчәнлеге шул юнәлешләрдә барды да. Тик хакимиятнең аңа карата кәгазьдә күрсәтелмәгән үз исәбе булуы да хак: милли хәрәкәтне үз контроленә алу һәм сәясәттән читләштерү. Ул моңа да ирешге - БТК сәясәткә кермәде һәм билгеле бер кысалардан чыкмады, хәтта татар халкы һәр елны үткәрә торган Хәтер көнендә дә катнашырга базмады. Бүген инде башка милли оешмалар төрле юллар белән таркатылды, ә БТК судан коры чыкты. Бу җәһәттән, аның чираттагы корылтае да коры булып калды. Чөнки, шул ук сәбәпләр аркасында, анда яңа идея һәм карарлар кабул ителә алмады.

Ә соңгы 30 елда урын алган сәяси вә хокукый чигенүләр, Татарстанда 1992 елның 21 мартында үткәрелгән референдум нәтиҗәләрен генә түгел, бүген инде татар халкының дәүләтчелеген һәм, гомумән, аның язмышын да кыл өстенә куя. Аңлашыла булыр, милләт мондый янауларга битараф кала алмый. Хәлбуки, БТКның бүгенге статусы һәм абруе аңа авторитар режим шартларында да үз мәйданчыгында эш итү мөмкинлеге калдыра. Бер яктан - бу хәл, ә икенче яктан – алда торган янау вә кискен үзгәрешләр, киң мәгънәдәге татар милли хәрәкәтеннән инде, яшәү рәвешендә дә вәзгыятькә тәңгәл ниндидер гадәттән тыш (экстраординар) чишелеш табып, нәтиҗәле чаралар күрелүен, ул гына түгел, аның яңа чор сынауларына җавап бирерлек эчтәлек вә динамизм да алуын таләп итә. Аллага шөкер, андый мөмкинлекләр бар һәм узган язмаларда ул хакта өлешчә телгә дә алынган иде. Язмаларның киләселәрендә, иншалла, аларга инде тәфсилләбрәк тә тукталырбыз.

Фоат УРАЗАЙ.

Авыллар тарихына ник игътибар зур?

Уфаның «Торатау» конгресс-холлында «Башкортстан тарихында авыл тарихы» дип аталган туган якны өйрәнү мәгълүмати-агарту акциясе тәкъдим ителде. Проект 2021 елның августыннан Башкортстан Республикасы Башлыгы гранты ярдәмендә тормышка ашырыла.

Проект кысаларында авыллар тарихына багышланган «Башкортстанның торак пунктлары» мәгълүмат ресурсы булдырылды, шул ук исемдәге энциклопедия чыкты. Анда торак пунктларның тарихы системага салынган, төгәллекләр кертелгән һәм бастырып чыгарылган. Башкортстанның юкка чыккан торак пунктлары турында мәгълүматлар тупланган.

«Торак пунктларның барлыкка килүе һәм тарихы – игътибарлы мөнәсәбәт таләп итә торган актуаль темаларның берсе, чөнки аның белән халыкның территориаль һәм этник тәңгәллеге бәйле. Башкортстан авыллары тарихын өйрәнүгә тарих фәннәре кандидаты Әнвәр Әсфәндияров күп көч салган һәм бу проект аның истәлегенә багышланган», – дип хәбәр итә Вәлиди исемендәге Милли китапханә вәкиле.

1939 елгы халык санын алу буенча БАССР территориясендә 8887 торак пункт (авыллар, бистәләр, бараклар, утар-кечкенә авыллар), 22 эшче бистә һәм 6 шәһәр исәпкә алынган.

Ә. Әсфәндияров хезмәтләренең нинди рухта икәне яхшы билгеле, димәк, әлеге проект та күптән алып барылган башкортлаштыру сәясәтен дәвам итә.

Татар бистәсенә башкала ярдәме

Ростуризмда беренче тапкыр ил шәһәрләре үзәкләрен төзекләндерү буенча проектлар конкурсы узды. Барлыгы 31 проектка 6 млрд сумлык ярдәм күрсәтеләчәк. Җиңүчеләр арасында Казан һәм Алабуга бар иде.

Татарстан Туризм буенча дәүләт комитетында аңлатуларынча, Казанда Иске Татар бистәсе территориясе төзекләндереләчәк. Аерым алганда, яңа эскәмия, урналар урнаштырырга, туристлык навигациясен яңартырга, шулай ук яңа фотозона, территорияне мультимедиа белән тулыландырырга, мәдәни мирас объектларын яктыртырга җыеналар.

Татарстан башкаласы проекты, иң күп балл җыеп, беренче урынны ала. Грантның төгәл суммасы соңрак игълан ителәчәк, әмма гариза республика бюджеты белән уртак финанслауны исәпкә алып бирелгән.

Моннан тыш, Зәйни Солтан скверында урам амфитеатры пәйда булачак, ә Каюм Насыйри урамында җәяүлеләр зонасы өчен яктырту баганалары һәм коймасы алыштырылачак.

Канунсыз такта

Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхинең вафатына 5 ел тулды. Шул көнгә туры китереп, Казанда Хәния Фәрхи яшәгән йортка истәлек тактасы куелды.

Җырчының исемен мәңгеләштерү Имәнлек урамындагы 57 йортта яшәүчеләр идеясе була. Финанс мәсьәләләрен тулысынча шушы йортта яшәүчеләр, Хәния апаның тормыш иптәше Габделхәй Биктаһиров һәм «Бәйрәм ансамбле» егетләре хәл итә. Истәлек тактасына татар һәм рус телләрендә: «Бу йортта 2005 елдан алып 2017 елга кадәр Татар һәм башкорт эстрадасы примадоннасы яшәде», – дип язылган. Ләкин бу йортка мемориаль такта куйдыру өчен тиешле органнардан рөхсәт алынмаган булып чыкты.

Андый истәлек такталары Татарстан Министрлар Кабинеты карары чыкканнан соң гына куела ала. Ә аңарчы махсус комиссия тарафыннан тикшерү уздырылырга тиеш.

Арчада рухи мәгърифәт үзәге

Арчада Габдулла Тукай исемендәге рухи мәгърифәт үзәге ачылды. Чара Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышланган театраль күренештән башланып китте.

Ачылышта Арча муниципаль район башлыгы Илшат Нуриев, Татарстан Республикасы мөфтиенең мөхтәсибәтләр белән эшләү буенча урынбасары Равил хәзрәт Зөфәров, Татарстан баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Дәүләт-конфессиональ мөнәсәбәтләр бүлегенең баш киңәшчесе Альберт Дирзизов, Татарстан Аксакаллар шурасы рәисе Айрат хәзрәт Әюпов катнашты.

Арча мөхтәсибәте Татарстанда иң зур мөхтәсибәт булып тора, аның карамагында 93 мәчет эшли, шуларның 88е Арча районы авылларында урнашкан. Бүгенге көндә мөхтәсибәттә 83 имам һәм 150 укытучы ислам нигезләрен укыта.

«Рухи-мәгърифәт үзәге ачыла торган нигездә элек мәдрәсә булуы билгеле. Ул Илгизәр хәзрәт, Сания абыстай һәм район мөселманнары тырышлыгы белән төзелгән булган. Әмма вакыт үтү белән бина искергән. Район җитәкчелеге, төзүчеләр ширкәте ярдәмендә 2021 елның 21 июнендә яңа мәгърифәт үзәгенә нигез салынды һәм бер ел дигәндә ул сафка басты. Биредә уку сыйныфлары, конференц-зал, ашханә, китапханә, ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен тәһарәтханәләр урын алган. Бүлмәләр кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителгән, барысы да заманча. Үзәк районыбыз халкына гыйлем таратуда озак еллар хезмәт итсен иде», – диде Арча районы имам-мөхтәсибе Әмир хәзрәт Миңнемуллин.

Хәзер дә язылып була!

Хөрмәтле милләттәшләр! «Мәдәни җомга» газетасына һәр айда язылырга мөмкин. 20 августка кадәр язылсагыз, сентябрь аеннан газета өегезгә килә башлаячак. Язылу кампаниясе вакытында өлгермәгән таныш-белешләрегезгә дә бу хакта хәбәр итсәгез иде.

«Мәдәни җомга»га 4 айга язылу бәясе – 435 сум 84 тиен. Язылу индексы – П2355.

1 нче биттә – Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның урып-җыю эшләре барышы белән танышу, федераль һәм республика программаларын гамәлгә ашыру максатыннан Аксубай районына эш сәфәреннән бер күренеш. Фото: president.tatarstan.ru

Мәдәни җомга
5 август
№30, 2022

Шагыйрьгә – шигырьле кабер ташы

Татарстанның халык шагыйре Роберт Миңнуллин каберенә таш кую мәрасименә иң якын кешеләре генә җыелган иде.

«Әтинең ташы үзе кебек гади һәм эчтәлекле булырга тиеш иде. Ул биредәге башка ташлардан зурлыгы белән аерылып тормый, чөнки әти халыктан аерылып тормады», – диде шагыйрьнең кызы Таңсылу Сабирова.

Ул таш кую эшендә ярдәм иткән хөкүмәткә, Мәдәният министрлыгына, ташны ясаучыларга рәхмәтләрен җиткерде.

Таш кую мәрасименә Татарстан мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Дәүләт Советы депутаты Римма Ратникова, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла килгән, туганнары, дуслары, каләмдәшләре җыелган иде.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.
Абдул ФАРХАН фотосы.

Габдулла Тукай һәм театр экскурсиясе

Казан халкына Галиәсгар Камал театры белән берлектә әзерләнгән «Габдулла Тукай һәм татар театры тарихы» экскурсия проекты тәкъдим ителде. Экскурсияне Габдулла Тукай әдәби музее мөдире Гүзәл Төхвәтова алып барды.

Маршрут кысаларында кунакларга төрле тарихи урыннарда Габдулла Тукай һәм аның чордашлары иҗаты, беренче татар артистларының тормышы яктыртылды. «Бу проектны тамашачыларга инде күрсәтеп карадык, һәр кеше экскурсияне ошатты, канәгать калды. Экскурсия атна саен чәршәмбе көнне 15.00 сәгатьтә татар һәм рус телләрендә уздырыла», – диде Гүзәл Төхвәтова.

Экскурсия Г.Тукай исемендәге әдәби музейдан башланды. «Беренче татар театрын оештыручылардан Габдулла Кариев теләге белән биредә 1917 елда беренче стационар татар театры ачыла. Беренче татар театры тарихы дигәндә, ул 1906 елның 22 декабрендә оешкан дип кенә әйтеп булмый. Тәүге спектакльләр Тукай музее каршындагы 1876 елда ачылган Укытучылар мәктәбе бинасында уйналган, дигән истәлекләр бар. Спектакльләрне татар мәктәбендә укучылар әзерләгән. Беренче спектакльләрдә монда укыган сәнгать эшлеклесе Ильяс Кудашев-Ашказарский да катнашкан дип әйтә алабыз», - диде экскурсовод.

Витринада Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның шәлен, Габдулла Кариевнең кара савытын, Галиәсгар Камалның «Беренче театр» әсәренең кулъязмасын күрергә мөмкин. «XX гасыр башы – татар мәдәниятенең ренессанс кичергән чоры. Беренче артистлар «Шимбәчеләр» түгәрәген оештыра», – диде Гүзәл Төхвәтова.

Экскурсия Юнысовлар мәйданында – Иске татар бистәсендә дәвам итте. «Юнысовлар мәйданы XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында төп иҗтимагый рольне үтәгән. Аның «Мәхәббәт», «Сагыш», «Биюләр» һәм «Мәйдан» дигән бакчалары булган. «Мәйдан» бакчасында революционер Мулланур Вахитовка һәйкәл торган. Г.Төхвәтова аның беренче татар спектакльләрендә уйнап, үзен артист буларак та сынап караганлыгын искә алды.

Габдулла Тукайның Казан зоопаркы каршында бүлмәләр арендалаганы турында да әйтелде. «Ул җәйге дача булган. «Әл-Ислах» газетасы редакциясе белән күчеп, 1908-1909 елларда җәен шунда эшләгәннәр. Дачага теплоходка утырып, Кабан күле буйлап йөзеп барганнар. Спектакльләрне бакчаларда да уйнаганнар. Тукай Апанаев бакчасына (бүгенге көндә «Динамо» спорт комплексы) спектакльләр карарга йөргән», – диде музей мөдире.

Меңьеллык бакчасында Г.Тукай бер йортны арендалап торган. Шул бинада яшәгәндә, Тукайның бөтен әйберләрен урлап китәләр.

«1910 елның 15 апрелендә «Татар утарының» бер йортында (Сабитовлар йорты) Тукай «Халык әдәбияты» дигән лекциясен укый. Әлеге лекциядә ул халык җырлары, иҗаты хакында әйтә. Аның тарихы бик кызыклы. «Әл-Ислах» газетасында Тукайның лекция укыячагы турында игълан языла. Газетада чыкканнан соң, моны Тукай белеп ала һәм лекцияне укырга мәҗбүр була», – дип сөйләде ул.

Алга таба экскурсия «Болгар номерлары» бинасы янында, элек татар зыялылары җыелган һәм «Сәйяр» труппасының спектакльләре куелган бина – «Шәрык клубы» интерактив мультимедиа комплексында барды. Монда заманча технологияләр ярдәмендә татар театры дөньясы белән танышу мөмкинлеге каралган. Экскурсия Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасының түбәсендә тәмамланды.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Шаляпин юбилеена игътибар

2023 елның февралендә Татарстанда опера җырчысы Федор Шаляпинның тууына 150 ел тулуга багышланган тантаналар узачак. Шул уңайдан республика Президенты Рөстәм Миңнеханов махсус карар чыгарды. «Бөек опера җырчысы Шаляпинның дөнья һәм ил мәдәниятенә керткән зур өлешен, шулай ук 2023 елда аның тууына 150 ел тулуны исәпкә алып, 2023 елның февралендә тантаналы чаралар үткәрергә карар бирәм», – диелә документта.

Моннан тыш, Татарстан Президенты тантаналарга әзерлек һәм үткәрү белән шөгыльләнәчәк оештыру комитеты булдырырга кушты. Аны Татарстан Президенты Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров җитәкли. Вице-премьер Ләйлә Фазлыева аның урынбасары, мәдәният министры Ирада Әюпова комитет секретаре булачак.

Составка шулай ук мәдәни берләшмәләр, уку оешмалары, театрлар, министрлыклар һәм ведомстволар, шулай ук телевидение һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, шул исәптән «Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев керде.

Өч ай дәвамында Татарстан Хөкүмәте бәйрәм итү программасына кергән чаралар планын эшләргә тиеш. Бәйрәм чараларына әзерлек һәм үткәрү белән республика районнары да шөгыльләнәчәк – аларның башлыкларына киләкле барлык чараларны да тәэмин итәргә һәм планны тормышка ашыруда актив катнашырга йөкләмә бирелде.

Моннан тыш, Р. Миңнеханов Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, шулай ук район мәгълүмат чараларына Ф. Шаляпинның тууына 150 ел тулуны бәйрәм итүне киңкырлы яктыртуны тәэмин итәргә кушты.

Мөселман яшьләре тәкъдим итә

Болгарда Ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы кысаларында мөселман яшьләренең Бөтенроссия форумы узды. Анда катнашучылар Россия өммәте ихтыяҗларын исәпкә алып эшләгән социаль проектларын тәкъдим итте.

1100 еллыкка багышланган форумда Россиянең төрле почмакларыннан 200 гә якын 18-30 яшьлек мөселманнар һәм мөслимәләр катнашты. Алар Татарстаннан, Мәскәү һәм Мәскәү өлкәсеннән, Оренбург, Екатеринбург, Тубыл һәм Чабаксардан, Кемерово, Пенза, Чиләбе өлкәләреннән, Самара, Новосибирск, Волгоград, Ижевск, Пермь, Уфа, Чиләбе, Первоуральск һәм илебезнең башка шәһәрләрдән, шулай ук Казахстан һәм Мисыр кебек чит илләрдән килде. Мөселманнарның бер атнага исәпләнгән күчмә җыены палаткалы шәһәрчектә үтте. Җыенны оештыручылар – Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифенә ярдәм күрсәтү фонды белән бергәлектә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте.

Җыен программасы 3 төрле чарадан – тарихи, дини һәм проектлау өлешләреннән тора. Барлык лекцияләр, практикумнар, осталык дәресләре, квестлар, экскурсияләр Россиядә ислам тарихы турындагы белемнәрне киңәйтүгә һәм тирәнәйтүгә, яшьләрнең шәхси, иҗади, рухи-әхлакый үсеше өчен кирәкле шартлар тудыруга юнәлтелгән иде.

Яшьләр белән очрашырга һәм аларның проектлары белән якыннан танышып, аларны тормышка ашыру мөмкинлекләренә үз фикерләрен белдерергә эшмәкәрләр, заманча технологияләр, социаль эшчәнлек, мөселман мәгарифе өлкәсендә танылган белгечләр килде.

Атна дәвамында белгечләр карамагына 100 гә якын социаль проект тәкъдим ителде. Алар арасында: интернет, кино, мәгърифәтчелек, инфраструктура, экология, спорт, хәйриячелек белән бәйле булганнары, шулай ук хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр, шәхси үсеш өчен атап эшләнгәннәре бар. Шулардан 3 иң яхшы идея сайлап алынды һәм акчалата премиягә – проектны гамәлгә ашыру өчен башлангыч капиталга лаек булды.

Киләчәктә финанслау һәм гамәлгә ашыру өчен идеяләрне сайлап алу тәҗрибәсе мөселман яшьләре форумы мәйданчыгында беренче тапкыр кулланылуга карамастан, форумда катнашучылар тарафыннан 7 ел дәверендә тәкъдим ителгән беренче проект Нәзарәт һәм мөхтәсибәтләр тарафыннан уңышлы тормышка ашырыла. Мисал өчен, ислам нигезләрен һәм намаз укырга өйрәнүне максат иткән «Ислам. Беренче адымнар» проекты, макулатура тапшырудан кергән акчаларны авыру балаларның дәвалануы өчен тапшыруны күздә тоткан «Ак кәгазьгә – яңа тормыш» дип исемләнгән хәйрия акциясен, Дискуссия клубын һ.б. атап үтәргә мөмкин.

● Япон Геннай Янагисава дөньяда иң кечкенә боралак ясаган: «GEN H-4» бер кешегә исәпләнгән, авырлыгы 70 кг, үзеннән өч тапкыр авыррак – 210 кг йөкне һавага күтәрә ала, сәгатенә 100 км тизлек белән очарга сәләтле. Аппарат конструктор кебек сүтелгән хәлдә сатыла һәм бер сумкага сыеп бетә, аны махсус белеме булмаган кеше дә җыя ала.

● Россия быел көз соңгы 46 елда беренче тапкыр Айга очарга – «Луна-25» аппаратын җибәрергә җыена. Очышның максаты – Җирнең табигый иярчененең көньяк полюсын өйрәнү. АКШтагы NASA оешмасы да ел азагында Айга космик аппарат җибәрергә ниятли. Россиядә галәмне сафтан чыккан аппаратлар, ракета фрагментлары кебек чүп-чардан арындыру өчен махсус иярчен дә ясала башлаган.

Атнаның сәяси мизгелләре

Хокукый икейөзлелек галәмәте

КХР рәисе Си Цзиньпин һәм АКШ президенты Джо Байден 28 июльдә телефон аша Украинадагы кризис һәм Тайвань белән бәйле хәлләр турында сөйләшкән. Әңгәмә ике сәгатьтән артык дәвам иткән. Кайбер экспертлар аңа этәргән сәбәпләрнең берсе дип Россиягә каршы кертелгән санкция шартларында Кытайның аңа ярдәм итүе турындагы имеш-мимешләрне атый. Бардыр. Әмма Кытай лидеры Украина мәсьәләсендә Пекинның принципиаль карашы үзгәрешсез калуы, мәсьәләне ул бары тик сөйләшүләр юлы белән чишү яклы булуы турында әйткән. Шул ук вакытта, Тайвань мәсьәләсендә Си: «Ут белән шаярганнар анда үзләре үк яначак», – дип тә кисәткән. Әмма соңгы көннәрдә зур киеренкелекне АКШ Конгрессы вәкилләр палатасы спикеры Нэнси Пелосиның Азия илләренә сәфәре барышында Тайваньга да тукталуы китереп чыгарды. Ярый ла әле эшләр бик зурга китмәде.

Шанхай хезмәттәшлеге оешмасы (ШОС) илләре тышкы эшләр министрларының Ташкентта үткән саммиты кысаларында узган Кытай-Россия сөйләшүләре дә кызыклы. Анда үзәктә шул ук Украина мәсьәләсе, шулай ук Үзәк Азиядәге берләшү процессы һәм Әфганстандагы хәлләр торган.

Башка вакыйгаларга килгәндә, игътибарны ДНР башлыгы Д.Пушилинның «пришло время освобождать русские города на Украине» дигән чакыруы да җәлеп итә. Кремльдә ул әйткәннәрне уңай бәяләгәннәр. Ә Федерация Советыннан А.Клишас бу җәһәттән, көзге сессиядә яңа территорияләрне Россиягә интеграцияләү парламентның мөһим бурычына әйләнергә дә мөмкин, дип өстәгән. АКШ Сенаты исә Дәүләт департаментын Россияне «террорчылыкка химая итүче дәүләт» дип танырга өндәгән резолюция кабул иткән. Ә Латвия бу атнада инде Сеймда хәтта Россияне, террорчыл дәүләт, дип танырга чакырган тәкъдимне дә караган. Россия исә Хәрби-диңгез флотының яңа Кораб уставын һәм Диңгез доктринасын кабул иткән һәм, «Адмирал Горшков» фрегатыннан башлап, флотны гипертавыш тизлекле «Циркон» ракета комплексы белән коралландырырга җыена.

Фоат УРАЗАЙ.

Татарларны башкортлаштыру тукталмый

Тарихчы Илнар Гарифуллин белән әңгәмә

– Илнар әфәнде, җанисәп алдыннан Башкортстанда татарларны башкортлаштыру процессы көчле барды. Хәзер вәзгыять үзгәрдеме?

– Көчләп башкортлаштыру проблемасының халык санын алу кампаниясеннән соң да бетмәячәге турында элек тә матбугатта кат-кат әйтә килдем. Чагыштырып кына карагыз. Башкорт корылтае башкорт халкының үсеш стратегиясен дәүләт программасы буларак кабул итте. Ә татар халкының стратегиясе эссе форматында гына язылган, шуңа күрә башкортларныкы безнекенә караганда ике башка өстенрәк. Хәзер алар стратегия нигезендә алга бара. Анда татарларны башкортлаштыру сәясәте, татар телен башкорт теленең төньяк-көнбатыш диалекты дип тану һәм аны үстерү кертелгән. Алар төньяк-көнбатыш диалекты буенча дәреслекләр әзерләп, Россия Фәннәр академиясенең Телләрне өйрәнү институтына экспертизага җибәргән. Киләчәктә Башкортстан бу телне рәсми рәвештә теркәп, мәктәпләргә кертергә җыена. Бу эш тормышка ашырылса, без Башкортстан мәктәпләрендә татар телен тулаем югалтачакбыз. Әлегә авыл мәктәпләрендә татар теле укытыла.

Бүгенге көндә Бөтендөнья татар яшьләре форумы Башкортстан мәктәпләре буенча вәзгыятьне яхшы белүче бер аспирант белән хезмәттәшлек итә. Аның мәгълүматы буенча, татар районнары үзәкләрендәге мәктәпләрдә башкорт теле укытыла, ә татар теленә урын калмаган диярлек. Татар теле әлегә кечкенә авылларда гына саклана. Диалектны рәсмиләштерү процессы шулай барса, татар теле авылларда да бетәчәк. Аның урынына башкорт теленең диалектын кертәчәкләр.

Татарларны башкортлаштыру сәясәте тел белән генә чикләнми. Узган елның декабрендә татар активистларына басым көчле булды. Мәсәлән, Илдар Габдрафиковны эшеннән куарга маташтылар. Башкортлаштыру процессы хәзер дә бара, тик ни гаҗәп: массакүләм мәгълүмат чаралары бу турыда язмый, берни чаң да сукмый.

Чын башкорт районнарына, башкорт оешмаларына дәүләт акчалата бик күп ярдәм итә, ә татар районнарына берни игътибар юк. Чиста башкорт төбәкләрендә кечкенә авылларга да асфальт салынган. Бөрҗән, Әбҗәлил, Баймак кебек башкорт районнарына игътибар итеп карагыз. Татар районнарында асфальт зур авылларның үзәк урамнарына гына кергән, ә кечерәк авылларга бөтенләй салмыйлар. Әнә, күптән түгел В.Имамов шәхсән үзе барып, шаһит булып кайтты: Мәчетле районының Олы һәм Урта Ака авылларындагы 20-30 урамның 18-28 ендә асфальт бөтенләй юк.

Күптән түгел Башкортстан башлыгы иҗтимагый оешмаларга грант таратты. Салават Хәмидуллинның татарларны башкортлаштыру сәясәтен алып баручы «Шәҗәрә» үзәгенә өч миллион сум биргәннәр. Икенче мисал: республика башлыгы дәүләт телләре һәм Башкортстан халыклары телләрен саклау һәм үстерү өчен 2022 елда 48 млн сум грант бирде. Татар теленә грант фондының 1 млн сумы гына, ягъни ике проценты тиде. Татарлар Башкортстанда сан буенча 30 процентны тәшкил итә. Алдагы елларда да шундый ук хәл иде. Шул ук вакытта бу грантлардан берничә миллион сум Урал төбәкләрендә татарны башкортлаштыру проектларына да бирелде.

Башкортстанда 2011 елдан бирле «Аек авыл» дигән бәйге үткәрелә. Җиңүчеләр авылның үсеше өчен 3-4 млн сум акча ала. Аңа юлны төзекләндерергә, парк ясарга һәм башка файдалы эшләр эшләргә мөмкин. Башка елларда ул грант хисабына оештырыла иде, ә быел Радий Хәбиров аңа аерым акча бирде. Бу бәйгене гел күзәтеп барам. Ел саен анда башкорт авылларын гына җиңдерәләр. Татар авылларына бик сирәк кенә өченче урын эләгеп куя. Быел беренче тапкыр Тәтешле районы үзәгенә беренче урын бирделәр. Аны ни өчен биргәннәрен чамалыйм. Бүген Тәтешле һәм Илеш районнарында татарларны башкортлаштыру сәясәте аеруча көчле бара.

Башкорт корылтае протекция буенча башкорт авылларына грант тарата, ләкин аларда берни социаль-икътисади үсеш юк. Башкорт районнарына элек-электән финанс ярдәме күп иде. Мортаза Рәхимов та акчаны бик күп койды. Рөстәм Хәмитов Урал аръягын үстерү буенча махсус программа эшләтеп, елгадай акча койды, ләкин аның нәтиҗәсе генә булмады. Радий Хәбиров та бу программаны дәвам итәргә вәгъдә бирде. Хак булса, алдагы берничә ел эчендә ул зонага 200 млрд сумга якын акча каралган.

Узган ел Азнакай белән Бакалы арасында күпер салу мәсьәләсе күтәрелгән иде. Татарстан аның яртысы бәясен капларга әзер икәнен белдерде, ләкин Башкортстан хакимияте баш тартты, ул татар районнары арасында икътисади бәйләнешнең үсүе милли бәйләнешкә йогынты ясавыннан курыкты.

Башкортстандагы татар оешмасы, гади генә фольклор ансамбле булса да, Татарстан белән берәр эш алып бара икән, аңа администрациядә бик начар карый башлыйлар. Татарстан белән турыдан-туры элемтәдә торган кеше Башкортстанда «кара исемлеккә» эләгә. Бездәк районындагы бер танышым гомере буе татар мәдәниятен үстерүгә зур көч куйды, бик күп мәдәни чаралар үткәрде. Лаеклы ялга чыгар вакыты җиткәч, аңа берни грамотага да өмет итмәскә кушканнар. Без бу апага татар оешмалары аркылы Татарстанның берәр дәүләт бүләген сорап карарга булдык.

Чынлыкта ике республика арасында берни дә проблема юк. Проблема – Башкортстанда татарларны кысрыклауда. Без андагы татарларның статусын күтәрмәсәк, ике республика арасындагы хезмәттәшлек бер тиенгә дә тормаячак.

Татарстан югары уку йортларында бик күп Башкортстан студентлары укый. Алар белән бик тыгыз эш алып барырга кирәк. Аларның күбесе Татарстанда кала дисәләр дә, минемчә, яртысыннан күбесе туган якларына кайта. Биш ел эчендә без студентлар белән элемтәне нығыта алсак, милли эштә алар безнең Башкортстандагы вәкилләребез булырлар иде. Казанда Башкортстан якташлары җәмгыяте оешса да әйбәт булыр иде. Монда Башкортстаннан килеп яшәүче татарлар күп бит.

– Башкортстанда җанисәп нәтиҗәләре ничек булыр икән?

– Җанисәп нәтиҗәләре ел азагында гына билгеле була, ләкин, хак булса, яшерен мәгълүмат буенча, Башкортстанда татарлар саны 2010 елдагы кебек булырга тиеш. Без җанисәп проблемасын ныклап күтәрә башлагач, моңа Татарстан җәмәгатьчелеге дә кушылгач, Башкортстан түрәләре үз позицияләрен йомшартты. Баштагы планнар буенча татарлар саны дүрт йөз меңгә кимергә, ә башкортлар саны шушы ук күләмдә артырга тиеш иде. Үз сүзебезне туры әйтүебез һәм позициябездә нык торуыбыз юкка булмады.

Йомшак булу, гел елмаеп тору, уртак элемтәләр булдырырга өметләнү беркайчан да Башкортстан татарларының хәлен яхшыга илтмәде. Моңарчы милли мәсьәләләрдә бөтен алга китеш хакимиятнең татарга уңай караш барлыкка килү аркасында түгел, ә активистларның каты торуыннан булды.

Рифат КАЮМОВ.

intertat.tatar

Мәдәни җомга
5 август
№30, 2022

Бәбки авылы

Бәбки авылы Буа районында, аның үзәгеннән 20 чакрым төньяктарак, Зөя елгасының уң як ярында урнашкан. Зөя еш кына үзенең юлын үзгәртеп тора, ел саен 8-10 метр авылга якыная бара. Шуңадыр, XI гасырдагы гарәп сәяхәтчеләре елганы «Дөбер су» дип атаган. Биредә руслар хуҗа булгач, Зөя елгасын «Свияга» дип атый башлый. Бәбки авылына XVII гасырның икенче яртысында нигез салынган дип исәпләнә. Тәүге кешеләр Олы Арза авылыннан килеп урнашкан диләр. Ләкин безнең гасыр археологлары Бәбки авылы тирәсендә Имәнкискә культурасына караган тарихи һәйкәлләр булуын ачыклады. Алар I-II гасырларда бу урында шәһәрчек булган, дигән нәтиҗә чыгарды.

XVIII-XIX гасырларда авыл халкы Рус дәүләте крестьяннары категориясенә кергән. Авылда чиркәү, аның мәктәбе, мәчет һәм мәдрәсә эшләгән. Шулай ук 3 җил тегермәне, 2 су тегермәне, тимерче алачыгы, 4 кибет, 1242 дисәтинә чәчү җирләре булган. Авыл янәшәсендә 1960 елларга кадәр Тирәнкүл, Мунчала, Сулау һәм Әби күлләре булса да, алар кибеп юкка чыккан. Авылдан Зөя елгасына таба Куян, Кыз, Корал таулары, Сугышчылар каберлеге булуы мәгълүм. Бу каберлектә язгы ташулар вакытында кеше сөякләре: бик озын аяк-кул, казан зурлыгындагы баш сөяге, бармак сөякләре табылган. Галимнәр авылга 17 нче гасырда гына нигез салынган дигән фикергә килсә дә, Зөя ярындагы комлыкларда кулдан ясалган билгесез язулы таткалар, 5 метр озынлыктагы, берничә җирдән боралап тишелгән борыс, имән агачыннан ясалган казыклар, кеше сөякләре табылуы бу җирлектә кешеләр аңа кадәр дә яшәвен дәлилли.

Авыл кешеләренең сөйләве буенча, янәшәдәге комлы җирләр астыннан гаять юан һәм озын буйлы имән агачлары күп табылган. Андый имәннәр күрше Килдураз авылы янәшәсеннән дә чыккан. 2016 елда мондый бер имән калдыгын Казанның руда булмаган файдалы казылмалар геологиясе үзәк институты тикшергән. Алар: “По результатам геолого-геоморфиологического анализа… возраст 11700 лет”, - дип бәя биргән. Кыскача аңлатканда, тамырлары туңлык катламында утыру аркасында һәлак булып, имәннәр туфракның тәмам җебеп бетүе сәбәпле ауганнар. Имәннәр таудагы боз эреп, аның белән бергә туфракның да таудан шуып төшүе сәбәпле, шул туфрак астында күмелеп калган. Димәк, бу имән агачлары 11700 ел буе ята…

Авылның «Бәбки» дип аталуын риваятьләр болай аңлата: бу җирләргә беренче булып аяк баскан кешеләр суда ялгыз каз бәбкәсен күрә. Аңа, әй бәбкәм, дип кызганып карап торганнар. Шуннан соң булачак авылны «Бәбки» дип атаганнар. Җирле халык авылны Бәбки дисә, документларда ул Черки-Бибкеево дип языла. Матур яңгырашлы «Бәбки» сүзенә «Черки» өстәмәсен ни сәбәпле китереп кушканнардыр, һич тә аңлашылмый. Черки-Гришино, Черки-Дүртиле, Черки-Килдуразы, Тюбяк-Черки, Табар-Черки, Черки-Бибкеево – бу тирәдәге берничә авылга менә шушы «Черки» атын өстәп чыкканнар. Килмешәкләр эше инде бу, шулар кулы...

Тарихи документларда авылдагы халык саны бу рәвешчә үскән:

1782 ел - 45 ир-ат (ул заманда кыз-хатыннарны исәпкә алмаганнар); 1859 елдан соң бар кеше дә исәпкә алына башлый - 579; 1908 ел – 1329; 1920 ел – 1181; 1926 ел –1005; 1938 ел – 849; 1949 ел – 655; 1958 ел – 130; 1970 ел – 278; 1979 ел – 143; 1989 ел – 86; 2002 ел – 34; 2010 ел – 26; 2015 ел – 21; 2022 елда 14 кеше яшәве мәгълүм.

1920 елга чаклы авыл Казан губернасының Тәтеш өязе Зур Фролово авылы волостена кергән. 1920 елдан Тәтеш, 1927 елдан Буа кантонына күчкән. 1930 елның 10 августыннан Буа районына керә. Хәзерге вакытта Черки-Килдураз авылы җирлегендә исәпләнә.

1930 елда авылда «Авыл хуҗалыгы артеле» оеша. Аңа «Пролетарий» дигән исем бирелә. 1931 елда ул «колхоз» дип үзгәртелә. 1958 елда «Пролетарий» колхозы бетерелә, колхозчылар күрше Килдураз авылындагы «Авангард» колхозына кушыла.

1917 елгы революцияләр һәм гражданнар сугышыннан соң башланган кызыл террор һәм репрессия гамәлләре Бәбки авылын да читләтеп үтми. Бик күп гаепсез кешеләр төрмәләргә, концлагерьларга, Себер һәм Казахстан далаларына гаиләләре белән сөргенгә озатыла. Аларның гасырлар буе җыелган мал-мөлкәтләре, җирләре, йорт һәм каралтылары тартып алына. Хак булса, Бәбкидән дә якынча 50 гаилә башлыгын Урал аръягына озатканнар.

1. Хөсәенов Касыйм, 1880 елда Бәбкидә крестьян гаиләсендә туган. Авыл Советы рәисе. 2.04.1935 елда кулга алына. 11.8.1935 елда колхозга каршы агитация алып баруда, колхозда язгы чәчүне тоткарлауда гаепләнеп, 6 елга концлагерьга озатыла.

2. Гусаров Иван Семенович, 1873 елда туган, рус. 28.3.1930 елда кулаклар оешмасында катнашуда гаепләнеп, 2.6.1930 елда атылуга хөкем ителә. 13.6.1930 да атылган.

3. Александров Александр Прокофьевич, 1896 елда Бәбкидә туган, поездларда вагон мастеры булып Свияжск ст. эшләгән. 29.9.1942 елда кулга алынган. 10 елга концлагерьга хөкем ителгән.

4. Борисов Сергей Александрович, 1891 елда туган. Колхозда умартачы булып эшләгән. 20.2.1937 елда кулга алынган, 5 ел концлагерь җәзасы.

5. Брагин Андрей, 1872 елгы, рухани. 1918 елның маенда Совет хөкүмәтен танымауда һәм буйсынмауда гаепләнеп кулга алына. 1918 елның декабрендә атып үтерелә.

6. Вахитов Каюм, 1880 елгы, Бәбки авылы мәчете мөтәвәллие. 2.4.1935 елда кулга алына, 4 елга концлагерьга хөкем ителә.

7. Краузе Фридрих Андреевич, 1916 елгы, Бәбкидә яшәгән, немец. 24.11.1941 елда кулга алына һәм Казан психик авырулар хастаханәсенә җибәрелә, 1944 елда шунда вафат була.

8. Киселев Василий Семенович, 1909 елда Бәбки авылында туган, рус, 2 улы булган, шофер, полуавтоматларда мастер булып, 220 нче шариклы подшипник заводында эшләгән. Немецларны мактап агитация алып баруда гаепләнеп, 27.12.1941 елда кулга алына. 23.5.1942 елда 10 елга Воркута концлагерена җибәрелә.

9. Мингалимов Шәрифулла, 1878 елда Бәбкидә туган. Гаиләсендә 8 кеше, «Пролетарий» колхозчысы. 2.4.1935 елда колхозлашуга каршы агитация алып баруда гаепләнеп кулга алына. 11.8.1935 елда 6 елга концлагерьга озатыла.

1939 елның 1 сентябрендә Икенче бөтендөнья сугышы башлана. 1941 елның 22 июнендә инде Икенче бөтендөнья сугышы СССР һәм Германия дәүләтләре арасындагы Бөек Ватан сугышына әйләнә. 1945 елның август аенда СССР Япония дәүләтенә каршы сугыш ача. Яу хәрәкәтләре 1945 елның сентябрь аенда тукталыла. Бу сугышларда Бәбки авылы кешеләре дә катнаша. Күп кешеләр яуда үлсә, кайберләре әсирлектә вафат булып, чит-ят җирләрдә ятып кала. Авылдан сугыш кырына чыгып китүчеләрнең күбесенең кайчан, кайда һәм нинди сәбәптән югалып калуы да билгесез.

Бәбки сугыш елларында 80 гә якын ир-егетен югалта. Кайсы Мәскәү һәм Сталинградны яклаганда, кайсы Херсон, Харьков, Киев, Ленинград, Латвия, Эстонияне азат итү яуларында башын салган. Кайбер сугышчыларның язмышлары бик гыйбрәтле, шуларны булса да телгә алыйк әле.

Костюхин Анатолий Семенович, 1919 елда Бәбкидә туган, гвардия өлкән лейтенанты. 18.4.1945 елда яралардан вафат булган. Ул 1943 елда госпитальдән дәваланып чыккач, бер көнгә гаиләсе янына кайта. Ләкин анасы хатыны белән төн кунарга ирек бирми: Ике балаң бар, өченчесен калдырмакчы буласыңмы? – дип хатыны ятагына якын да җибәрми...

Минкашев Хәлиулла Сәмигулла улы, 1914 елда Бәбкидә туган. Туганнарына һәлак булуы турында хәбәр килә. Ләкин ул яраланып исән кала. Хәлиулла туганы Минкашев Корбангали белән бер полкта хезмәт итә. 1942 елның гыйнварында Туапсе янәшәсендәге 301 биеклек өчен барган сугышларда Корбангали батальоны 301 нче биеклекне немец гаскәреннән алу өчен атакага җибәрелә. Ләкин аларның бөтен батальоны һәлак була. Чөнки, тау итәгендәге калкулыкка урнашкан дошман, ачык җирдән килүче кызылармиячеләрне тиз арада юк итә. Ә аларның атакасы самолет, танк, пушка, миномет уты белән тәэмин ителми. Бу вакыйганы Хәлиулла үз күзләре белән күреп тора. Алар артыннан Хәлиулла хезмәт иткән икенче батальон атакага җибәрелә. Немецлар бу батальонны да юк итә. Хәлиулла берничә үлгән иптәшләре арасында, 2 атна яраланган килеш снаряд чокырында ята. Ике атнадан соң янә һөҗүм итеп, совет гаскәрләре 301 биеклекне алгач, Хәлиулланы медсанбатка алып китәләр. Шул ике атна арасында аның һәлак булды дигән хәбәре барлык инстанцияләргә таралып өлгерә, ул һәлак булганнар исемлегенә кереп кала. Туган авылына да кара пичәтле хат җибәрелә. Ләкин ул исән-сау килеш сугыштан соң туган авылына әйләнеп кайта. «Мин яраланмаган булсам, шул вакытта, дезертир, яисә сатлыкҗан дип хөкем иткән булырлар иде», - дип сөйли Хәлиулла...

Галиәкбәров Гомәр Г. 1916 елда Бәбкидә туган. 7.7.1943 елда һәлак булган. Курс өлкәсе, Поныри авылы янында җирләнгән. Бу белешмә Оборона министрлыгында ялгышлык белән теркәлгән. Гомәр Галиәкбәров һәлак булмаган, әсирлеккә эләккән. Ул Германиягә хәрби лагерьга җибәрелә. Аны немец офицерының биләмәсенә эшкә алалар, шунда яши дә. Бервакыт хуҗа-немец фронттан отпускка ялга кайтып төшә (Германия армиясендә һәр хәрби кешегә, сугыш хәрәкәтләре булуга карамастан, 10 көн ял бирелгән.) Өендә Кызыл Армия әсирен күргәч, аны атып үтерергә теләгән. Ләкин хатыны аны бу эштән тотып калган. Гомәрне кабат лагерьга җибәргәннәр. Анда, еврей диеп, газ камерасына җибәрелгән төркемгә эләккән. Шул газ камераларында хезмәт итүче кеше Гомәрнең бер танышы булып чыга. Һәм ул немецларга аның еврей түгел, татар икәнен җиткерә. Гомәрне газ камерасына керүче төркемнән аералып алалар. Сугыш беткәч, ул авылга кайта. Ләкин аны, әсир булганы өчен, 7 елга Себергә, Сталин лагерьларына хөкем итәләр. Аннан да исән кайта, «Пролетарий» колхозында эшли. Бәбки авылында җирләнгән. 1939 елда туган улы Әнвәр хәзер Ульяновск шәһәрендә яши, фән кандидаты.

Расих ҖӘЛӘЛ.

ЯРАТАМ ӘЛЛӘ НИЧЕК

Яратам шул бу дөньяны,
яратам әллә ничек:
бозлар кичеп яратам да
яратам утлар эчеп.

Илүзәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!

Иртәләрем, көннәремә,
кичләремә таң калам:
өзгәләнеп, ямьсезгә дә
матурым дип әйталам.

Илүзәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!

Узмас сыман ачылары –
уза бит әллә ничек:
яратам шул бу дөньяны
каласын белгән өчен.

УЛ ШУЛАЙДЫР ӘЛЕ, УЙЛАСАҢ...

Рәхәтләнеп көлеп яшәгәндә
Башкаемны авыр уй баса:
Бу дөньяда әле бер көлүең
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң?!
Гомер итү әллә нинди нәрсә,
Үзе татлы, үзе әрнетә.
Елап яшәүчеләр шуңа күп ул –
Көлеп яшәүләргә ни җитә,
Көлеп яшәүләргә ни җитә?!
Ак көненне буса төн карасы,
Төнне арттан буып ала таң.
Бу дөньяда әле бер елавың
Җинаятьтер, бәлки, уйласаң,
Ул шулайдыр әле, уйласаң?!

АВЫЛДАШКА ХАТ

Аэродром иде безнең урам:
Казлар күтәрелде каңгылдап,
Бүрәнәгә утырып сөйләштек бер:
Мин китәргә булдым авылдан.

Рөстәм МИНГАЛИМ

ике такта – бер басма, ди,
уртасында мәхәббәт!
Шуны язып, әллә кемнәр
язучы булып җитте.
– Милләткә аннан ни файда? –
дисеңме?
Сорау җитди!
Без барыбер языйк, энем,
каләм бит ул бездә бар.
Ашап дуңгыз да булалар,
укып дуңгыз булмаслар.

БУ ЕЛЛАРДА...

Үземә

Без актарган таулар артта калды,
таш күтәрер көчем, калмады.
Хәзер көчем – сирәк бәйрәмнәрдә
йөз грамм да ярты алмалык.
Узды китте яшьлек сәер чорда,
сәерләтеп узды җанымны.
– Яшь кызлар! – дип
өзелеп ялганмадым,
гел ханымнар күзгә чалынды.

Аэродром иде безнең урам: Казлар күтәрелде каңгылдап...

(Татарстанның халык шагыйре Рөстәм Мингалимнең тууына 85 ел)

Илүзәрем, ак канатым,
пар канатым син икән.
Дөнья гаҗәп матур икән,
дөнья гаҗәп киң икән!

ҮПКӘЛӘРМЕН КЕБЕК

Хатамдырмы, юкмы,
Тик сөйләмим көлеп:
Миңа Татарстан –
Җир үзәге кебек...
Йөрим кайчак чыгып,
Шәһәрләрем күреп;
Казан – шәһәрләрнең
Иң гүзәле кебек.
Сорасалар әгәр,
Бирә алмам бүлеп:
Мәскәү – Татарстан
Шәһәредер кебек.
Мин дөньяны сөйдем,
Дөнья торсын белеп:
Ул да – Татарстанның
Бер өлеше кебек!
Хаталанма, диеп
Әйтсә кемдер, көлеп, –
Шул кешегә мәңге
Үпкәләрмен кебек.

ВОЕНКОМАТТА

Нигә
Бу егетләрне үлчәп маташасыз
Салкын, җансыз үлчәгечләр белән?
Алар –
Әтиләре сугышка киткәндә
Кайнар биләктә калдылар.
Төгәл авырлыкларын
бары әниләре белә.
Алар –
Иң биек агач очыннан
чикләвек өзделәр,
Иң биек тау түбәсеннән
чия таптылар;
Иң биек атны
йөгәнләделәр.
Кул арасына керү белән,
Аларның төгәл буйларын
бары әниләре белә.
Булашмагыз,
«Хезмәткә яраклы» дип языгыз
үлчәмичә генә!

Кайбер агайларга үпкәләдем, –
Булмагангадырмы этиләр,
Безнең колакларны еш бордылар,
Авыр-авыр сүзләр әйттеләр.
Күнегергә теләү туды миндә.
Тик өстенлек алды чиркану.
Малай булсаң да бит, горурлык бар,
Тамырларда барыбер ир каны;
Шуңа түгелмени авыл эшен
Бик тиз генә алдык өйрәнеп?!
Йөгәненнән тотып, зур атларны
Кырмыскалар кебек сөйрәдек.
Бүген сезнең кулда машинадыр,
Исәннәрме теге агайлар?
Безне шактый кимсеттегез диеп,
Син бәрелмә инде аларга:
Калса калган икән безнең хәтер,
Аларның да хәтере калмасын...
Әй, ташлыйк ла моны, ничек хәзер
Кәрим бабайларның алмасы?
Клуб ничек? Яшь-җилкенчәк кызлар
Сибәләрме «Ярмәк» көенә?
Безнең буын ничек – «абый» булгач,
Онытып бетермиме биюне?
Самолетлар төсле күтәрелеп,
Очалармы казлар каңгылдап?
Кашка бия күптән үлдеме соң?
Ә малайлар ничек авылда?
Әтиләре бармы барсының да?
Әтисезе булса, син тагы
Берүк авыр сүзләр әйтә күрмә,
Бора күрмә берүк колагын!

АК БОЛЫТЛАР...

Күккә карап еш сөйләшәм хәзер,
Үзем генә калгач, бергә-бер.
Әткәм, бабам, аның бабасы да
Бу күк йөзен шулай күргәндер.
Күпме утте, утте ак болытлар –
Еллар битен сыйпап, иркәләп...
Гомер иттем, җыйдем, канатландым.
Бәйрәм, җырлар
Истә... истәләр.
Әрнеп-әрнеп елаганым да бар,
Чыплап елау булмый онытылырлык:
Җан теленде, ачык яраларда
Тоз таулары эреп утырды.
Шуның өчен көлгән чагым булды
Яралану, әрнү, елаудан,
Мәхәббәттән,
Табу, югалтудан;
Гомер, тарих,
Уйдан,
Юллардан.

Мин көлмим дә хәзер, еламыйм да,
Әллә нинди сәер чак килде:
Еласам, мине һичкем юата алмас,
Көлсәм – туктап булмас шикелле.

ИКЕ ТАКТА – БЕР БАСМА

Язучы Ркаил Зәйдуллага

Син, энем, затлы фикерләр
уйлап йөрисең, беләм.
Аларны язып халыкка
бирмә келисең, беләм.
Мин дә күп уйлап уелдым,
язып та карый идем.
– Алыгыз, ал! – дип, татарга
үрелеп арый идем.
Алар мине ишетми дә,
күрми дә сыман юри.
...Яннарында сәер янгын
үзләрен ялмап йөри.
Беттеләр болар дигәндә –
калганнары табыла:
сөннәтлесе, сөннәтсезе –
үз сөягең таныла!
Ул ат булган җирдә булыр,
себерке торган җирдә.
...Товар сата-ала белер,
эчә белер хәмер дә.
Сүгенүе нәзек чыгар,
кысылыбрак, тоныграк.
Йә гөрләгән тавышы да
нечкәреп алыр кайчак.
Ул әйбәт «господин» булыр,
иң әйбәт «холоп» булыр.
Ана телен яхшы белмәс,
шул безнең халык булыр.
Ясканма әллә ни затлы
шигырь бирәм дип аңа.
Андыйны кабул итми ул,
аңа кирәкми яңа.
Аңлашырлык иске булсын,
хатыннар төсле булсын.
Ал ягы текә булсын да,
арт шәриф көчле булсын.
Яз, энем, минемчәрәк син,
йә Ризван Хәмид кебек.
Гәрәй Рәхим киңәшләрен
тыңлап кара бер кереп.
Әйткән сүзен Батулланың
ишеткәнең бардыр, шәт:

Уйлап шуны хәзер елмаям да,
сызланам да кайчак утырып.
Мин гомерне тормыш учагына
яктым бугай артык тутырып.
Күралмадым татлы малай-йокы,
саташулы булды төннәрем.
Төшкә керде күрше матур апа,
мин иреннән аны көнләдем.
Егет булган мәлдән көннәрем дә
саташулы төшкә әверелде.
Муеннан ук иде яшьтәшләрем,
яшем җитмәсләргә үрелдем.
Әти булгач – кемгә бәхет бирдем,
үзем йөрдем дөрләп-куанып!
Бүгенгәчә янып бетмәгәнгә –
мин тилегә һәйкәл куярлык.
Күләр идем карап – һәйкәле юк,
һәм күңелдә нәни бер шом бар.
Бу елларда нык картайдым, ахры,
гел чалына күзгә яшь кызлар.

ТОМАННАРГА ТАБА ИЛТТЕЛӘР

Сары бодай кыры җилдә кайный,
әйләнәсе тимер сак иде...
Үҗәтләнеп безнең үсеп йөргән,
гел ашыйсы килгән чак иде.
Бирмәделәр ипи туган якта,
читтә бәхет вәгъдә иттеләр.
Төяп-төяп безне поездларга,
томаннарга таба илттеләр.
Безне суга сипте пароходлар,
машиналар җиргә таратты.
Кемдер сугып тешне
койды безнең,
кемдер каршылады яратып...
Әвереләдек моңлы килмешәккә,
чын йөрәктән җырлар чыгардык.
Җырыбызга тыгылып үләр чакта,
туган якны уйлап чыдадык.
Табалмадык читтә бәхет димим,
бөтенләй үк буш кул кайтмадык.
Туган якка кайткач, күпләребез
әнкәйләрне генә тапмадык.
Инде безнең күңел
шул вакыттан
мәңгелеккә хәтле өшегән...
Киләчәкнең тимер түрәләре
ни күрсәтер тагын кешегә?!

Һәр ел репрессия корбаннарын искә алу чараларында Казанның Архангел зиратына берничә дистә кеше җыела. Аларның күбесе – өлкән яшьтәге карт-карчыклар. Бирәдә ике метрлы мәрмәр плитәләрдә шәхес культы корбаннарының исемнәре чокып язылган. Берничә мең исем арасында безнең газиз бабабыз Сөнгатулла Бәдретдин улы Мәһдиевнең исеме дә бар. Ә мазарстанның түрендә бетон койма буйлап ак каеннар үсеп утыра. Шул тирәдә чардуганнар арасында кеше буе кызгылт таш һәйкәл бар. Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов хөрмәтенә куелган истәлек ташы ул. Әдипнең тормыш юлын өйрәнгән галимнәр сүзенә караганда, бу үзенә күрә символик кабер. Уйлап карагыз, даһи юлбашчы көйләгән «канлы конвейер» тулы куәткә эшләп торганда кем инде җәзалап үтерелгән бәндәнең мәетен, аның кем булуына карамастан, кадерләп җирләп, билгеләп маташсын, ди...

Шомлы еллар





● Язучы Мөхәммәт Мәһдиев һәм аның әти-әнисе.

Садри Җәлал үзенең истәлекләрендә, Плөтән төрмәсендә, классик әдип белән бер камерага туры килеп, инде синдәй ата коммунистны да кулга алгач, нихәл итмәк кирәк, дигән риторик сөальгә, Ибраһимов: «Күгәрчен көтүенә карга баш булгач, үләксә чукуы табигый», – дип уфтанган, имеш.

Картларның сүзенә караганда, теге шомлы елларда шушы койма янында озын гына котлован казылган булган, төннәрен шуңа машиналар белән Черек күл подвалында атылган «халык дошманнары»ның мәетләрен китереп бушатканнар. Кем белә, бәлки безнең бабабызның җәсәде дә шул каеннар астында ятадыр... Соңрак шушы ундырышлы вә дымлы җиргә үсентеләр китереп төрткәннәр һәм тора-бара бирегә, агач араларына, вафат булганнарны күмәргә рөхсәт бирелгән. Шулай итеп, коточкыч җинаять эзләре астыртын һәм мәкерле юл белән җуелган. Эзтабарларга эксгумация ясау өчен һичнинди мөмкинлек калмаган. Хәзер биредә мәһабәт ак каеннар яфрак ярып моңсу гына язгы җилләрдә тибрәлә. Каеннарның җәелеп куклэргә ашып үсеп утыруы, үткәннәрнең шомлы кайтавазы булып, гыйбрәтләнергә һәм моннан дистә еллар элек булган трагедияне онытмаска өнди сыман.

Халык язучысы Мөхәммәт абый Мәһдиев истәлекләреннән тетрәндергеч юллар: «...Аларны, Арча районындагы элекке җиде мулла һәм бер укытучыны, 1937 елның 19 декабрь төнендә җыеп алдылар. Укытучы дигәне әлеге «группа»ның исемлеген НКВД-ОГПУ органнарына биргән. Сигез кешелек «группа» Арча районында колхозга каршы контрреволюцион оешма төзүдә гаепләнә, имеш. Арча базарына килгәч, бер урыска чәйгә кереп, шунда колхозларның һәлакәте турында сөйләшеп утырганнар. Шулай сөйләшкәннәрдер дә. Чөнки 1933–1936 елларда авылларда коточкыч ачлык оештырылган. Аерым хуҗалыктан җыеп алынган атлар ачлыктан кырылып беткәннәр иде. Теге доноста бу чәй мәҗлесендә катнашкан кешеләрнең исемлеге бирелгән. НКВД-ОГПУ рәхәтләнгән инде! Әлеге исемлектә 1933 елда бер тапкыр утырып чыкканнар да бар. Арада – минем әти. Имеш, «контреволюцион» бу оешма белән Париждан торып Садри Максуди җитәкчелек итә. Ә аның Казандагы «агенты» – журналист Гыйлемдар Баимбетов икән. 19 декабрь корбаннары НКВД-ОГПУ подвалларында нәкъ уналты көн җәфа чиккән. «Тройка»ның соңгы карарын укыйм. Сигез кешедән иң соңгы документ – әтинеке.

– Үзегезнең совет строена каршы контрреволюцион оешмада торуыгызны таныйсызмы?

Дер-дер килеп документ укыйм. Барысының да җавабы бер:

– Әйе, таныйм. Мин контрреволюцион оешмада әгъза идем. Совет властена каршы көрәштем.

Күрәсең, бик каты кыйнаганнар, газаплаганнар. Хәтта теге «доносчы» да шулай дип имза куйган. Соңгы документ: әтинең язуы. Мәрхүм, русчасы бик әйбәт иде, үләр алдыннан язган соңгы җөмләсе: «Ни в какой контрреволюционной группе не состоял, виновным себя не считаю». Имза.

Аны әллә ул кадәр үк каты кыйнамадылар микән?

Ләкин барысын да атканнар 1938 елның 5 гыйнвар иртәсендә. Һәрберсенең үлеме турында автобус талоныннан аз гына зуррак кәгазь «дело»га ябыштырылган. Үлүләрен раслап, табиб кул куйган. Сигез кешене атып үтерү өчен сигез-ун минут вакыт җиткән. Арча районы шулай итеп чистартылган».

Бу вакытта гаилә башлыгы, бабам Сөнгатулла хәзрәт Мәһдиевкә нибары 53 яшь була. Байтак еллар узгач, аның шулай ук «Һади Атласов җитәкчелегендәге җинаятьчел, бөтендөнья империалистларының корткычлык оешмасының активисты» булуы һәм әлеге оешманың төп максатлары – Совет илен җимерү, «даһи юлбашчының» башына җитү һәм кире патша режимын торгызу булган икән.

Кулга алынган кешеләргә мөнәсәбәт ничек булган? Аларга карата мәрхәмәтлелек вә шәфкатьлелек күрсәтелгәнме? Тарихи язмалардагы, истәлекләрдәге вәхшиләрчә газаплаулар чынлыкта булганмы? Әллә болар барысы да язучы-журналистларның «авыру фантазиясенең җимешеме»? Аерым шәхесләрнең газапларга түзә алмыйча үз-үзләренә кул салуларын күпмедер дәрәҗәдә ачыклаучы дәлил дә, соңгы араларда «халыклар атасы»н яндән кабереннән торгызып кайтару хыялы белән җенләнгән кайберәүләргә кире какмаслык дәлил китерергә мөмкин.

Интернет сәхифәләренең берсендә 1939 елның 10 гыйнварында ВКП(б) Үзәк Комитетының «Үтә дә яшерен» грифы астында тоткыннарны җәзалауга рөхсәт итәлү турындагы карары пәйда булды. Без әлеге документны күренекле журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим әфәнде Яушевның фейсбук сәхифәсендә таптык. Әлеге карарда репрессияләр чорында кулга алынганнардан сорау алу вакытында кыйнау-җәзалауларны кем рөхсәте белән башкарылган һәм бу гамәлләрне ничек акларга, аларның ни дәрәҗәдә үтемле, «халык дошманнары»н фаш итүдә никадәр файдалы икәнлеге аңлатылып бирелә. Боерык-хат формасында язылган ошбу бит ярымлык документ өлкә һәм край партия комитетлары, милли компартияләрнең Үзәк комитетлары секретарьларына, эчке эшләр халык комиссарларына, НКВД идарәләренең башлыкларына атап язылган.

Дәүләт җитәкчелеген нәрсә борчыган соң? Халыктан яшерерлек нинди сер булган? Хатның татар теленә тәрҗемәсе: «Урыннардан килгән хәбәрләр буенча, – диелә карарда, – өлкә һәм крайком секретарьлары НКВД идарәләренең эшчәнлеген тикшергәндә кулга алынган кешеләргә карата физик көч кулланыну гаепле эш дип карыйлар һәм әлеге гамәлнең җинаять булуын фаш итәләр. Шул уңайдан партиянең Үзәк Комитеты тоткыннарга физик көч куллану 1937 елдан ук ВКП(б) ҮК рөхсәте белән башкарылуын искәртергә мәҗбүр». «Тәҗрибә күрсәткәнчә, диелә хатта, әлеге чаралар халык дошманнарын фаш итүне шактый җиңеләйтте һәм шулай итеп уңай нәтиҗәләр бирде. Шуның белән бергә тора-бара кайбер кабахәт затлар, шул җөмләдән Задовский, Литвин, Успенский һ.б. эшчәнлеге аркасында очраклы рәвештә кулга алынган намуслы кешеләргә карата да физик көч куллана башлады. Әлбәттә, бу башбаштаклыклар өчен әлеге затлар тиешле җәза алды. Әмма моның белән генә сорау алуның әлеге ысулларының әһәмияте югалмады», – диелә партия карарында.

Үзәк Комитет бу чараны ничек аклый соң? Дәлил бик гади һәм җәмгыятьтә бара торган хәлләргә «сыйнфый көрәш» күзлегеннән карап эш кылучылар мантыйгына мач килеп тора.

Мәгълүмдер ки, диелә документта, социалистик пролетариат вәкилләренә карата буржуаз разведкасы тарафыннан физик көч куллану киң таралыш алган, өстәвенә дошманнар аның коточкыч ысулларын эшкә җигә икән. Ә безнең социалистик разведка алардан кай ягы белән ким? «Буржуазиянең тугрылыклы агентлары эшче сыйныфның һәм колхозчыларның гомерлек дошманнарына карата без гуманлы булырга тиешме соң?» дигән риторик сорау белән тәмамлана яшерен күрсәтмә.

Бу урында көндәлек матбугатта дөнья күргән бер истәлекне китереп үтми мөмкин түгел. Рашат Низаминың «Сират күперен кичкәндә» дигән мәкаләсе чыкты. Анда сүз репрессия корбаны Васил Касыйм улы Адаевның ачы язмышы турында бара. Бу кеше 1910 елда Дөбьязда туган. Ул кулга алынуы, җәзалануы турында менә нилэр язып калдырган: «Мине «черный ворон» дигән каплаулы, бер генә кешелек камералы машинада алып киттеләр. Икенче катта сорау алдылар. Сорау алучы хәрби киемле, 35–40 яшьләрдәге татар кешесе иде. Сорау алганда ныклап кыйнамадылар үзе, ләкин бик кысып карадылар мине. Колак төбенә наган терәү, яңакка сугулар булмады түгел. Ә башка иптәшләр 2–3 көнлек сорауда булып кайтканда – алар кыйналудан, төрле җәфалаулардан хәлдән таеп кайтырлар иде. Аяклары шешкән, йөзләре кара көйгән була, кыйнаулар, карцерга ябу, берничә тәүлек буе бастырып торгызулар, кыскасы, нинди җәза ысуллары бар – барысы да кулланышта иде». Васил Адаев сүзләренә караганда, Казан читендәге Коры елга басуында репрессия корбаннары күмелгән туганнар каберлеге дә булган, имеш.

Архивларда ниләр бар?

1998 елның октябрендә мин бабамның эше белән Татарстан Дәүләт иминлеге һәм КПССның өлкә комитетлары архивларына барып таныштым. Монда бәян ителгәннәрне дәлилләр белән беркетү йөзеннән, кулымда булган документларны китерәм. Менә алар: 9268 санлы 1937 елның 28 декабрендә ачылган һәм шул ук көндә төгәлләнгән «дело» бунча кыскача белешмәдә кулга алынучылар исемлеге китерелгән: Мөслимов Габделхәй – Мәтәскә авылыннан; Гаффаров Хәнәфи – Биектау районы Тимерче авылыннан (бу урында чигенеш ясап, Мөхәммәтхәнәфи хәзрәт турында

кайтавазы...


"УТВЕРЖДАЮ":
Полномочный Представитель ОГПУ по Татарской АССР: (В. ГАРИН).
"9" Октября 1933 года.

ОБВИНИТЕЛЬНОЕ ЗАКЛЮЧЕНИЕ

по делу

о контр-революционной, повстанческой организации, именующейся "ВСМ", вскрытой на территории Татарской Республики.

40. МАГДИЕВ Сунгатулла Бадретдинович, 1885г. рождения, татарин, уроженец дер. Сокортан, Арского р-на ТР, житель дер. Малый Муй, того же р-на, сын муллы, сам мулла. Окончил медрессе и русско-татарскую школу. Женат, детей 6 человек, старшему 14 лет, -

В ТОМ, ЧТО:

Состоял членом Арской ячейки к/р. организации и руководил практической к/р. деятельностью ее, заключающейся: в насаждении повстанческих настроений среди населения, в агитации против мероприятий партии и правительства и в распространении провокационных слухов с использованием религиозных предрассудков верующих масс. Был в непосредственной связи с руководителями к/р. организации БИГАЕВЫМ, МАКСУДОВЫМ и др.

(Том 3-й, стр. 619, 620, 599, 616),

т.е. в преступлении, предусмотренном ст. 58-10, 11 УК.

ВИНОВНЫМ СЕБЯ НЕ ПРИЗНАЛ, но изобличается показаниями других обвиняемых.

кайбер мәгълүмат биреп китүне кирәк дип саныйм. Бу – хәзрәтнең оныклары Тимерче авылы балалары бертуган Әнәс һәм Альберт белән шәхсән таныш идем. Хәзрәт турында мәгълүмат «Адрес-календарь и справочная книжка Казанской губернии на 1915 год» белешмәлегендә дә бар: «Мүлмә волосте, Тимерче авылы имам-хатыйбы Мөхәммәтхәнәфи Мөхәммәтсафа улы Гаффаров»), Галиев Зәки – Көтек авылыннан; Ногманов Каюм – Югары Бәрәзә авылыннан, Мәһдиев Сөнгатулла – Гөберчәк авылыннан. Шушы «дело»да 1937 елның 15 декабрендә төзелгән рапорт бар, аңа түбәндәге затлар кул куйган: Хисамов Ризван – колхозның вакытлыча рәисе, Җиһаншин Мөбарәк – хисапчы, Йосыпов Галимҗан, Маннапов Хаммат (читтән кайткан яшь укытучы, активист – **Р.М**).

Документлар арасында шулай ук 1937 елның 19 декабрендә кулга алу ордеры да бар. Моннан тыш бирелдә шулай ук әтием Мәһдиев Рәшитнең 1941 елның 31 гыйнварында НКВДның Арча район бүлеге начальнигы исеменә гариза язуы турында беркетмә дә теркәлгән. Шуңа җавап йөзеннән, миңа мондый аңлатма бирелә: «Гариза бирүчегә телдән СССР НКВДсының боерыгы буенча, аның атасы Мәһдиев Сөнгатьнең хөкемгә тартылуын җиткерегез. Шәхсән үзегезгә хәбәрдар булуыгыз өчен, Мәһдиев Сөнгатьнең ВМН (высшая мера наказания) хөкем ителүе турында җиткерәбез».

«Дело»да шулай ук 1936 елның 25 августында сорау алу протоколлары да бар. Сорау алуда түбәндәге затлар, нигездә Гөберчәк авылы кешеләре катнашкан: Вәлиуллин Әсхәдулла (1883 елда туган); Хөсәенов Хәсән (1872); Йосыпов Галимҗан (1907); Маннапов Хаммат (1911); Әхмәтҗанов Әхмәтҗан (1886); Колесников Александр.

Мин Татарстан партия архивына барып, анда саклана торган документларны да өйрәндем. Бабама кагылышлы кәгазьләр арасында укыйбыз: «Гомуми исемлектә 40-нчы булып Мәһдиев С.Б. теркәлгән, 1885 елда туган. Арчадагы контрреволюцион оешманың әгъзасы булган һәм чынбарлыкта шушы оешманың контрреволюцион эшчәнлеге белән җитәкчелек иткән. Бу оешманың максаты – халык арасында властька каршылык күрсәтүгә өндәү, партия һәм хөкүмәт үткәрә торган чараларга каршы агитация алып бару һәм дин белән агуланган халыкны төрле хорафатларга таянып, провокацион имеш-мимешләр тарату. Контрреволюцион оешманың җитәкчеләре Бигаев һәм Максудовлар белән тыгыз элемтәдә торган. 58–10 маддәсендә каралган җинаятьне эшләүдә үзен гаепле дип санамый, әмма әлеге җинаятьләрдә гаепләнүчеләр тарафыннан фаш ителә.

39 нчы – Зарипов Закир (Тимершык, Саба) үзен гаепле дип танымады;

41-нче – Гыйниятуллин Галимҗан (Татар Урматы) гаебен таныды;

42-нче – Галиев Әхмәт (Кәче) гаебен танымады;

44-нче – Яхин Фатыйх (Мәтәскә) гаебен танымады;

45-нче – Зарипов-Галиев Сабир (Көек) гаебен танымады;

46-нчы – Бакиров Сабир (Олы Бирәзә) гаебен танымады;

Әлеге делода шулай ук түбәндәге кешеләр телгә алына: Хәйруллин Гарәпша – Орнашбаш; Усманов Габдулла – Колачы; Габдрахманов Шиһап – Югары Бәрәзә; Гаффаров Хәнәфи – Тимерче».

Шушы көннәрдә генә минем кулыма «Сәяси репрессия корбаннарының Хәтер китабы» килеп ирешә (8 нче том, 2003 ел). Ошбу китапның 218 битендә бабам турында татар һәм рус телләрендә менә нәрсәләр хәбәр ителә: «Мәһдиев Сөнгать Бәдретдин улы, 1885 елда Арча районы, Сикертән авылында туган, Гөберчәк авылында яшәгән. Татар, 6 баласы булган, мулла. 30.01.33 кулга алынган. Җинаятьләр кодексының 58–11, 58–10 маддәләре буенча гаепләү белдерелгән. 15.05.33 читкә китмәү турында имзанамә алынган. 13.12.33 эш туктатылган. 19.12.37 кабат кулга алынган, 28.12.37 Җинаятьләр кодексының 58–11, 58–10 маддәләре буенча хөкем карары: үлем җәзасы, мөлкәтен конфискацияләү. 5.01.38 Казан шәһәрендә атылган. 14.02.57 акланган». Китапка өстәмә рәвешендә бирелгән аңлатмада Җинаятьләр кодексының 58–11, 58–10 маддәләренең эчтәлеге дә искәртелгән, менә алар: «58–10. Совет властен бәреп төшерү, аны какшату яки хәлсезләндерүгә юнәлтелгән пропаганда яисә агитация алып бару... 58–11. Шушы бүлектә күрсәтелгән җинаятьләрне кылу өчен төрле оештыру эшчәнлеге алып бару, аларны әзерләү һәм башкару...»

Минем шәхси архивымда ТАССР Югары Судының 1957 елның 20 февралендә В–41 санлы белешмә дә саклана. Аерым алганда, анда мондый юллар бар: «1957 елның 14 февралендә Татарстан АССР Югары Суды Президиумы Арча районы Сикертән авылында 1885 елда туган Мәһдиев Сөнгатьнең хөкемгә тартылуы турындагы эше кабат тикшерелде. Гаепләүләрнең исбатланмаганлыгы уңаеннан, ТАССР НКВДсы каршындагы Өчлекнең 1937 елгы 28 декабрь карарының производствосы туктатыла». Белешмәне ул вакыттагы Татарстан АССР Югары Суды рәисе А.Орлов имзалаган.

Шушы коточкыч вакыйгалар бабамның хәләл җефете Рәбига абыстайның йөрәгә аша үткән. Аның күпме кан-яшь түккәнен, хәсрәт чигеп уйланганлыгын Аллаһ Тәгалә һәм ул үзе генә беләдер. Ничек түзгәндер аның йөрәккәе, ничек көч-куәт тапкандыр шушы кайгы-хәсрәтне күтәрергә. Әлбәттә, кылган догалары, намазлары аңа таяныч та, терәк тә булган.

Гаиләнең, балаларның язмышы Рәбига абыстайга йөкләнә. Тузгытылган, таланган хуҗалык хәрабә хәлендә була. Гаиләне авыл читендәге иске мунчага куып чыгаралар, ә өйләренә бер әтрәк-әләмне кертәләр, әмма авылдагы мәрхәмәтле кешеләр җыелып барып гаделлекне торгыза – теге килмешәкләрне йорттан куып чыгарып, мулла абзыйның балаларын һәм хатынын кире өйләренә кайтарып урнаштыра. Ачлыкка, авыруларга түзә алмыйча төпчек кыз Гөлчәчәк вафат була.

Тузгытылган, таланган хуҗалыкта алты нарасыен кочаклап ялгызы Рәбига абыстай утырып кала. Балаларына аз булса да сөт бирер, дип кырып-себереп бер кәҗә юнәтә. Әмма авылның бер юньсезе шул мәхлукны да алып китеп, үзенең ихатасына бәйләп куя. Сүтелгән каралты-кура бүрәнәләре барыбер яңа хуҗаларына игелек китермәгән, эшкә ярамаган, ахрысы. Әле алтмышынчы елларда күрше авылдан узышлый, әтинең, әнә теге тау өстендәге черегән бура безнең амбар иде, дип уфтанып куйганын бүгенгедәй хәтерлим.

Атадан бала яшь кала

«Бала атасы өчен хөкемгә тартылмас», дигән канатлы гыйбарә диктатор авызыннан чыккан һәм хакыйкатьтә чеп-чи ялган вә икейөзлек галәмәте икәнен әтиемнең тормыш юлыннан күзәтеп исбатларга да мөмкин.

Шуны да истән чыгармыйк, 1937 елның 15 августында СССР Эчке эшләр комиссары Н. Ежов «Ватанга хыянәт итүчеләрнең хатыннарын һәм балаларын репрессияләү турында» дигән боерыкны имзалаган. Әлбәттә, бу документ юлбашчы күрсәтмәсе буенча гамәлгә кергәне шиксездер.

Минем әтием Габдерәшит 1918 елның 2 гыйнварында Арча районы Гөберчәк авылында туган. Бала чагыннан ук аңа әти-әнисенә булышырга, малларны карарга, бакча эшләрендә катнашырга туры килә. Чабата үрергә дә өйрәнгән ул. Баштарак кыен шөгыль сыман тоелса да, тора-бара кулындагы юкә телемнәре «тыңлаучан»га әверелә, нәни бармаклары арасында биеп-бөгелеп кенә тора. Әмма төп эшкә керешкәнче курысның ничек барлыкка килүен укучыга аңлатып китик. Курыс – каезланмаган, юкәсе суелмаган кабык. Аны суда тотканнан соң, ул кат-кат булып куба торган булган. Шушы купкан юкәне киптереп, телемнәргә аерып чыпта, чабата ясаганнар. Әлбәттә, чабата озакка чыдамаган. Корыда тула оек яки ыштыр чорнап кигәндә, ул менә дигән җиңел аяк киеме булган, әмма яңгырдан соң юл өзегендә яланаяк йөрүең – мең артык. Чабата ясау сабырлык, пөхтәлек һәм күпмедер дәрәҗәдә үҗәтлек сорый. Бәгъзеләрнең ошбу аяк киемен үрә алмавы гаеп саналган, аларны мыскыл итеп: «Чабата да үрә белмәгән башың белән, акыл сатып утырган буласың», – дип кенә авызларын томалаганнар. Гөберчәкнең чабата ясау остасыннан бер-ике дәрес алгач, әти дә ошбу һөнәрне үзләштергән. Чабата үрү – акча эшлисе килгәннән. Авыл малае өчен аның һәр тиене бик кадерле. Яшүсмер әтисенең кул арасына керә башлагач, дөньяда әле тагын да авыррак һәм кыенрак эшләр булуына төшенә. Сука башы тоту, тырмалау, чәчү, иген игү, җир сөрү – болар барысы да ифрат тырышлык, сабырлык һәм егәрлек сорый икән. Иң җиңеле дилбегә тоту булса, иң кыены – буразнаны очлагач, сука башын тотып, атны бордыру. Кояш чыкканчы торасы, караңгы төшкәч, эшне тәмамлап, өйгә кайтасы – көн озынлыгы әнә шулайрак үлчәнгән. Әмма маңгай тирләрен сөрткән мәлдә егет үзе ачкан хакыйкатькә һаман саен ныграк инана бара: игенче крестьян хезмәте адәм баласында игелекле хисләр тәрбияли торган могҗизалы һөнәр икән ләбаса!

Әти 1930–1931 уку елында Сеҗе авылының беренче баскыч мәктәбенең 4 нче группасын тәмамлаган. Ә 1933 елда Сөнгатулла хәзрәт беренче тапкыр кулга алына.

Әти сөйләгәннәрдән: «Ни хикмәттер, Казанга Бөтенсоюз старостасы Михаил Калинин килгәч, төрмә ишекләрен ачып, байтак кына хаксызга утыртылганнарны ирекккә чыгаралар...» Әмма бу вакытта инде үсмер гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителә һәм «халык дошманы малае» дип тамгалана. Аңа белем алуын дәвам итү дә, сайлауларда катнашу да катгый тыела һәм эшкә урнашу мөмкинлеге чикләнә.

(Дәвамы киләсе санда).

Рөстәм МӘҺДИЕВ.

(“Туган җир” журналыннан).

Идегәй мирзаның шанлы көннәре

(Дәвамы. Башы 29 нчы санда).

Ярты сәгатьтән барысы да җыелды, киеренке тынлыкта ханның сүзен көттеләр:

– Бисмиллахир-рахманир-рахим! – Яшь ханның тавышы каушабрак чыкты, моны барысы да сизеп алды. – Алдыбызда торган дошман артык көчле һәм ишле, аның кинәт һөҗүм итүе бар. Безнең көчләр исә аз, анысы үзегезгә мәгълүм. Бу очракта орышка керү акылсызлык булмасмы? – дип, Тимер Котлык хан җаваплылыкны өлешчә тыңлаучылар өстенә салуны кирәк тапты. Бераз тын торганнан соң сүзен дәвам иттерде. – Без үзебез тәхеткә тугры әмирләр белән баһадирларыбызның һәлак булуын теләмибез. Шул сәбәпле кенәз Витовт белән сөйләшү башлап җибәрергә, солых сорарга кирәк дигән уйда торабыз. Кем моңа каршы?

Хан җыелган гаскәр башларына күз йөртеп чыкты. Кайтарып сүз әйтүче табылмагач, мәсьәләне үзе хәл итте:

– Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламасын!

Берничә кеше, аның зирәклеген мактап сүз әйтсә дә, күпләрнең йөзе караңгы, күзләре ханга карамаска тырыша иде. Каршы дәшәргә берәү дә җөрьәт итмәде. Барысының да уенда Идегәй мирза: «Тизрәк килеп җитсен дә шушы куркак кулыннан идарәне тартып алсын иде. Мондый түбәнлеккә төшкәнче...»

Әмма хан инде илчеләрне кенәз Витовт тарафына солых теләнергә озату өчен соңгы күрсәтмәләр бирә иде.

3

– Олуг кенәз Витовт галиҗәнаплары! Кодрәтле Тимер Котлык хан сиңа сәлам юллый, үзеңә һәм яраннарыңа саулык, илеңә-көнеңә иминлек тели, – дип башлады сүзен татар илчесе.

Кенәз Витовт ягыннан йола таләп иткәнчә сәлам кабул ителгәч, илче төп сүзгә күчте:

– Тимер Котлык хан синнән, олуг кенәз: «Ни өчен җиремә аяк бастың? Мин синең җиреңне дә, калаларың белән авылларыңны да тартып алмадым?» – дип сорый. Ул синнән җавап көтә.

Илчегә җавап кайтарганчы кенәз Витовт башта зур чатыр эченә җыелган Литва һәм Польша аксөякләренә, немец рыцарьларына, рус кенәзләренә караш ташлап алды. Татар илчесенең сүзне болай мескен башлавы аны гаҗәпкә салды. Аның уенча, татар ханы аның өстенә ярсу әтәч кебек очып кунар, гаепләү сүзләре ташлап, куркыта башлар дип көткән иде. Димәк, Тимер Котлык хан илчесен солых сорау өчен җибәргән. Кенәзнең сөенече йөзенә бәреп чыкты. Моны мәрасимдә катнашучыларның барысы да күрде, кенәзгә көлемсерәү белән җавап бирделәр. Димәк, Алтын Урданың хәлләре чыннан да мөшкел икән. Яу кузгатып ул дөрес эшләгән. Бүгенге көндә аңа каршы торырлык көч юк. Сарайның биләмәләрен тартып алса, аннан да кодрәтле хаким булмаячак. Шуңа күрә кенәзнең җавабы катгый яңгырады:

– Ходай ярдәме белән мин күп җирләрне, халыкларны яуладым. Син дә, Тимер Котлык хан, миңа угыл бул, ә мин сиңа ата булырмын. Миңа ясак түләп торырсың. Әгәр дә угыл буласың килмәсә, колым булырсың...

Бу сүзләрдән илченең йөзе, камчы белән сыдыргандай, тетрәнеп куйды. Ул бераз югалып торды да, үзен кулга алып, кенәз алдында бил бөкте һәм чыгып китте. Чатыр эченнән кенәз Витовтны котлап әйтелгән авазлар ишетелде.

Шулай ике арада илче йөрергә тотынды. Күпмедер вакыттан соң татар илчесе солыхка ризалык алып килде. Әмма кенәз Витовт бу юлы Тимер Котлык хан алдына тагын да катгыйрак таләп куйды. Ул болай диде:

– Алтын Урдада сугылган акчаларда минем исемем булырга тиеш!

Дошманның оятсыз таләбе белән илчегә кабат хан янына әйләнеп кайтырга туры килде.

4

Кенәз Витовтның яңа таләбе Тимер Котлык ханны, диварга терәп куйгандай, чарасыз итте. Аңа риза булсаң, Алтын Урда Литва кенәзлегенең бер олысына әверелә дә куя. Бу – дәүләтнең, мөстәкыйльлегенең югалту дигән сүз. Әлбәттә, Тимер Котлык хан моңа бара алмый, шуңа күрә мәсьәлә һавада асылынып калды. Ә кенәз Витовт җавап көтә, вакытны сузсаң, һөҗүмне башлавы да бик ихтимал.

Тимер Котлык хан түземсезләнеп агасы Идегәй мирзаның килеп җитүен көтте. Ул Аксак Тимернең үзен җиңгән, хәйләсе белән аны төп башына утырткан...

Менә якынлашып килүче атлы гаскәрдән җир селкенә башлагандай булды. Алда унлап гаярь җайдак тарафыннан ярым алка эченә алынган Идегәй мирза үзе бара иде. Озын аяклы җиңел атияр өстендәге төз гәүдәле җайдакны сизми дә кебек. Идегәй мирза өстендә кыска җиңле тимер тәңкәле көбә, билендә зиннәтле аел белән бизәлгән киң каеш, башында затлы очлым. Урта буйлы, нык бәдәнле, сакал-мыегына чал кергән Идегәй мирза башкалардан каратут йөзе, гайрәтле күз карашы белән аерылып тора. Гомерендә даланың җил-давылларын, кар-бураннарын, канлы орышларын күп күргән, алардан исән чыккан, акылы, зирәклеге, һәрнәрсәне алдан күреп эш итә белүе, үзен белгәннән бирле агасы киңәше белән яшәде, һәр адымы аның ярдәме белән ясалды, Сарай тәхетенә дә абзасы ярдәме белән чыкты. Ул мәмләкәтнең үзәк олысларыннан җыелган зур гаскәр белән кичә үк килеп җитәргә тиеш иде. Нигәдер тоткарланды. Килеп өлгерсә, Тимер Котлыкның өстеннән тау төшкәндәй булыр иде.

Шулай да бәхете бар икән Тимер Котлык ханның! Чатырга килеп кергән чапкын Идегәй мирза төмәннәренең Урдага якынлашуын хәбәр итте.

Бу вакыт тышта:

– Идегәй мирза килә!

– Ярдәм килә! Ярдәм!

– Бәкләрбәк ярдәмгә килә! – дигән дәртле авазлар яңгырый башлады.

Сугышчылар да, гади олаучылар, хезмәтчеләр дә, эшләрен ташлап, Алтын Урданың гаскәр башы – бәкләрбәк Идегәй мирзаны каршыларга ашыкты. Аның турында гаҗәп сүзләр йөри иде. Имеш, кешеләр белән идарә итүдә камиллеккә ирешүе аркасында хакимиятнең иң югары баскычына күтәрелгән асыл зат иде ул. Дәүләт эшләрендә дә, тормыш-көнкүрештә дә, галим-голәма белән аралашканда да вәзгыять һәм шартлар таләп иткәнчә эш йөртә, кирәксә, кешеләрне үз ягына аудара белә иде Идегәй мирза. Аңа хас төп сыйфат – кирәк чакта дөрес карар кабул итә белүе иде.

Ул атыннан төшмичә генә яугирләрне үз янына чакырып ала, аларга кыска-кыска боерыклар бирә. Тегеләр боерыкны алу белән аны үтәргә ашыга. Бу да аның абруен, аңа булган ышанычны, хөрмәтне күрсәтә иде. Зур гаскәр белән Идегәй мирзаның килеп җитүе хан урдасында бер тантанага әверелде, кәефләрне күтәреп җибәрде, төрле яктан дәртле авазлар яңгырый, моңарчы хөкем сөргән билгесезлекнең эзе дә калмаган иде.

Аңа хан тирмәсендә нинди карар кабул ителүен дә, аннан соң булган хәлләрне дә җиткереп өлгерделәр. Ул, Урданы саклаучылар янында туктап та тормыйча, бер төркем әмирләр, бәкләр белән хан чатырына якынлашты, атыннан төшеп, эчкә узды.

Бәкләр, әмирләр Идегәй мирзаны күптән көтсәләр дә, аның чатырга килеп керүе ничектер кинәтрәк килеп чыкты. Билләр бөгелде. Идегәй мирза иелгән аркалар өстеннән тәхеттә утыручы Тимер Котлык ханга күз ташлап алды да аңа таба китте. Яшь хан нидер әйтмәкче булып авызын ачкан иде, агасының ярсу йөзен күреп, катып калды, сүзе тамагына тыгылды.

Идегәй мирза бер сүз дә дәшмичә ханга арты белән борылды, тезелешеп баскан әмирләргә, гаскәр башлыкларына күз йөртеп чыкты. Йөзе яшенле яңгыр алып килгән кара болыттай иде:

– Ишетүемчә, монда кайберәүләр колак ишетмәгән мәсхәрәлеккә төшәргә – дошманнан солых теләнергә әзерләнәләр икән, – дип башлады ул сүзен. – Мин моны «мәсхәрә» дип бәялим, чөнки орышмыйча солых теләнү дала батырларын мескен хәлгә куя. Безгә ни булды? Кая азаматлыгыбыз, ирлегебез? Буынчык, сөңге очларында татар данын йөртүчеләр без түгелме? – Бәкләрбәкнең һәр әйткән сүзе, эрегән кургаштай, тыңлаучыларның миенә тама, чаң тавышыдай яңгырый иде. – Мондый мескенлекне күрсә, бабаларыбыз ни әйтер – алар оятларыннан каберләрендә әйләнеп ятар иде! Туган җиребезне күмергә әйләндергән Аксак Тимер явы сезгә җитмәдемени?

Чатырда үлем тынлыгы урнашты. Идегәй мирза күрде: кешеләр аннан күзләрен яшерә, димәк, әле өмет бар... Үзләрен гаепле саныйлар.

– Җир йөзендә иң яманы ни-нәрсә? – дип, чатырдагылар өстенә сорау ташлады ул һәм үзе үк җавап бирде: – Халык өчен иң яманы – дәүләтеңне югалту, ирекле халыкның ятлар колына әверелүе. Без моңа бара алабызмы? Юк, бара алмыйбыз! Тәхетеннән сөрелгән оятсыз Туктамыш хан монда дошманнар ияртеп килде. Алар белән берләшеп ватаныбыз Дәшти Кыпчакны, Идел-Йортны таларга җыена! Шуны читтән күзәтеп торыйкмы? Юк, тормабыз! Әллә туган-үскән, кендек каныбыз тамган шушы изге җирдә дошман хуҗа булуын телибезме? Юк, теләмибез! Ата-бабаларыбыздан мирас булып калган изге Тәхет Иле безнең бәхетебез түгелмени? Без бәхетебезне шушында таптык, абруй казандык. Дөньяда туган җирдән дә изге ни-нәрсә бар? Аны дошман кулына бирү мөмкинме?..

Бөек бәкләрбәк сөйләде дә сөйләде, әмирләрне, төмән башларын татар данына лаек булып калырга өндәде. Ул күрде: әмирләрнең, төмән башларының караңгы йөзләре акрынлап үзгәрә, аларда тәвәккәллек, өмет, ярсу дәрт чаткылары арта бара иде.

– Дошманга баш биргәнче үлем артыграк! – дип тәмамлады ул сүзен.

Чатыр эчендәгеләр аны дәррәү күтәреп алдылар:

– Яшәсен Идел-Йорт! Яшәсен бәкләрбәк Идегәй!

– Яу башы бәкләрбәккә дан!

Аннан соң Идегәй мирза, бәрелешкә әзер булырга боерып, әмирләрне, төмән башларын үз сугышчыларына озатты.

Татар урдасы, гөж килеп, хәлиткеч орышка әзерләнә башлады.

5

Бу көн тарихка урта гасырлар азагындагы иң аяусыз һәм канкойгыч сугышларның берсе буларак кереп кала. Ул 1399 елның 12 августында Днепрның сул кушылдыгы Бурсыклы суы буенда була. Бу сугыш кояшы байый баручы татар дәүләтенең гайрәтен тагын бер тапкыр дөньяга күрсәтә.

Бөек бәкләрбәк Идегәй мирза, олуг кенәз Витовт белән шәхсән очрашырга теләк белдереп, аңа илче җибәрә. Берничә сәгатьтән алар сөзәк ярлы Бурсыклы елгасы ярында очраша. Бер-берсе турында күп ишетсәләр дә, бу аларның беренче күрешүе була. Бер ярда – озын буйлы, көяз киенгән кенәз, каршы ярда – уртача буйлы, горур кыяфәтле бәкләрбәк. Ниһаять, сөйләшү башлана, күп тә үтми эшне үзара килешеп төгәлләү мөмкин түгеллеге ачыклана. Кенәз Витовт үзен инде җиңүче дип саный, чөнки сөйләшү барышында татарлар ясаган һәр чигенеш аңа Алтын Урданың көче аз икәнне раслап торды.

Хәлсез мәмләкәттән зуррак калҗа эләктереп калырга кирәк, дигән фикер аңа тәкәбберлек өсти. Идегәй мирза исә, киресенчә, мәмләкәтне Витовт белән Туктамыш талавыннан саклап калу, аны ныгыту, элекке тәртипләрне кайтаруны кайгырта.

(Дәвамы киләсе санда).

Солтан ШӘМСИ

Узган гасырның 60 нчы еллары уртасында Казан дәүләт университеты студенты Әгъзам Фәйзрахмановка Казахстан далаларындагы чирәм җирләрендә бик тырышып эшләгәне өчен ВЛКСМ Үзәк Комитетының Мактау грамотасы белән истәлек значогы тапшырыла. Бу уңайдан студентларның стена газетасында булачак галим Хуҗи Мәхмүтовның «Күкрәгендә значок, яхшы эшләгән, значит» дигән шигыре урнаштырыла. Әгъзам бу грамота һәм значок белән генә калмый, аны алда зуррак дәүләт бүләкләре дә көтә. Әмма бу значок һәм грамота, ә икенче елны «Чирәм җирләрен үзләштерү өчен» медале белән бүләкләнү тарихы Татарстан журналистикасына 60 елдан артык намуслы хезмәтен багышлаган Әгъзам Фәйзрахмановның күңелендә якты хатирә булып саклана. Хәер, бу аксакал-журналистның республикабыз халкының күркәм эшләре, күренекле шәхесләренең игелекле гамәлләре, гыйбрәтле хәлләр турында язылган меңнәрчә газета-журнал мәкаләләренә, телевидение тапшыруларына мөнәсәбәтле истәлекләрен сөйләп тә бетерерлек түгелдер.



«Күкрәгендә значок»

Сугыш елларындагы татар балаларының берсенең дә тормышы җиңел булмаган. Күп балалы гаиләдәге төпчек малай Әгъзамныкы бигрәк тә авыр була. Арча районындагы Иске йорт авылының алтын куллы балта остасы Фәтхрахман Ватан сугышына китеп баргач, әниләре Мәрьям биш бала белән торып кала. Тиздән әтиләренең сугыш кырында һәлак булганлыгы турында хәбәр килә. Әгъзамга тугыз яшь булганда әнисе дә үлеп китә. Ул Әдһәм абыйсы тәрбиясендә кала. Әгъзам башта Иске йорт авылының башлангыч мәктәбендә, аннан соң Өчиле мәктәбенә, ә 8 нче класстан – 6 чакрым ераклыктагы Субаш Аты мәктәбенә йөреп укый.

Ачлык-ялангачлыкта яшәү Әгъзамның белемгә омтылышын сүндерә алмый. Ул, 10нчы классны бик яхшы билгеләргә тәмамлап, югары белем алу нияте белән Казанга барып, абруйлы Казан университетына кабул ителә.

Тормышның кырыс сынаулары дәвам итә: Әгъзамның терәге Әдһәм абыйсы да үлеп китә. Ярдәм итәрлек кеше калмый. Ләкин Әгъзамның ятимлектә үсеп чыныккан булуы, рухи ныклыгы, уңганлыгы аңа монда да көч бирә. Ул укуын ташламый: үзе кебек үк нык холыклы студент иптәше Зиннур Гыйззәтуллин белән, төннәрен чиратлашып, университет тулай торагында кочегар булып эшли, укудан буш вакытларда елга портында баржадан, тимер юл вокзалында вагоннан йөкләр бушата, өлкән яшьтәге кешеләргә утыннарын кисеп, ярып бирә, ишек алларындагы карларын көри... Университетта әлен-салын гына йөрми, яхшы белгеч булыйм дип, күңел биреп укый. Аның тырышлыгын тарих-филология факультеты деканы күреп ала, группаларының старостасы итеп билгели. Тиздән Әгъзамны комсомол бюросына да сайлап куялар.

Укуының соңгы елларында Әгъзам журналистлык эшенә тартыла башлый: газеталарга мәкаләләр яза, радио белән дә хезмәттәшлек итә. Ул, университетны тәмамлагач, «Социалистик Татарстан» газетасының хатлар бүлеге корреспонденты булып эшли башлый. Тиздән аны бу газетаның җаваплы секретареның урынбасары итеп куялар. Күренекле журналист Шәмси Хамматов җитәкчелегендәге газетада эшләү Әгъзам Фәйзрахмановка тиз арада тәҗрибәле матбугат хезмәткәре булып җитлегергә ярдәм итә.

Көннәрдән бер көнне Әгъзамны өлкә комитетының идеология секретаре Мөзагит Вәлиев үзенә чакыртып ала да, аны республика телевидениесе редакторы итеп куярга дигән карарга килүләрен әйтә. «Минем телевидение тапшыруларын әзерләгәнем дә, караганым да юк бит», – ди Әгъзам. «Әзерләрсең дә, карарсың да», – дип кырт кисә М.Вәлиев.

Шулай итеп, газета журналисты Ә.Фәйзрахманов телевидение хезмәткәренә әверелә, аны информацияләр редакциясе редакторы итеп билгелиләр. Әгъзам яңа эштә дә, сынатмаслык итеп, бөтен көчен салып хезмәт итә. Тырышлык тиздән нәтиҗәсен күрсәтә: ул, яңа эшен үзләштереп, әйбәт тапшырулар әзерли башлый. Аңа җаваплы участок тапшыралар – республика парламенты эшен яктырту бурычын йөклиләр. Ул Югары Совет сессияләрендә, парламент президиумы утырышларында, башка җитди чараларда катнаша һәм әһәмиятле мәгълүматны эфирга тапшыра.

Тиздән Әгъзамга җаваплырак эш йөклиләр: аны иҗтимагый-сәяси тапшырулар редакциясенең баш редакторы итеп билгелиләр. Иҗтимагый-сәяси тапшырулар редакциясенә пропаганда, авыл хуҗалыгы, промышленность, информация һәм тәрҗемә бүлекләре керә иде.

Мин, ул вакытта пропаганда бүлеге редакторы буларак, шаһит: 60нчы елларда Казан телевидениесе үсеш, алга барыш чоры кичерде. Татарстан АССР карамагындагы радио һәм телевидение комитеты председателе Фаик Надыйров, аның телевидение буенча урынбасары Хәйдәр Шакирҗанов, телевидениенең баш редакторлары Итфал Ихсанов һәм Ә.Фәйзрахманов республика телевидениесе тапшыруларының, шул исәптән татар телендәге тапшыруларның да, сыйфатын күтәрү өчен зур тырышлык күрсәтте. Баш редактор Әгъзам Фәтхрахман улы инициативасы һәм ярдәме белән атналык телевизион журнал «Вечерняя Казань» һәм татар телендә «Идел» телевизион журналы чыгарыла башлый.

Ул чорда Казан телевидениесе режиссерлар Эдмас Үтәгәнов, Юрий Циммерлинг, Гали Хөсәенов, Эмиль Ключарев (композитор Александр Ключаревның улы), редакторлар Туфан Миңнуллин, Юрий Зайцев, дикторлар Айрат Арсланов, Абдулла Дубин, Әминә Сафиуллина, Рөстәм Нәбиуллин кебек талантлы язучылар, сәнгать әһелләре белән баетыла.

Ә.Фәйзрахманов Казан телевидениесендә эшләгән елларда тапшыруларның сыйфатына югары таләпләр куелды. Һәр дүшәмбе көннәрендә редакторлар һәм режиссерлар җыелып, узган атнада булган тапшыруларга, уңышлы якларын һәм җитешсезлекләрен күрсәтеп, җитди анализ ясыйлар иде. Баш редакторлар исә һәр тапшыруны, эфирга чыгарыр алдыннан, ныклап тикшерә, редакцияли, ә режиссерлар, репетиция ясамыйча, тапшыруны эфирга чыгармыйлар, репетиция вакытында исә тапшыруда катнашучыларның телләрендәге хаталарын төзәтәләр, начар сөйләгәннәрен катнаштырмыйлар иде. Хәзер исә телевидениедәге татарча тапшыруларда катнашучыларның телләрендә мәгънәви, лексик, грамматик, стилистик, орфоэпик ялгышлар күп, саф, дөрес татар телендә сөйләүчеләр аз.

Ә.Фәйзрахманов телевидениедә күңелен биреп, тырышып чирек гасыр эшли. Төп эше белән бергә төрле җәмәгать эшләрендә дә актив катнаша. Берничә ел андагы партия оешмасының секретаре дә була. Хезмәт хакы алмыйча башкарыла торган бу җаваплы эш баш редакторның күп вакытын һәм энергиясен ала.

Еллар уза тора, телевидение дә яңара, мәгънәлерәк, кызыклырак була бара. Ә.Фәйзрахмановның телевидение журналисты осталыгы да көннән-көн арта. Ул әле мондагы күнеккән эшендә күп еллар эшләгән булыр иде. Ләкин Татарстан матбугаты тормышында әһәмиятле яңалык була: Казан шәһәре җитәкчеләре, үзләренең татарча һәм русча матбугат органнарын булдырырга карар кыла, «Шәһри Казан» һәм «Вечерняя Казань» дигән абруйлы газеталар чыгарыла башлый. Куелган максатка ирешү өчен беренче шарт – аларның журналистлары югары дәрәҗәле булу. Лаеклы кадрлар сайлап алу башлана. «Шәһри Казан»ны җитәкләргә редактор итеп тәҗрибәле, кыю фикерле Хәлим Гайнуллинны билгеләп куялар. Хәлим урынбасары һәм җаваплы секретареның да үзе кебек булдыклы булуын тели. Редактор бу эшкә Әгъзам Фәйзрахмановны күндерә: Әгъзам редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь эшенә керешә. «Шәһри Казан» тиз арада халык яратып укый торган газетага әверелә.

«Шәһри Казан» газетасының Х.Гайнуллин белән Ә.Фәйзрахманов эшләгән чоры башка матбугат органнары өчен дә үрнәк булырлык. Алар, беренчедән, газеталарында эшләргә бай тәҗрибәле, күренекле язучы-журналистларны – Әхәт Гаффар, Госман Садә, Әхмәт Гадел, Вакыйф Нуриев, Габдулла Шәрәфетдинов, Таһир Нурмөхәммәтов, Айрат Садыйкларны җәлеп итеп, иҗади, көчле коллектив оештыруга иреште. Һәм бу коллектив яхшы нәтиҗәләр күрсәтеп килде: газета халыкны кызыксындырган, борчыган мәсьәләләрне кыю яктыртып барды, шаблон, трафаретлы рубрикаларны укучылар күңеленә ятарлык яңалары белән алыштырдылар. Газета коллективында әдәпле, демократик атмосфера хөкем сөрде.

«Шәһри Казан» редакциясе әйбәт кенә эшләп, газетасы яхшы гына булып чыгып килгәндә, коллективны хәвефнең кара канаты каплый. «Туры әйткән туганына ярамаган» дип, дөрес әйтә халык. Хөр фикерле, туры сүзле редактор хәер-фатыйхасы белән шәһәр проблемалары кыю күрсәтеп язылган мәкаләләр Казан җитәкчеләренә ошамый, һәм Х.Гайнуллинга эшен калдырып китәргә туры килә. Күәтле, бердәм коллектив та таркала башлый. Бераздан редакторның уң кулы булган Ә.Фәйзрахманов та «Шәһри Казан» белән саубуллаша.

Әгъзамны мәртәбәле «Мәдәни җомга» газетасы редакторы – күренекле язучы Зиннур Мансуров, үзенә чакырып алып, аңа редактор урынбасары һәм җаваплы секретарь вазифаларын башкарырга тәкъдим итә. Әгъзам Фәйзрахманов бу яңа урында да җиң сызганып эшкә керешә. Ул, редактор Зиннур Мансуров, коллегасы Газинур Моратов белән бергә, мул тәҗрибәсен, белемен кулланып, «Мәдәни җомга» укучыларына турылыклы хезмәт итә.

Ә.Фәйзрахманов «Мәдәни җомга»да нәтиҗәле, намуслы хезмәт итеп, яше олыгаю сәбәпле пенсиягә чыга. Ләкин редакция белән элемтәсен өзми, анда еш була һәм үзенең күп кенә кызыклы, әһәмиятле мәкаләләрен бастырып бара. Аның энергиясе әле «Татарстан яшьләре»нә һәм башка газеталарга язып торырга да җитә. Маршаллар пенсиягә чыкмый, диләр. Әгъзам да шулай: рәсми рәвештә лаеклы ялда саналса да, эшләвеннән туктамый. Укучылар аның язмаларын көтеп ала.

Рүзәл ЮСУПОВ,
Татарстан фәннәр академиясе академигы.

ҮЗ ИЛЕНДӘ

Казан шәһәре филармониясе солисты Рөстәм НАСЫЙБУЛЛИН башкарган җырларның күбесе Бөек җиңүгә багышлана. Ул Ватан сугышы ветераннары алдында еш чыгыш ясый. Әлеге җырчыбызның сөенечле уңышлары да байтак. Быел ул II «Яңа татар җыры» конкурсында җиңеп чыккан иде. Берничә көннән соң Воронежда узган «Весна в центральном Черноземье» IX Россия авыл хуҗалыгы югары уку йортлары студентларының конкурсында I урынга лаек булды. Рөстәм Нәсыйх улына – 28 яшь. Аның шушы һөнәренә килү тарихын барлыйк әле.

– Рөстәм, сез ничек бас-баритон тембрлы җырчы булып киттегез соң?

– Мин 1993 елда Чаллы шәһәрендә туганмын. Гаиләбездә өлкән бала – апам Регина. Әтием Нәсыйх – һөнәре буенча машина йөртүче. Әнием Зилә – медицина хезмәткәре. Миңа 7 яшь тулгач, гаиләбез Чаллыдан Норлат районындагы Кизләү авылына күченеп кайтты. Каланың шаукымы, ыгы-зыгысы әти-әнием күңеленә һич ятмаган, шәһәр тормышына күнегә алмаганнар. Әтиемә рәхмәт, ул мине V сыйныфтан алып, дүрт ел һәр көн саен Кизләүдән егерме чакрымдагы Норлат музыка мәктәбенә укырга йөртте. 2010 елны, IX сыйныфны тәмамлаганда, бер җыр бәйгесендә Гран-при яулагач, мине Әлмәт музыка училищесына укырга чакырдылар. Әмма И.Әухәдиев исемендәге Казан музыка көллияten сайладым. Имтихан көне җитте. Кабул итү комиссиясе алдында җыр башладым. Бер куплеттан соң ук: «Энем, туктагыз. Башка җырлап тормагыз, рәхмәт!» – дип туктаттылар. Мин ул чак «Әдрән диңгез»не сузган идем. Чыктым да уйланам... Аптырап калдым инде. Бактың исә, укытучылар минем тавышны бер куплет эчендә ошаткан булган икән...

Әлеге училищеда дүрт ел уку дәверендә бик яхшы укытучыларда һөнәри белем алдым. I курста – Татарстанның халык артисты, укытучы Ания Туишева, аннары Ренат Хәбибуллин классында укыдым. Тавышымны бозмадылар да, сындырмадылар да. Тавышым бер-ике ел эчендә формалашты. Бас-баритон тембрлы җырчы шулай туды.

– Аннары консерваториягә?

– Бу бит тәкъдир кебек, консерваториябездә уку – бик табигый теләк. Дөрес, мәшһүр җырчыбыз Венера Ганиева Казан мәдәният институтына да чакырган иде, әмма мин консерваторияне сайладым. Аңа керү җайлы түгел, абитуриентларны нык сайлап алалар, чөнки анда нибары җиде йөз студент укый. Ректор да, урынбасарлар да аларның һәркайсын белә, йөзенә карап таный. 2014 елда узган имтиханда бер куплет җыр башкардым. Җыйган балл буенча исемлек элеп куелгач, мин дә, авыл баласына хас тыйнаклык белән, исемлекне астан өскә таба укып менә башладым. Фамилиям дә Насыйбуллин бит әле... Тик укыган саен, күңел тынычсызлана барды. Фамилиям очрамый гына бит... Ул исемлекнең башында, беренче итеп язылган булып чыкты. Шатландым, әлбәттә, әти-әни дә сөенде. Консерваториядә сынатмыйча укырга тырыштым. Ул елларда узган барча республика, халыкара бәйгеләрдә дә катнаштым. Аннары инде гаиләм барлыкка килде, бер-бер артлы балалар туды... Тормыш алып бару өчен, концертларда күбрәк катнашыр чаклар килеп җитте. «Казан нуры» халык уен кораллары ансамбле җитәкчесе, атказанган артист Рәсим Ильясов миңа «Казан» милли-мәдәни үзәгенә солист кирәклеге хакында хәбәр итте. Анда кабул ителгәч, Бөтендөнья татар конгрессы белән хезмәттәшлек башланды. 2014 елда ук Казан филармониясенә дә эшкә алганнар иде инде.

– Ә үзегез бүген дә укыйсыз...

– Әйе. Казан дәүләт аграр университетында читтән торып укыйм. Биредәге магистратураны тәмамлап, икенче югары белем алачакмын. Аграр университет минем өчен күптәннән якын. Студентларның «Тургай» театры җитәкчесе Роберт Галиев белән даими хезмәттәшлектә идек без. Мине шушы университетта узган байтак чарага чакыралар, җырларымны яратып тыңлыйлар иде. Җырчы һөнәре тавыш халәте белән бәйле, тавышың озак елларга җитсә, бик яхшы да бит, әмма тормышта төрле хәлләр туа. Ярык тагарак янында торып калмас өчен, башка һөнәргә дә ия булыйм әле.

– Сез сугыш тематикасындагы җырларны бигрәк яратасыз...

– Чөнки алар рух күтәренкелеге белән, көчле тавыш белән җырланырга тиеш, ә минем тавышның үзенчәлеге нәкъ шундый. Бөек Җиңү уңаеннан оештырыла торган концертларны ветераннар да бик яратып тыңлый. Алар – үзгә тамашачы. Чөнки каршымда аяусыз үлем белән очрашкан, никадәр михнәт аша узган, каһарманлык кылган кешеләр утыра! Аларның елдан-ел азая баруы гына кызганыч.

– Сез кечкенәдән ватанпәрвәрме?

– Сугыш, Бөек Җиңү темасы күңелгә һәрчак якын. Репертуарымда патриотик җырлар булганга, бик дәрәҗәле кунаклар алдында, дәүләт күләмендәге мәдәни чараларда да катнашам. Шәһәр көнендә, Татарстан бәйрәме, 9 Май бәйрәме белән бәйле тантаналарда катнашам. Халыкның мондый чараларга да яратып йөрүен күреп куанам. Менә быел, 5 майда Казанның «Чулпан» мәдәният үзәгендә Бөек Җиңүгә багышланган «Сугыш ялкынында туган җырлар» дип аталган зур соло концертымны үткәрдем. Ике сәгатькә якын барган концертта «Казан нуры» халык уен кораллары оркестры, «Казан» бию ансамбле, Казан мәдәният институты хоры, җырчылар, Татарстанның атказанган артистлары Гөлшат Имамиева һәм Алинә Шәрипҗанова да катнашты. Тамашачыларым концертның атмосферасы белән бик канәгать калды.

Танылган җырчыбыз, халык артисты Гөлзадә Сафиуллинаның миңа биргән киңәше дә истә. Ул: «Энем, син халкыбызны тәрбияли торган патриотик җырларны яхшы башкарасың. Ярты юлда туктап кала күрмә, бу теманы дәвам ит, сиңа өметем зурдан!» – дип, үз теләк-нәсихәтен белдергән иде.

– Һөнәри эшчәнлегегездә сезнең өчен кемнәр үрнәк булып тора?

– Беренчесе, әлбәттә, даһи җырчыбыз Илһам Шакиров. Икенчесе - мәшһүр Иосиф Кобзон. Мин шушы ике шәхеснең талантына мөкиббән. Алар – профессиямдәге эталон. Эш бит тавыш куәтендә генә дә түгел. Беләсез булыр, Ф.Шаляпин да бит куәтле итеп җырлауны гына мактамаган. Аның «Көч - тыныч итеп җырлауда да була» дигән сүзләре дә бар. Җырланган җыр матур килеп чыгарга тиеш. Аннары һәр җырчы өчен тагын бер кагыйдә – кайнар чакта сугып кал! Тавыш көчле булган елларда күбрәк чыгыш ясарга, иҗат итәргә кирәк.

– Сез опера җырчысы булып та китә алыр идегез...

– Минем, авылда үскәндә үк, опера сәнгате хакында беләсем килә иде... Ни гаҗәп, күп кенә опера артистлары: «Баштарак опера сәнгатен, гомумән, ошатмый идем», – дип сөйли. Операларны тыңлыйм, кайбер арияләрне үзем дә башкарам, чөнки алар күңелемә ята. Ф.Шаляпин исемендәге Халыкара опера фестивалендә катнашучыларны да тыңлыйм, әмма мин бу сәнгать төрен сайламадым. Ә опера җырчылары арасыннан Хәйдәр Бигичев репертуарын үз итәм.

– Сезнең җырга сәләтегез нәселдәнме?

– Юк, гаиләдә әтием дә, әнием дә җырламый. Гомумән, миннән кала беркем дә җырламый. Балачагымда да, бәйрәмнәр үткәргәндә дә, җырлап утыручылар булмады. Минем әнием – Сарман ягыннан, ә ул якларда, ни гаҗәп, җырчылар еш туа. Бәлкем, сәбәп шуның белән бәйледер. Әнием – минем иң якын кешем, якын дустым. Ул бик сабыр холыклы. Әтием дә нечкә күңелле кеше. Аларның шушы сыйфатлары геннарымда бардыр. Аллаһы Тәгалә шундый ата-ана, апа, гаилә насыйп иткәнгә шөкер итәм.

– Профессиональ уңышларыгыз аз түгел дип беләм...

– Барысын да санау кирәкмәс. С.Сәйдәшев исемендәге вокал башкаручылар конкурсы, «Татар моңы» Халыкара телевизион яшь башкаручылар конкурсы лауреаты. Р.Ваһапов исемендәге татар җыры фестивалендә дә җиңү яуладым... Җиңүләр алда да булыр әле, иншаллаһ!

– Артист ни хакындадыр еш җырласа, тормышына да шундый вакыйганы тарта, диләр. Сезнең белән шулай булганы бармы?

– Җырның кеше аңына йогынтысы зур. Һәр җырчының репертуарында мәхәббәт хакындагы җырлар бар. Менә минем мәхәббәт хакындагы җырларымның да тормышыма тәэсире булгандыр... Без Юлия белән бик яшьли гаилә кордык. Хәзер инде кызыбыз Әмирәне, улларыбыз Әскәр белән Әнвәрне үстерәбез.

– Гадәттә, ата-ана балаларны тәрбияли дип сөйлиләр,

САНДУГАЧ

ә чынбарлыкта, балалар да ата-анага йогынты ясамый калмый...

– Шулай. Мәсәлән, мин балаларымны автомобильгә утыртып, аларның утыргычларын ныгытып куйгач, үзем автомобиль каешын элеп куярга бераз онытсам, улым мине шундук «шелтәли» башлый...

– Киләчәктә үз балаларыгызның концертларын тыңлыйсыгыз киләме?

– Минемчә, кешегә жырчы булу насыйп икән, ул барыбер шул юлдан китә. Балаларым яхшы жырлармы... әлегә белмим. Шулай да... киләсе елда Әмирә белән Бөек Жиңү көнендә, халык, ветераннар алдында бергәләп берәр патриотик жыр башкарырга килештек инде.

– Жырчы һөнәренең нинди тискәре яклары хакында әйтә аласыз?

– Минем өчен аның тискәре яклары юк. Тик шул хакта әйтәсем килә,миңа кайбер жырчыларның жыр санаулары ошамый. Безне кая да булса, ниндидер чарага чакырганда кайбер артистлар: «Мин бары тик ике генә жыр жырлаячакмын», – дип алдан ук әйтеп куя. Мин андый түгел. Әгәр дә инде концерт костюмын киеп килгәнмен икән, һәм тамашачылар тагын жырлавымны үтенәләр икән, жырлаячакмын. Жыр санап тору юк.

– Ә сезгә тавышыгыз көйсез чакларда да жырларга туры киләме?

– Бервакыт, «Фанфары Казани» фестивалендә 480 кешелек тынлы инструменталь оркестр белән берлектә, урамда уздырылган бәйрәмдә жырларга туры килде. Тән температурам 39 градус иде. Жырлап бетерү белән, туры хастаханәгә алып киттеләр, пневмония башланган булган икән. Андый чакта гади халык синең нинди халәттә булганны аңламый да, сизми дә. Нинди хәлдә жырлаганын артист үзе генә аңлый. Консерваториядә шулай өйрәттеләр: артист чыгыш ясарга тиеш икән, берничә тәүлек йокламаганмы ул, карыны ачмы, авырып торамы... барыбер билгеләнгән сәгатьтә сәхнәгә чыгарга, жырларга тиеш! Кайчак миңа да көтелмәгән мәсьәләләрне тиз арада чишәргә туры килә. Мәсәлән, берәр тематик концерт өчен жыр өйрәнергә кирәк, ә вакыт шулкадәр тар. Андый жырны үзең үк атлый-йөгерә эзләп тапмыйча ярамый...

– Һәрвакыт шатланып күрешкән артистларыгыз бармы?

– Бар. Ул – танылган жырчыбыз, халык артисты Зөһрә Шәрифуллина. Студент чакта аның житәкчелегендәге төркем концертларында чыгышлар ясадым, гастроль тормышын шунда өйрәндем. Әти-әнидән акча сорамадым, барча ихтыяжларны үзем ерып чыктым. Зөһрә апа да Сарманнан бит! Без аның белән хәзер дә һәр көн аралашып, сөйләшеп торабыз.

– Репертуарыгызда Ф.Шаляпин ижатындагы жырлар да бар. Алардан кала да сез байтак композиторларыбыз әсәрләрен, эстрада жырларын башкарып, йөрәкләребезне яулыйсыз. Ә үзегез нинди жыр-көйләр тыңлыйсыз соң?

–Милләтебезнең мәшһүр С.Сәйдәшев, Р.Яхин, М.Мозаффаров әсәрләрен жырлыйм. Рәшит Абдуллин, Айдар Фәйзрахмановлар ижатындагы жырларны теләп башкарам. Башка төр концертлар да була. Аларында инде романслар, опера арияләреннән, төрле классик әсәрләрдән өзекләр жырлыйм. Ә концертлардан ял иткән чакларда бары тик инструменталь көйләр генә тыңлыйм.

– Сез илнең күп өлкәләрендә узучы мәдәни чараларда катнашасыз, шул сәфәрләр арасыннан кайсы каланы аеруча да истә калдырдыгыз?

– Мине татар милли-автономияләре оештырган бәйрәм чараларына, зур концертларга еш чакыралар, Себер якларын да күп урадым... Илебездәге калаларның байтагы бик матур. Тик истә калганы Монголия башкаласы Улан-Батордыр, чөнки анда килеп төшкәч тә, сине Чыңгызхан мәйданы, Чыңгызхан урамы, «Чыңгызхан» кунакханәсе... каршы ала. «Бу калада тагын нинди бинага аның исемен кушарлар икән?» - дип уйга каласың хәтта.

– Рөстәм, артист нинди сыйфат һәм сәләтләргә ия булырга тиеш дип саныйсыз?

– Артист мәдәниятебез тарихын өйрәнергә, үз-үзен оештыра белергә, сәхнәне ихтирам итәргә тиеш. Репетицияләрдә даими булу, музыкаль хәтерне чыныктыру да мөһим. Жырчы башка артистны кабатларга тиеш түгел. Ә бездә нәкъ берәр жырчының сәхнәдә басып торуын, аның кул хәрәкәтләрен күчереп, хәтта аягын да аның кебек үк кәкрәйтеп жырлаучылар бар. Болай ярамый, һәр жырчы үз йөзен булдырсын... Жырчы сүзләрнең мәгънәсенә игътибар итеп, визуаль рәт тудырып, үз жаны аша үткәреп, тамашачыларга житкерә белсә әйбәт. Гомумән, практика кирәк. Чын жырчы һәрчак көйләмичә тора алмый. Менә остазым, күптән түгел арабыздан киткән Венера апа Гәрәева безне фольклор белеменә өйрәтте. Аның дәресенә кергәч, халык жырлары дәреслеген ачып куя идек тә, бер дәрес дәвамында ун-унике жырны, аларның тирәнлеген житди итеп өйрәнә идек. Дәрестән чыкканда, өстемдәге футболкам манма су була торган иде. Жырчы һөнәренә өйрәнү шундый газаплы ул! Венера апаны бик еш искә алам. Ул биргән белемнәр өчен бик тә рәхмәтлемен!

– Һөнәри офыкка күз төшергәндә, нинди яңа чаралар әзерли башладыгыз?

– Ижади планнарым житәрлек. Бу арада Рөстәм Яхинның 1954 елда ук Муса Жәлил шигырьләренә язган «Моабит дәфтәре» вокаль циклын өйрәнәм. Шуны тулысынча үзләштергәч, Жәлил шигырьләренә ижат ителгән әсәрләрне башкарачакмын. Аның «Жырларым» шигыренә язылган романс та – каһарманга чын гимн. Ә гомумән алганда, һөнәремне бик яратам, үз эшемнән канәгать. Татарстан да күңелемә якын. Миңа кайчак: «Син чит дәүләтләрдә дә жырлый алырлык жырчы бит!» – диләр. Мөгаен, андый килешүләрне дә табу мөмкин эштер, әмма мин үз илемдә генә яшәячәкмен. Кайсыдыр даһи сүзләрен кабатласак, «үз илемдә генә сандугач» мин. Үземне биредә генә бәхетле тоям.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәхәббәт лирикасында ихласлык

(Ренат Харис иҗаты мисалында)

Әдәбият белемендә, әдәби тәнкыйтьтә поэзияне акыл һәм хис шигъриятенә бүлеп карау кабул ителгән. Беренче төргә караучы шигырьләр рациональ-аналитик яки фәлсәфи-афористик фикерләүгә нигезләнүләре белән характерлана. Хис шигърияте исә хис-тойгыга, экспрессив эмоцияләргә корылуы белән аерыла. Шулай ук әлеге ике принципның үзара үрелүенә нигезләнгән синтетик шигърият төре дә бар. Анысы инде – лириканың сәнгати-аналитик фикерләү тибына корылган өченче төре.

Әдәбият белгече Нил Юзиев 1973 елда басылган «Хәзерге татар поэтикасы» дигән монографиясендә Ренат Харис иҗатын тоташы белән әлеге төркемнәрнең беренчесенә кертә, димәк, акыл шагыйре буларак таный. Сүз дә юк, поэзия мәйданына шуннан бераз алда, 60 нчы елларда аяк баскан шагыйрьнең тәүге чор иҗатында акыл-фикер бермә-бер өстенлек итә иде. Әмма моннан соңгы чорларда, образлы-эстетик фикерләвенең камилләшә һәм тирәнәя баруына бәйле рәвештә, Р.Харис шигъриятендә хис-тойгы да киңрәк урын ала барды. Дөресрәге, шагыйрь акрынлап акыл һәм хис башлангычларын бергә үрергә, аерым әсәрләрендә аларның гармоник берлегенә ирешергә өйрәнде. Бу инде – шагыйрь акыл-фикер шигъриятеннән синтетик характерындагы хисси-интеллектуаль лирикага борылыш ясауны мәгъкульрәк һәм отышлырак күрә башлый дигән сүз. Шигырь белгечләре билгеләгәнчә, Х.Туфан иҗаты да заманында акылга өстенлек бирүдән хис-кичерешләрне көчәйтү, ике башлангычны органик рәвештә бергә үрү юнәлешендә үсә бит.

Шигырьнең нинди поэтик фикерләү яки сурәтләү тибына каравы, бердән, шагыйрьнең чынбарлыкны тоемлау үзенчәлеге, психологик табигате белән аңлатылса, икенчедән, билгеле бер дәрәҗәдә темага һәм тасвирлау объектына да бәйле. Мәсәлән, җитди уйланулар яки фәлсәфи күзаллаулар сорый торган темалар акылны эшкә җигүгә мохтаҗ. Ә менә кеше күңелендә үзеннән-үзе төрле эмоцияләр һәм тирән кичерешләр кузгата торган темалар исә хис шигъриятендә аеруча тәэсирле һәм саллы булып ачыла. Шул ук вакытта әлеге төр шигырь хис-тойгыны интеллектуаль фикер белән үрү яки куәтләүгә дә юл калдыра.

Шундый темаларның иң-иң бөеге һәм изгесе, беркемне дә читләп үтми торганы, әлбәттә, мәхәббәт темасы. Мәхәббәт төшенчәсе күп ярату төрләрен үз эченә ала. Әйтик, туган җиреңне яки телеңне ярату, әти-әни яки балаңны ярату, табигать күренешләрен ярату һ.б. Бу очракта дөньяның токтасы булган ике җенес арасындагы мәхәббәт турында сүз алып барыйк.

Табигый ки, җенси яки тән мәхәббәте дигән бу ярату төре һәр шагыйрь һәм шагыйрә иҗатында, шул исәптән Р.Харис әсәрләрендә дә төрле төсмерләрдә чагыла. Ләкин сөю-ярату дигән нәрсә гаҗәеп дәрәҗәдә шәхси-интим характерда. Кешеләр бер-береннән ничек яратулары ягыннан гына түгел, ә ярату хисләрен ни рәвешле белдерүләре яки күрсәтүләре буенча да аерыла. Мондый аерма, әлбәттә, кешенең биологик һәм психологик үзенчәлеге, нинди тәрбия алуы һәм эчке культурасы белән бәйләнгән.

Ә инде шәхесләр арасындагы икенче төрле аерма – монысы, әлбәттә, турыдан-туры шагыйрьләрнең үзләренә кагыла – мәхәббәтне шигъри әсәрдә ничек, ни рәвешле гәүдәләндерүгә кайтып кала. Күп кенә шагыйрьләр сөюгә бәйле кичерешләрне «өзелеп яратам», «күңелем сиңа ашкына», «йөрәгем түрендә син», «мәхәббәтем гөле син» кебек артык гомуми яки тәме-кызыгы беткән традицион гыйбарәләр аша бирү белән шөгыльләнә. Минем үземә мондый турыдан ярып әйтүгә яки кат-кат «чәйнәлгән» өлге-калыпларга корылган шигырьләр ошамый. Алар дулкынландырмый да, истә дә калмый. Арада, билгеле, сөю-ятатуның илаһи көчен, кодрәтен аерым эпизодларга бәйләп, эмоциональ кичерешләр уятырлык итеп язылган шигырьләр дә бар. Шулай ук бу теманы фәлсәфи-афористик метафоралар яки канатлы сүзләр ярдәмендә ача торган тезмәләр иҗат итүче әдипләр дә юк түгел. Андый шигырьләр күңелдән бигрәк акылга тәэсир итә. Р.Харис иҗатында да андый тип әсәрләр бар. Шулай ук шагыйрьнең хис һәм акыл үрелүенә нигезләнгән мәхәббәт шигырьләре дә җитәрлек. Ләкин бу очракта авторның башкалар мәхәббәт лирикасыннан нәкъ менә сөюнең үзе кебек үк индивидуальлеге, кабатланмаслыгы, үзгәлеге белән аерыла һәм акылга да, күңел кылларына да көчле тәэсир итә торган мәхәббәт поэмаларына тукталыйк. Заманында кайберәүләр тарафыннан «тимер-бетон конструкцияләр шагыйре» дип нахак мөһер сугылган шагыйрьне мин әлеге әсәрләрдә яңа ягы белән ачтым.

Әсәрләргә ачкыч хезмәтен үтәүче поэма «Рәссам» дип атала. Ул - авторның беренче поэмасы. Әлеге әсәрдә кеше гүзәллегенең ялангач тән концепты яки образы аша ачылуы аеруча нык ошады. Кеше тәнен матурлык эталоны итеп иң башта борынгы греклар таныган. Мәсәлән, аларның матурлык һәм мәхәббәт алиһәсе булган атаклы Афродитаның һәм борынгы римлеләрнең шуңа охшатып ясалган гүзәллек алиһәсе Венераның бөтен дөньяны сокландыра торган скульптур сыннары үзләре үк күпне сөйли. Соңыннан ялангач хатын-кыз тәненең матурлыгы Микеланджело, Рафаэль, Тициан, Эль Греко, Рембрандт кебек Ренессанс чоры рәссамнары, Ренуар, Моне кебек XIX йөз импрессионист художникларының буяулы рәсем сәнгатендә һәм татарлардан Бакый Урманченың «Тәнкәең ак» дип исемләнгән график рәсемендә чагылыш тапкан.

Р.Харис та «Рәссам» поэмасындагы «Гүзәл тән» дип исемләнгән бүлеген, эпиграфта искәртелгәнчә, Казанның атаклы рәссамы Николай Фешинның ялангач хатын-кыз картинасы тәэсирендә иҗат иткән, «һәр төсне кырыкка яра белүче, һәр сызыкта җан хәрәкәте сизүче» рәссам образы ярдәмендә автор әлеге гүзәл тән иясенең ясалу, полотнода пәйда булу процессын җанлы итеп күз алдына бастыра. Үзе дә рәссам булган шагыйрьнең төсләр белән генә түгел, ә сүзләр белән дә сурәт ясау осталыгы менә шунда күренә дә инде. Ачыклап әйткәндә, ул кызның чибәр йөзен, коңгырт чәчләрен, ахак күкрәкләрен, алсу тәненең матурлыгын, рәсем ясаучыга ияреп, бәйнә-бәйнә тасвирлый, һәм соңыннан язылып беткән полотно алдында шаккатып калган натурщица кызның үз авызыннан мондый сүзләр әйттерә:

Йә Хода!
Киндердә тере кеше!
Тере... кеше...
Юк, юк! Анда ул түгел,
Анда – тәңгә әверелгән илаһи пакьлек,
Анда – батырлар, акыллылар,
матурлар анасы булырлык
Тиңдәшсез гүзәл!

Алай гына да түгел, хатын-кыз тәненең матурлыгын үзенчәлекле итеп күрсәтү өчен, шагыйрь хәтта су тамчыларын җанландыра һәм тәэссоратын аларның тоюы-сиземләве аша да гәүдәләндерә:

Юынды кыз – Маңгаенда ак ялтырап,
Иренендә кызыл ялтырап,
Күкрәк очларында көрән ялтырап,
Актылар энҗе тамчылар.
Актылар биленең нечкәлеген,
Бөеренең текәлеген,
Ботларының тыгызлыгын тоя-тоя,
Аңнарын җуя-җуя,
Төймә кендегенең кайнарлыгын
сизә-сизә,
Парга әверелмичә чак-чак түзә-түзә.

Антик чордан ук башланган һәм Европаның төрле чор рәссамнары иҗатында чагылыш тапкан кеше тәненә соклану традициясен менә шулай татар поэзиясенә кертеп җибәргән башка шагыйрьне белмим.

Әмма хатын-кыз тәне соклану объекты гына түгел, ярата белгән ир- атка чиксез бәхет-ләззәт бирүче һәм карынында гомерне-гомергә ялгаучы тереклек Кояшы

да. Бу хакта Р.Харис «Тәүбәсез мәхәббәт» дигән поэмасында, натурализмга бирелмичә, үзенчәлекле төстә белдерә:

Ә түй узгач!.. Бусын инде
Сөйләп булмый... Кирәкми дә –
Тән бәхетен яулау юлын
Сүзләр белән өйрәтмиләр...
Һәр кеше дә үзе белә,
Үзе саклый моның серен.
Кыскасы, алар көттеләр
Җан-агачта тере бөре.

Әйе, һәр гаиләдә ир белән хатынның якынлык кылу җимеше, һичшиксез, газиз бала булырга тиеш. Җиде ел буе зарыгып бала көткән һәм интим тормышларын да шул изге теләккә буйсындырган Мәхмүт, ниһаять, алтынчы тойгысы белән хатынының түшләрендә сөт төшкәнен сизеп ала. Шагыйрьнең үз остазы Һ.Такташ гыйбәрәсен инверсияләүгә корылган сүзләре белән әйткәндә:

Күкрәк сөте хуш исеннән
җаны-тәне аның тулы.
Ир кешенең иң югары
биеклеге – ата булу!

Баксаң, Зөбәйдә үзен өзелеп яраткан, әмма җенес орлыгы зәгыйфь булган Мәхмүтен бәхетле итү хакына хыянәткә барырга мәҗбүр булган икән, ягъни ул баласын санаториядә чакта үзен дәвалаучы табиб белән никахсыз бәйләнешкә керү исәбенә тапкан. Әмма хатын моны әлеге табиб кыяфәте белән үз иренә охшаганы өчен һәм Мәхмүте сизмәс дип эшләгән. Гөнаһ кылуына чиксез әрнесә дә, ачы һәм шатлык яшьләрен тыялмыйча, серне тишәргә кат-кат укталса да, ул ирен түбәнсетергә һәм рәнҗетергә җөрьәт итә алмый. Чөнки Мәхмүте:

Беркайчан кыңгыр карамый,
Беркайчан авыр сүз әйтми.
Ничек итеп сөя, назлый –
Хәтта эретә үзәкне. Фәрһадлар да,
Таһирлар да, Дон Жуан да аның кебек
Матур итеп кисә алмас
Ләззәт бәлешенең төбен.

Гомумән, Р.Харис мәхәббәтнең иң биек ноктасы булган якынлык кылу мотивын парнографиягә әверелдереп, бозык яки тупас төстә тасвирламый, ә нәзакәтле һәм кинаяле образлар ярдәмендә үтә үзенчәлекле һәм тәэсирле итеп бирә. Менә поэмадан шуны раслаучы тагын бер өзек:

Ә мәхәббәт йөрәкләрдә
элеккечә туа, яши,
элеккечә татлы-назлы
беренче хиснең күз яше.
элеккечә үк тартыла
кыз егеткә, егет кызга,
итәк асты фәрештәсе
элеккечә шырпы сыза
һәм кабыза Адәм, Хава
кабызган теге учакны.
Ирнең ата, кызның ана
буласы килү шул чаклы –
изге теләк! Син шуңа да
кигертәсең үз йөгенең...
Әй, Замана, нишләтәсең
мәхәббәтнең изге ямен?

Соңгы сорауга бәйләп, автор мәхәббәтнең ал-гөлдән, сөешүдән генә тормавын, ә авыр сынауларга да дучар ителүен, хәтта гөнаһ һәм алдау-йолдау белән дә уралып китүен ачып сала. Әлеге поэма шул ягы белән гаҗәеп тормышчан һәм инандыру, сабак бирү куәтенә ия дә.

Ә менә «Евнух» дигән поэмада хәзерге заманда да очрый торган кыргый гадәтнең саф мәхәббәтне харап итүе, вәхшиләрчә өзүе тасвирлана.

Аһ, беренче мәхәббәтләр!..
һәркайсысы – могҗиза!
Шуңадыр хуш исен яшьлек
гомер буйлата суза.
Барысы да беренчеләр...
Ә чыны, тормышчаны
асылда бер генә була.
Шунысы – тормыш җаны.

Буа шәһәрендә урта мәктәп тәмамлап килүче егет үзенең әти-әнисе яшәгән авылга эшкә килгән фельдшер кыз белән таныша, ике яшь йөрәк арасында ялкынлы мәхәббәт уты кабына. Болар җәен өйләнешергә вәгъдәләшә, ә аннары Казанга бергәләп институтка китәргә була. Әлеге фәрештәдәй саф, чибәр кызны – мунча кергән чагында – шул авылның сабантуйлар батыры, әзмәвердәй егет урлый. Үзенә ярдәмләшергә алынган иптәше белән лар зурлыгындагы мунчаны ниргәсеннән куптара да шәрә килеш тышка йөгереп чыккан кызны, тунына төреп һәм җигүле чанасына корбан сарыгы кебек салып, өенә алып китә. Әмма ике-өч көн дә үтми,

фельдшер кыз каядыр качып юкка чыга. Каникулга кайткан егет шушы аянычлы хәлне ишетеп үрсәләнә, тетрәнеп кала. Шулай да, ахырда бу сөйгән кызын урлаган әзмәвердән үч алу әмәлен таба. Автор аны болай тасвирлый. Бер кичне егетебез юану эзләп клубка чыга һәм, кулына гармун алып, кызларны биетергә керешә. Шунда кызган уен уртасына каяндыр пәйда булган әлеге әзмәвер килеп керә дә:

Авыл чибәрләре белән
биеп алыйм әле бер, –

дип сөрән сала. Әмма гармун шып туктый һәм уйнаучының ачуы, мыскыллы сүзләре ташып чыга:

Мин булам аның егете,
мин яшердем инанып
сафлыгына... Хатын итә
алмагансың син аны!
Синдәйләрне «евнух» диләр –
ирлеге кипкән кияү;
шушы чирен больницаларда
дәваларга оялып,
ул фельдшер кыз урлап кайткан –
и надан, и хыялый.
Ул Буа сабан туенда
тарттырган шул тамырын –
бернишләтеп тә булмый шул
чиле-пешле камырны...

Кыю Буа егете кыз урлаучыны менә шулай көлкегә калдыра, хәтта аны, ямьсез атын чыгартып, авылны ташлап китәргә мәҗбүр итә. Иң мөһиме: каһарманыбыз кавышырга насыйп булмаган тәүге ярының намусын, гыйффәтле исемен менә шул рәвешле саклап кала.

«Тәүбәсез мәхәббәт» поэмасы кебек үк, бу поэма да тормышта сирәк очрый торган үтә гыйбрәтле, әмма ышандыра һәм уйландыра торган драматик коллизиягә корылган. Әсәрдә тасвирланган Буа егетенең прототибы автор үзе булуы да бик ихтимал. Әлеге әсәрләр, һичшиксез, мәхәббәт темасын тапталмаган һәм бөтенләй көтелмәгән юнәлештә ачулары белән кыйммәтле һәм оригиналь. Темасы белән түгел, ә эмоциональ һәм фикри куәте, табигый һәм ихласый образларының егәрлеге белән укучыга көчле тәэсир итә торган менә шундый тип әсәрләр, минемчә, илаһи-романтик мәхәббәт лирикасының кырыс чынбарлык һәм драматизм белән үрелгән классик үрнәкләре булып саналырга хаклыдыр.

Р.Харисның сүз барган поэмаларына хас янә бер үзенчәлек аларның шигырь төзелеше белән бәйле. Ошбу әсәрләрнең кайберләре, мәсәлән, «Рәссам» поэмасы фикер һәм хис-тойгының табигый агышын үз итә торган ирекле шигырь төзелешенә корылган. Хәтта формаль яктан 8-7 һәм 8-8 үлчәмендә иҗат ителгән башка поэмаларда да уй-кичереш сөреше һич тә, традиция таләп иткәнчә, кырт кисеп, һәр дүртьюлык чигендә тәмамланып бармый, ә табигый сөйләм таләбенә ярашып, строфа кысаларыннан даими рәвештә читкә дә чыга. Белүебезчә, чичәннәр иҗатыннан башланган алган шигырь юлларының бер-берсенә ялганып, өзлексез чылбыр хасил итә торган строфа төрен фәндә тезем (тирада) дип йөртәләр. Димәк, Р.Харисның тотрыклы үлчәмдә иҗат ителгән икенче төр текстлары да, әнә шундый үтәли тезмә формасы белән үрелеп, асылда ирекле ритмга, табигыйлеккә омтылучы шигъри сөйләм рәвешен ала.

Әлбәттә инде, чын мәхәббәт лирикасы үрнәкләре көчле тәэсир итү белән генә чикләнми, ә хәтердә, күңел түрендә уелып кала. Ни өчен, мәсәлән, Кол Гали көчле романтикага төреп тасвирлаган Зөләйханың Йосыфка мәхәббәте, йә булмаса Кандалыйның Парау авылы чибәре Сәхибҗамалга адресланган сөю ташып торган илаһи сүзләре гасырлар буена халык теленнән төшми, хәтта җырлар белән үрелеп яши?! Чөнки алар һәркайсы мәхәббәтнең һәм шигъриятнең ямен-төмен белгән талант тарафыннан ихлас иҗат ителгән.

Әйе, әсәрләндерә, җанны өтеп ала торган мәхәббәт лирикасын тудыру өчен ихласлык кирәк. Немец галимнәре ачыклавынча, компьютер акыл эшчәнлеге белән бәйләнешле төрле операцияләр башкара алса да, шул исәптән көтелмәгән метафораларга корылган шигырь үрнәкләре тудырырга сәләтле булса да, мәхәббәт шигырьләре чыгара алмый икән. Чөнки, җаны булмагач, аңа ярату тойгысы, ихласлык – ят нәрсә. Хәер, хәтта чынлап, тирән итеп ярата белмәгән һәм шигырьне дә салкын ният белән «ясарга» өйрәнгән шагыйрьләр дә чын мәхәббәт лирикасы тудыра алмый. Чөнки автор белән укучы арасындагы күчемле бәйләнешнең күңелләрне җилкендерә торган нәтиҗәгә китерүе, һичшиксез, шагыйрьнең шәхесенә, тәэсир итү осталыгына бәйләнгән. Ә моңа көчле мәхәббәт кичерешләрен үзләре татыган эчкерсез һәм чын инсани затлар гына сәләтле.

Зөлфәт әйтмешли, әгәр шигырь укыгач, кыз белән егет үбешә икән, димәк, андый шигырь язучы шагыйрьнең яшәвендә мәгънә бар. Р.Харисның «Өч үбешү» дип исемләнгән поэмасы моңа уңышлы мисал була аладыр. Дөрес, әлеге әсәрдә мәхәббәт темасы алдагы сүз барган поэмалардагы кебек эпик сюжет белән үрелгән драматик конфликтка, тормыш-көнкүреш каршылыкларына бәйләп тасвирланмый. Чөнки әсәрнең максаты – импрессионизм алымнарына нигезләнеп, сөю-сөешүгә бәйләнешле гүзәл мизгелләр, жест-хәрәкәтләр һәм хис-тойгылар өермәсен гармоник бөтенлектә сурәтләү. Сюжетлылыктан бигрәк, төрле эмоциональ халәт үзгәрешләрен һәм яратышу күренешләрен үзара үрелдереп гәүдәләндерү. Зигмунд Фрейдның сексуаль мөнәсәбәтләрне биологик инстинктка һәм эчке аңга гына бәйләүче психоанализы белән Р.Харисның тән һәм җан мәхәббәтен сәнгати-эстетик югарылыкка күтәреп гәүдәләндерүче ялкынлы хис-тойгы хәрәкәте арасында, билгеле, бернинди дә уртаклык юк. Натурализмга бирелү очракларын исәпкә алмаганда, гашыйкларны үбештерү һәм татарны үрчетү өчен, минемчә, менә шундый эротик-эстетик рухлы әсәрләр дә кирәктер. Җыеп әйткәндә, без анализлаган поэмалар Р.Харисның гражданлык лирикасы шагыйре генә түгел, ә кушйөрәкле мәхәббәт җырчысы да булуын ышандырырлык итеп раслый.

Тагын бер өстәмә. Моннан алда Г.Кандалыйга багышланган мәкаләмдә мин Р.Харис исемен мәхәббәтне күптән җиргә төшергән әлеге шагыйрьнең традицияләрен үзенчәлекле һәм калку төстә дәвам итүче, үстерүче шагыйрь буларак телгә алган идем. Талантлы замандашыбызның югарыда анализланган мәхәббәт лирикасы, миңа калса, ике чор арасындагы менә шул иҗади дәвамлылык-күчемлелекне дә раслый. Һ.Такташ әйтмешли: «Мәхәббәт | ул үзе иске нәрсә, | ләкин | һәрбер йөрәк аны яңарта». Ә инде заман дигәннәре - бигрәк тә.

Марсель БАКИРОВ,
филология фәннәре докторы,
Татарстанның атказанган
фән эшлеклесе.

Мәдәни җомга
5 август
№30, 2022

«Ялгышлар»ны һәм язмышны

(Язучы Әхәт Сафиуллин белән әңгәмә)

– Әхәт абый, синең тормышыңда гаҗәпләндерә торган хәлләр күп. Хәтта туган җиреңнән үк башлап...

– Чынлап та, туган җиремә килсәк, мине гомер буе озата килгән «ялгыш»ларымның беренчесе ул: дөньяга әби-бабамнар гомер иткән авылда аваз саласы урында, Донбасста туганмын. Яшәү дәверендә аларны гел төзәтә килдем. Беренчесен дә: тууыма сигез ай тулгач, әти-әниемнең кулларыннан тоттым да: «Йөрмәгез монда күмер тузанын иснәп, сезнең бәхет – авылда!» – дип, җилтерәтеп, монда алып кайттым. Борынгыларның: «Хәрәкәттә – бәрәкәт», дигән сүзен истә тоткан хәрәкәтем шул Донбасс-Балык Бистәсе юлыннан башланды. (*Көлә.*) Шуннан бирле, «ялгыш»ларымны төзәтә-төзәтә, хәрәкәттә мин. Башлангыч мәктәптән соң җидееллык мәктәпле Балыклы Чүкәй юлын таптадым. Чөнки тора-бара анда да, авылыбыз Иске Арышта да ачылачак урта мәктәпләрне көтеп тормыйча туып ялгышканмын...

Өч ел биш чакрым арада йөри-йөри унбиш чакрымдагы Олы Солтан авылына йөреп укырлык көч тупладым. Тирә-як авыл балалары килеп укыган урта мәктәп иде ул. Без анда, аннары талантлы язучылар булып танылачак В.Нуруллин, М.Миншин, Казан шәһәре прокуроры булып эшләячәк М.Әхмәтшин, район хастаханәсенең баш табибе булачак Ф.Мифтахов белән бер класста укыдык.

– Юмор күзлегеннән караган ул «ялгыш»лар шуның белән беткәндер?

– Киресенчә, яңалары башланды. Урта мәктәптән соң, киләчәктә әдәбиятка алып керергә тиешле вузга керәсе урынга (шигырьләр яза идем!), Казан авыл хуҗалыгы институты ишеген ачып кердем. Мөгаен, балачагын сугыш еллары урлаган, 6-7 яшьтән әнинең кул арасына кереп, тормыш авырлыкларын кичергән «егет» буларак, киләчәктә авыл яшәешен җиңеләйтү теләге булгандырмы (әллә чираттагы ялгышыммы?), механизация факультетына кермәкче идем. Тик рус теле язмадан «икеле» алдым...

Шуннан тезелеп китте инде ул ялгышлар... Башта, сатирик Хазанов әйтмешли, «калинария» училищесы ишеген шакыдым. (Моны ничек ялгыш димисең?!) Аны төзәтергә «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газетасында эшләгән, аннары язучы булачак М.Хуҗин ярдәм итте. Мәктәптә укыганда бу газетага язгалый идем. Бер мәртәбә ул, укырга кая керүем белән кызыксынып, «калинария»гә икәнен белгәч, катгый итеп: «Ал аннан документларыңны, ир-атлар һөнәрен сайла!» дип кырт кисте. Шуннан соң ике ел техник училищеда төзелеш эшен өйрәндем. Шагыйрь Шәрәф Мөдәррис алып барган әдәби түгәрәккә йөрдем. Соңыннан Татарстан мәгариф министры булып эшләгән профессор, ул чакта, минем кебек үк, газетага язгалап торган керәшен егете Володя Иванов белән күләмле язмалар әзерләвебез истә калган. Ул министр чагында янына кергәнем бар (ул чорда түрәләр янына кереп була иде). Эше турында сорашкач, уйга калып: «Өстә дүрт мең мәктәп бит, малай!..» дип күрсенгән иде. Чиста күңелле кеше иде...

– Төзүче булып киткәч, бу «ялгыш»ыңны төзәтмәгәнсең...

– Гәрчә резин итекләр киеп ничәмә еллар төзелеш пычрагын таптап, күп борчулар кичерсәм дә, аны алыштырырга уйламадым, киресенчә, тора-бара КИСИның кичке бүлеген тәмамладым. Анда да, сиңа тагын да күбрәк йөгерергә кирәк, дип икенче курстан армиягә алдылар. Йөгертеп тә күрсәттеләр инде анда – сержантлар әзерләүче «учёбка»га эләктем. Кайбер төндә икешәр тапкыр «тревога» белән күтәргәннәре булды! Аннары – берничә чакрымлык «марш-бросок»ка! Әллә кечкенәдән эшләп үскәнгәме, әллә Чүкәй, Солтан юллары чыныктырган идеме, аларны җиңелрәк кичердем. Хәтта чаңгы һәм атыш буенча 3 нче разрядлар алдым...

Төзүче һөнәре исә - тынычсыз, авыр хезмәт ул. Әйтик, иртән эшкә җыенасың, урамда коеп яңгыр ява. Инде иртәнге ашың да аш түгел, чөнки бетонга яисә измәгә заявка бирелгән. Мондый яңгырда ничек бетон яисә кирпеч стена саласың?! Тикмәгә генә яңа төзелештә унике ел ярым эшләгән мастер һәм прораб (производитель работ) пенсиягә биш ел алдан чыкмый!

– Иҗатың шигырьләр язудан башланган, Әхәт абый. Алай да 2002 елда чыккан «Туган якның таң җилләре» дигән китабың берәндбер шигъри җыентыгың. Димәк, инде шигырьләр язмадың?

– Шигырь – күңел халәте җимеше. Үземне шагыйрь дип санамыйм. С.Ибраһимов, Ф.Хатипов, З.Гыйбадуллин, Л. Хәйретдинова, Р.Курамшин, М.Исхаков, И.Закиров кебек талантлар кайбер шигырьләремә көйләр язды. «Балык Бистәсе таңы» дигәненә көй язган Сафьян Ибраһимов һәм аны җырлаган Габдулла Рәхимкулов белән дуслашып та киттек. Алар Язучылар берлегендә узган 60 яшьлек юбилеемда да катнашты. Габдулла абый авырып торган килеш килде һәм берничә җыр җырлады. Тик бу аның соңгы чыгышы булды: икенче көнне вафаты турында авыр хәбәр килде... 2001 елда аңа багышлап «Моңлы җыр булып...» дигән истәлекләр җыентыгы әзерләп чыгардым.

Алмаз Хәмзиннең кызы Алия минем «Ничек яшәгәнмен?» дигән шигыремә көй язып, үзе үк «башкарды». Аннары ул телевидениедән дә күп тапкырлар яңгырады, аның репертуарына керде.

Күңел халәте таләп иткәндә, хәзер дә язгалыйм шигырьләр. Тик яңа җыентык итеп чыгарырга җыенмыйм – басарга әзерләп куелган проза әсәрләрем дә чират көтеп ята...

– Кайчан прозага күчтең, Әхәт абый? Беренче хикәяң кайчан язылды?

– «Аерылышканда кавышу» дигән тәүге хикәямне 1956 елда, техник училищеда укыганда яздым. Һәм тоттым да – булган бит кыю чаклар (*Көлә.*) – «Социалистик Татарстан» газетасына бирдем. Аны язучы С.Сабиров, фәлән көнне килерсең, дип алып калды. Килдем, ни әйтер, дип калтырап утырам. «Укып чыктым, хикәяң ошады, – диде ул. Аннары: «Тик... – дип дәвам итәргә җыенды. – Тик темасы буенча безнең газетага бармый. Әйдәле, диде дә «Яшь сталинчы»га төштек. «Сезгә яхшы хикәя алып килдем. Үзем укып чыктым. Менә авторы», – диде ул, миңа күрсәтеп. «Яхшы, Сафа абзый, сез хуплаган икән, басарбыз» диделәр аңа. Ул хикәя ике санда басылып чыкты. Тагын да канатланып язарга керештем, тик никтер аларны редакцияләргә шактый соң гына бирә башладым. 1980 елда фотом белән «Казан утлары»нда төзүчеләр турында язылган «Гел зәңгәр булмый күкләр» дигән күләмле хикәям басылды. Аны Төзүчеләр көнендә радиодан тапшыралар иде. Бер мәртәбә күршем мине бакчасына булышырга чакырды. Килдек тә эшләп йөрибез. Бераздан радиоалгычтан бик таныш җөмләләр ишетәм. Карале, дим, кемнеке икән соң миңа таныш бу хикәя? Баксаң, шуны бирәләр икән...

Буылып торган буа ерылды. Әйберләрем татар басмаларында еш басыла башлады. Берничә хикәям, урысчалатып, «Комсомолец Татарии» газетасында да басылды. Анда журналист, булачак язучы Ә.Мушинский белән таныштым. Җиң сызганып сатира-юмор өлкәсендә эшли башлагач, «Советская Татария» газетасында да егермедән, «Вечерняя Казань»да унбиштән артык юмореском дөнья күрде. Соңыннан «Звезда Поволжья» газетасында Чечня сугышына багышланган «Последний бой Хазбулата» дигән хикәям басылгач, мине галим, шагыйрь Н.Хисамов та котлаган иде.

1982 елда хикәя һәм повесть кергән «Язларында ялгыз йөрсәң...», 1986 елда «Онытылган вәгъдә» дигән китапларым дөнья күрде. Иҗат юлымда, Сафа абыйдан башлап, гел яхшы кешеләр очрап торды. Беренче җыентыгым «Идел» ял үзәгендә тикшерелеп, язучы Г.Сабитов аны китап итеп басарга тәкъдим итте. Тик Т.Миңнуллин каршы чыкты. Берничә көннән чылтыратып, Габделхәй абый җыентыкка аны да кертергә кушты – Туфанны анда повестьның да урын алырга хаклы икәненә ышандыра алган. Иҗат юлында язучы Б.Камаловның да ярдәме зур булды.

– Инде ике китап авторы була торып, нигә Язучылар берлегенә 1991 елда гына алындың?

– Кайчак аңлап булмаган сәбәпләр дә була икән. Барлас абый да: «Нигә Союзга кермисең инде син?!» дип гаҗәпләнә иде. Беренчедән, мин эшләвемне һәм вакыт тигән чакларда язуымны белдем, анда керү турында уйламадым да. Ул тирәдә йөрергә вакытым да юк иде: төзүчеләр хәтта ял көннәрендә дә эштә. Аннары, инде гариза биргәч тә, ул каралмыйча озак ятуының сәбәбе, бәлки, «технарь» булуымдадыр дип тә уйлыйм. Язучылар белән аралашмыйм, алар бер-берсен яхшы белә – йә бергә укыганнар, йә бергә эшлиләр, ә мин алар арасында ак карга булып күренгәнмендер. Союзга кергәнче мин, 1980 елдан башлап, сатирик буларак шактый танылган идем: юмор һәм сатирик хикәяләрем басылмаган басма юк иде! Аларны рус газета-журналлары да бик теләп бастырды, радиодан да күп яңгырадылар. Ә «Чаян»ның татарчасында да, русчасында да даими рәвештә чыгып килделәр, җыентыкларга кертеләләр... Алар бик күп җыелды, теге китаплар янына «Чаян» журналларын да өстәгәч, А.Гыйләҗев (кабул итү комиссиясенең җитәкчесе иде бугай), аларны кулына алып: «Күрегез бу галәмәт хезмәтне!» диде. Шулай итеп, Союзга «тагын бер тапкыр» керерлек сатирик әсәрләр язган идем. Шуңа күрә үземне анда хаклы рәвештә язучы-сатирик буларак алындым дип әйтә алам. Алар «Сер бирмәдек!» (1997), «Тулгана дөнья» (2000) һәм «Җиденче буын» (2006) дигән китапларыма керде.

Балык Бистәсендә узган, мине күбрәк язучы-сатирик итеп күрсәткән кичәдә аларның шактые А.Хәмзин алып кайткан театр училищесы студентлары һәм репертуарының күп өлеше минем хикәя–юморескалардан торган «Зәй утлары» театры җитәкчесе Р.Гәрәев һәм газета буенча хезмәттәшем З.Хәйруллин авызларыннан яңгырады. Анда шагыйрьләрдән Э.Шәрифуллина, В.Фәттахов һәм Р.Гарифуллинаның катнашуы да, Алмазның чыгышы да нур өстенә нур булды. Гәрчә кичә мине язучы-сатирик буларак күрсәтсә дә, анда берничә җырым да «катнашты». Якташым композитор Г.Мингалиев минем «Бер карасаң...» дигән шигыремә көй язган булган, аны музыка мәктәбе укучылары белән шунда яңгыратты.

– Иҗатыңда балалар игътибарсыз калган сыман, Әхәт абый...

– Чынлап та, алар өчен нибары юка гына ике китап яздым. Алар психологиясен белмим бугай. Алай да «Кичер мине, песием!»(2001) һәм «Актәпи һәм Сорыкай. О Белолапке и Сером» (2011) дигән ул

ТӨЗӘТКӘЛӘП...

китапларның беренчесе «Ел китабы»нда беренче урынга лаек булды.

– Үзең язучы, ә пенсиягә чыккач журналист булып эшләвең гаҗәп...

– Моны бары тик «лаеклы ял»ның һәр көн иртән эшкә барырга күнеккән кеше өчен нинди газап икәнен татысаң гына аңлап була. Аны бер-ике атна ял итүгә үк сиздем. Шуннан соң үземне кая куярга белмичә йөрдем дә хатынга: «Болай акылдан язарга мөмкин, берәр эшкә урнашырга кирәк», дидем. «Эштән туймадыңмыни әле?! – дип гаҗәпләнә. – Яз да яз иркенләп!» Тик язып булмый, моның өчен кешеләр белән аралашу, тере атмосфера кирәк. Төшемдә дә – төзелеш мизгелләре: эшчеләр белән «сөйләшәм», кран чыңнарын «ишетәм». Кешеләр арасына да чыккалап карадым, тик бу мин күнеккән «тере» атмосфера түгел. Шуннан соң бер фирмага прораб булып кердем. Тик бер-ике атна эшләүгә, «Чаян»да эшләүче язучы К.Кәримов, сине хуҗа күрергә тели, дип чылтыратты. Килдем, баш редактор Р.Зәкиев миңа шушында эшләргә тәкъдим итеп гаҗәпләндерде. «Сез нәрсә, мин төзүче бит, ничек монда эшли алыйм?!» дим. «Мондый хикәяләр язгач, эшлисең дә эшлисең!» диде ул. Шулай итеп, иҗади юлымда очраган яхшы кешеләрнең берсе булган Рәшит Зәкиев мине журналист сукмагына алып керде. Бу эштә унбиш ел гомеремне (тугыз елы «Ватаным Татарстан»да) багышлап, икенче мәртәбә «лаеклы ялга чыккан» гына идем, эшкә чакырып, «Мәгърифәт»тән шалтыраттылар. «Мин бу эшемә нокта куйдым, инде ял итәм, яшьләрне чакырыгыз», дидем. «Алай кырт кисмә килеп чык әле, Әхәт абый, сөйләшик» дип нык торгач, кышын гына эшләп торырмын, дип күнгән идем, ике ел чамасы эшләргә туры килде. Аннары якташым, С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы директоры М.Шиһапов эшкә чакырды... «Ял итәргә дә бирмисез, дип «сукрана-сукрана» анда да бераз эшләргә туры килде.

– Соңгы елларда публицистикага да күчеп алгансың, Әхәт абый. Бу хәзерге язучыларга хас күпкырлылыкмы, әллә тормыш таләбеме?

– Минем иҗатымдагы бу өлкә кичә-бүген генә башланган нәрсә түгел. Андый язмалар белән көн кадагына сугып баруым 1993 елдан бирле килә. Андый сәяси-публицистик язмаларым дүрт йөздән дә артыктыр. Аларның соңрак язылганнарын туплап, «Кая барышың, Россия?» (2017) һәм «Нишләвең бу, Россия?» (2019) дигән китапларыма керттем. Инде «Бөекме син, Россия?» дигән өченче җыентыгым да әзер. Олуг язучыбыз А.Хәлимнең миңа: «Их, синең ул язмаларны русчага тәрҗемә итеп бастырасы иде!..» дип әйткәне бар. Чөнки аларда – илдәге кешелексез, түбән дәрәҗәдәге тормыш-яшәешебез сурәтләнә. Алар турында язмыйча түзеп булмый. Гәрчә ул шагыйрь Ф.Тютчев тарафыннан 1848 елгы француз революциясеннән курыккан патша Николай I һәм даирәсенең илне Европадан аеруны, рус җәмгыятендә «аерым юл» формалаштыруны күздә тотып бирелгән яшерен заказ белән язылса да, бер шигыренең «Умом Россию не понять» дигән юлын тикмәгә генә еш искә алмыйбыз, чөнки ул бүгенге Россияне күздә тотып язылган сыман: юлсызлык, кешесез калган җимерек авыллар, ярлылык һәм шул фонда ил финансының яртысы диярлек 500 гаиләдә тупланусы, авыл хуҗалыгының 5 агрохолдинг олигархлары кулында булуы... Бүген без араларын тирән упкын аерган ике – байлар вә ярлылар Россиясендә яшибез. Тик беркем дә аңлый алмый бу парадоксны...

– Син тәрҗемә белән дә шөгыльләнәсең, бу аерым өлкә бит...

– Тәрҗемәгә В.Шукшин әсәрләре аша килдем. Аның хикәяләре укып туймаслык! Берничәсен тәрҗемә итеп, «Яшисе килә» дигән китап чыгардым. Иҗатның бер төре ялыктыра башласа, ял итү өчен, башкасына күчә торган гадәтем бар. Аннары Ә.Мушинскийның «Һаваларда – ак күгәрчен» романын тәрҗемә иттем, ул «Казан утлары»нда да басылды, китап булып та чыкты. Без аның белән «Казанский альманах» журналы өчен татар язучыларының шактый әсәрләрен, шул исәптән, Т.Миңнуллинның берничә хикәясен тәрҗемә иттек (алар аның «Незаконченный монолог» китабына да керде). Шулай ук Әхәт белән «Устами татарского народа» дигән җыентык (2007) төзеп чыгардык. Инде берничә ел нәшриятта күп вакыт һәм көчемне алган хезмәтем – бурят халык язучысы И.Калашниковның Чыңгызхан турындагы «Жестокий век» романының тәрҗемәсе ята.

– Бүгенге әдәбиятны ничек бәялисең: үсештәме ул, торгынлыктамы? Телебез язмышы киләчәгеме ничегрәк кузаллыйсың? Хәзер газета-журналларның тиражы да борчу тудырырлык бит...

– Мин хәзерге әдәбиятны үсештә дип саныйм: күләмле роман, повестьлар да язылa, сирәк вә аз тираж белән булса да, китапларыбыз да басыла. Ә рустан башка милләтләрне, шул исәптән татарны да, явыз рәвештә, хәтта ил Конституциясен дә санга сукмыйча кешелексез, бернинди халыкара хокук кысаларына сыймый торган шовинистик урыслаштыру сәясәте алып барылган хәзерге чорда, һәммәбезне алда ни булачагы борчый. Мәктәпләрдә телебезне факультатив рәвештә өйрәнүгә генә кала икән, димәк, тора-бара татар укучыларыбыз да, вузларда телебезне укытырлык укытучыларыбыз да әзерләнмәячәк, ә туган телебездә язучы әдипләребез буыны китә барган саен милли язучыларыбыз да, журналистларыбыз да калмаячак. Тик әле телебез берникадәр вакытка, әйтик, хәзерге һәм әле татар мәктәп-вузларында белем алган буын яшәгәндә, сакланыр. Ә аннары аны фаразлау да куркыныч. Әлбәттә, талантлар киләчәктә дә булыр, әсәрләр дә язылыр, тик инде алар татар телендә булмас... Әгәр киләчәктә Россиянең милли мәгарифкә карашы, сәясәте үзгәрми икән, безне хәзер мәчетләрдә, төрле үзәкләрдә ачыла торган татар телен өйрәнү курслары гына коткармаячак. Мин аларның ачылуын хуплыйм, алар телне саклауда роль уйнар. Тик әдәби тел булуын тәэмин итә алмас. Хәзер тел мәсьәләсе турында борчылып күп сөйлибез, язабыз. Бу аңлашыла да, чөнки тел беттеме, милләт тә юкка чыгачак дигән сүз. Матбугатта кайбер галимнәребез киләчәктә дәүләтчелегебез дә булачак дигән оптимистик фикерләр дә әйтә. Ничек? Кайчан? Нинди очракта? Җавап бирелми. Аларны укып: «Бирсен Ходай!» дип куям. Кем белә, бәлки, безгә, чигенә-чигенә, бер яклы толерантлык күрсәтә-күрсәтә шушы көнгә калуыбызның зур ялгыш булуын исбатлап шундый көн дә килер. Дөнья бик үзгәрүчән бит ул! Әйтик, СССР дигән империя таркалачак, дип әйтергә җөрьәт иткән кешене, юләргә санап, психлар йортына салырлар иде. Алда ни буласын хәтта ил җитәкчеләре дә әйтә алмый. Без шушы хәлдә дә телебезне саклау мәсьәләсендә, паникага бирелмичә, барыбыз да кулдан килгәнне эшләргә тиеш. Тик, кайберәүләр хыялланганча, телне үстерү белән шөгыльләнергә генә кирәкми, чөнки ул зур үсешкә ия, аны куллана белергә һәм чистарта барырга гына кирәк.

Әңгәмәдәш –
Рамазан КӘБИРОВ.

Айга карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

6 август (шимбә). ***Мөхәррәм аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 14.34 сәгатьтә калка, 22.15 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.43 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Өйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Баллы карлыган

Бавыр авыртканда, 1 кг кара карлыганга шулкадәр үк бал кушалар да, яхшылап болгаталар, бер тәүлек тә калдырмыйча, көненә 3-4 тапкыр 1әр чәй кашыгы кабалар.

7 август (якшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 16.08 сәгатьтә калка, 22.41 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.39 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

Кан тамырларының варикоз киңәюе

Сәбәпләре: 1) Аяклардан менгән кан тамырларының киңәюенә бавыр сәбәпче. Бавыр тыгылса, корсак асты кан тамырларында басым күтәрелә, тамыр тышчалары кабара; 2) Утырып озак эшләгәндә кан өскә таба начар күтәрелә, шунлыктан кан тамырлары тышчасы йомшара, формасын үзгәртә; 3) Дөрес тукланмаганда, кан ойый һәм тамырларда начар хәрәкәт итә, тыгыла. Варикоз киңәюдән котылу өчен, бавырны чистарту, күбрәк җәяү йөрү, аякларга эш бирү, төрле күнегүләр ясау, яшелчә-җимеш соклары эчү, майлы ризык кулланмау, төнгә ач карынга яту файдалы. Аякларны югары куеп ятарга кирәк, бер урында озак басып йә утырып торырга ярамый.

8 август (дүшәмбе). ***Мөхәррәм аеның 10 нчы көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 17.35 сәгатьтә калка, 23.24 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.34 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

9 август (сишәмбе). ***Мөхәррәм аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 18.44 сәгатьтә калка, 0.32 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.30 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

Керән суы

Геморрой интектергәндә, вак угычта уылган 1 аш кашыгы керән тамырын эмальләнгән кәстрүлдәге 300 мл суда кайнатып чыгаралар, плитәдән алып, яхшылап төреп, төнәтәләр. Сөзеп, шешәгә тутыралар һәм суыткычта саклыйлар. Көненә 3 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1әр аш кашыгы эчәләр. 1 литр керән төнәтмәсен эчеп бетерүгә үк, геморрой юкка чыга.

10 август (чәршәмбе). ***Мөхәррәм аеның 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 19.29 сәгатьтә калка, 2.03 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.26 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Аяк табаны ярылса

Чистартылмаган көнбагыш мае һәм уылган кишерне тигез микъдарда кушып, 2 көн буе караңгы урында төнәтәләр, аннан соң ярылган табанга сөртәләр. Яки 50 г төз тәпичә (лапчатка) үләне тамырын ваклап, ярты стакан атланмайга салалар, сулы савытка утыртып, 8-10 минут пешерәләр, суынгач, җәрәхәтләнгән урынга сөртәләр.

11 август (пәнҗешәмбе). ***Мөхәррәм аеның 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 19.57 сәгатьтә калка, 3.42 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 15.23 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Бүген кеше үз нәфесенең теләк һәм коткыларына бигрәк тә бирешүчән.Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Сеңер тартылганда

1 аш кашыгы балга әз генә аш серкәсе кушып болгаталар да, шуны кәбестә яфрагына сылап, авырткан урынга куялар, өстеннән җылы шәл урыйлар. Авырту йоклап торганчы басыла.

12 август (җомга). ***Мөхәррәм аеның 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 20.14 сәгатьтә калка, 5.22 сәгатьтә бата. 4 сәгать 35 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 15.18 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Дулкынландыргыч очрашулар булырга мөмкин. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Алма кагы

Ачы алманы чистартып, бераз су кушып, йомшарганчы пешерәләр. Тимер челтәрле иләктән сыттырып чыгаралар. 1,5 кг алма боламыгына 1 кг исәбеннән шикәр кушып, пешәргә куялар, агач кашык белән гел болгаткалап торалар. Тәлинкәгә тамызып суытып карыйлар: әзер как желе куелыгында булырга тиеш. Ут өстеннән алыр алдыннан әз генә лимон кислотасы кушалар. Җылы какны тыгыз тукымага сылап, өстенә пергамент каплап суыталар, аннары шикәр сибәләр. Ике катлап төреп куйгач, как шул шикәрне үзенә сеңдерә һәм тәмләрәк була.

(Ахыры. Башы 29 нчы санда).

Саран һәм юмарт

Бер хатын бай сәүдәгәргә кияүгә чыккан. Иренең зур кибете булган, анда тукымалар һәм кием-салым саткан, әмма үзе гаять саран булуы белән аерылып торган.

Беркөнне ул үзенә тавык сатып алган һәм хатынына кичкә тавык шулпасы пешерергә кушып калдырган. Өстәл артында кичке ашны ашап утырган чакта өй ишеген шакыганнар. Сәүдәгәр барып ишекне ачкач, анда бер ярлы кеше, үзенең ач булуы турында әйтеп, аңардан ашарга сораган. Сәүдәгәр аны бик каты сүккән. Теләнүче аңа әйткән:

– Сине Аллаһ кичерсен, әгәр ач булмасам, бу ишекне шакылдатмаган да булыр идем, – дигән. Сәүдәгәр ач кеше алдында йорт ишеген шап иттереп ябып куйган.

Яңадан өстәл артына ашарга утырган. Хатыны аңа:

– Нигә син соранган кеше каршында ишекне шапылдатып яптың? – дигән. Ире начар сүзләр әйтеп сүгенгән.

– Тавыкның канатларын гына бирсәң дә бик шәп булыр иде, – дип әйткән хатыны.

– Мин һәр хәерчегә тавык канатлары өләшергә тиешмени? – дип кычкырган сәүдәгәр. Хатыны аңа:

– Һич югында җылы сүз булса да әйтергә кирәк иде аңа, – дигән.

Берәр атнадан соң, сәүдәгәр үзенең кибете янына килсә, янгын чыгып малының янып беткәнен күргән. Бернәрсә дә калмаган: тукымалар, затлы киемнәр – барысы да күмергә әверелгән. Кибетнең янган бүрәнәләре генә калган.

Сәүдәгәр өенә кайткач, кибетенең янып бетүен, көле генә калуын әйткән. Хатыны бу хәлләргә артык кайгырмыйча: “Аллаһ бәрәкәт бирүче дә, алучы да”, – дигән.

Сәүдәгәр аңа бик ачуланып:

– Син ул Аллаһтан көтеп утыр әле, ул кайчан бирер. Бар әниең янына кайтып кит, – дигән һәм хатынын аерып куып җибәргән.

Әмма аерылган иманлы хатынны Аллаһ ташламаган, ул башка кешегә кияүгә чыккан. Яңа ире ярлыларны кызгана, юмарт, шәфкатьле була.

Беркөнне алар кичке ашны ашап утырганда ишек шакыйлар. Хатыны барып ишекне ача һәм соранып йөрүчене күрә. Аның азык һәм су сораганын иренә барып әйтә. Ире аңа:

– Безнең икебезгә бер тавык җитә, бер тавыкны аңа бир. Безне Аллаһ үзенең нигъмәтләре белән бүләкләде, шуңа күрә ярлы-мескеннәр хәленә кермичә, Аллаһ алдында оятлы булмыйк, ди. Яңадан өстәл янына ашарга утыралар. Хатынның күзләреннән яшьләре ага, моны күреп, ире аңардан сәбәбен сорый. Бераздан хатыны күз яшьләрен сөртеп, иренә әйтә:

– Бу хәерче кеше – минем беренче ирем иде, – ди. Ире хатынына:

– Ишекне шакып, ашарга сораган кеше синең ирең булса, ул минем алдымда шапылдатып ишеген япкан иде, – ди.

Хикәятләр



Яхшы ир

Бервакыт мөселманнар казые янына Сәрия исемле бер хатын килә. Ул казыйга түбәндәге сүзләрне әйтә:

– Ике ел элек миңа ирем белән сез никах укып өйләндергән идегез. Әхәзер безне аер, аны күрәсем дә килми, аның белән яши алмыйм, -ди.

– Аерылышу өчен сәбәпләрегезне аңлатып күрсәтегез, – дип әйтә казый хатынга. Сәрия сөйли башлый:

– Барлык кешеләрнең ирләре эштән кайткан, ә минеке һаман соңга кала. Шуның аркасында һәр көн ызгыш-талаш.

– Төп сәбәбе шул гынамы? – ди казый.

– Шундый кимчелекле кеше белән яшисем килми, – ди Сәрия.

– Әлбәттә, мин сезне аера алам, әмма бер шарт белән, – ди казый. – Хәзер өенә кайт һәм миңа зур гына тәмле икмәк пешереп кил. Өегездәге ризыкларны кулланма. Суны, онны, тозны күршеләрдән алып тор. Ни өчен аерылганыңны һәрберсенә сөйләп бир, – дигән имам.

Сәрия өенә ашыгып кайткан да, бу эшләрне озакка сузмыйча, суга дип күршеләренә кергән.

– Гайшә, миңа ярты чиләк су биреп тор әле, – дигән.

Күрше хатыны сәбәбен сораган:

– Сезнең коегыз бар бит, суы беттеме әллә? – дигән ул.

Сәрия барысын да сөйләп биргән. Шуннан соң Гайшә үзенең иренең яманлыгы, тәртипсезлеге, уңмаганлыгы турында сөйләргә тотынган...

Сәрия икенче күршесенә Гафияләргә тоз сорарга кергән. Казый кушканча сөйләп биргән.

Гафия сүз алган:

– Әле син минем иремне белмисең, ул соңга калып кайту гына түгел, кайвакыт иртә белән генә кайта, – дигән.

Сәрия аннары он сорарга Асияләргә кергән. Хәлләрне сөйләп биргәннән соң, Асия аңа он салып биргән һәм ярты сәгатьләр чамасы ирен яманлаган...

Кәч-хәл белән күтәренеп өенә кайтып кергәч, мич ягып, камыр ясап, зур тәмле икмәк пешергән.

Иртән Сәрия икмәкне чиста зур сөлгегә төреп, мәчеткә казый янына киткән. Хәзрәт белән исәнләшеп зур тәмле икмәкне аңа рәхмәт әйтеп сузган:

– Хәзрәт, өйдә гаиләгез белән тәмләп ашагыз, аерылмаска булдым әле мин. Ирем тирә-күршеләрдәге барлык ирләрдән дә иң яхшысы икән, шуны аңладым, зур рәхмәт, – дигән Сәрия.

Коръән уку

Бер мөселман карт, иртән һәр көнне тәһарәтләнеп, Коръәнне кулына алып, сүрә-аятьләр укыган. Бабасына охшарга тырышып, шулай ук һәр көнне Коръән укыган оныгы аңа:

– Мин дә синең кебек һәр көнне Коръән укыйм, ләкин аның әчтәлеген аңламыйм. Укыганнары да китапны ябу белән онытыла. Шулай булгач, Коръән укудан нинди файда бар соң? – ди.

Мичкә күмер тутыручы бабай туктап куйды һәм оныгына әйтте:

– Әнә күмер ташый торган кәрзинне ал да, елгадан шуңа тутырып су алып кайт, – диде.

Малай ничек кенә тырышмасын, өйгә кайтып җиткәнче кәрзиндә су калмый, түгелеп бетә. Бабай, көлемсерәп, малайга:

– Син бик әкрен йөрисең, кызурак йөгер, – ди. Малай бар көченә йөгереп барып кайтса да, кәрзиндә су калмаган була, хәле бетеп ава һәм бабасына:

– Кәрзин белән су алып кайтып булмый, хәзер чиләк белән су алып кайтам, – ди. Бабасы аның бу сүзләренә каршы килә:

– Мин суны чиләк белән алып кайтуыңны теләмим, кәрзин белән алып кайт, – ди.

Малай тагын бер тапкыр буш кәрзин алып кайта.

– Бабай, башка бармыйм, бу файдасыз, – ди оныгы.

– Ничек файдасыз булсын, ди бабай, – кәрзингә кара әле. Тышы да, эче дә нинди чистарды, аның белән күмер ташыйбыз бит, – ди.

Бабасы оныгына аңлата:

– Син Коръәнне укыган саен, шушы кәрзин кебек калебең чистарачак. Укыганыңның мәгънәсен аңламасаң да, Аллаһ синең калебеңне тышыннан да, эченнән дә чистартачак. Аллаһы Тәгалә безнең тормышыбызны шулай яхшы якка үзгәртә.

Нияз БИШБАЛТА туплады.

Борынгылар әйткән сүзләр

(Мәкальләр һәм әйтемнәр)

Хуҗи МӘХМҮТОВ

НУХ ЗАМАНЫННАН КАЛГАН

Бик күптәнге хәлләр-вакыйгалар, озак торудан тузып-искереп беткән, яраксызга әйләнгән нәрсәләр турында көлеп йә тәнкыйтьләп әйтелә торган гыйбарәләр.

«Хатын-кызга чуар чүпрәк кирәк –
Нух заманында да шулай булган». – *(Гамил Афзал. Август йолдызлары).*

«Мөгълифә. Менә бер яхшы алтын алка бар. Үзе бик яңа. Иясе акча кирәккә генә сата.

Сәрвиҗамал. И әби! Бу алкаң Нух заманындук булгандыр, күптән мудыдан чыккан нәрсә бу. Кайда, башка берәр чибәррәкләре юкмы?» *(Галиәсгар Камал. Әсәрләр: өч томда).*

«Пароходтан чыгучы шома, ак киемле, шат кыяфәтле чит милләтләр арасында тетелеп беткән пычрак киемнән, каешланган төксе бүрек астында Нухтан калган түбәтәй кигән ... татар күрдем» *(Шәехзадә Бабич. Зәңгәр җырлар. – Казан, 1990. – Б. 367).*

Бу гыйбарәләрнең мондый мәгънәләре ничек хасил булганлыгы ачык аңлашыла. Чөнки Нух - Аллаһы Тәгаләнең иң әүвәлге, димәк ки иң борынгы заманнарда яшәгән пәйгамбәрләреннән берсе. Коръәндә аңа 28 аятьтән торган махсус «Нух» сүрәсе багышланган, моннан тыш, аның тормышы һәм эшчәнлеге хакында тагын 30 га якын сүрәдә искә алына.

Раббысы Нухны Адәм галәйһис-сәламнең уллары Кабил һәм Шис токымнарын иманга өндәргә җибәрә. Ләкин алар потларга табыналар, Нухның вәгазьләренә колак салмау гына түгел, аның үзен гел кыйнап, җәберләп торалар, ташлар белән бәреп газаплыйлар. Кайчакларда ул хәтта таш өеме астында күмелеп кала. Кавеме «инде үлде» дип китеп баргач, Җәбраил фәрештә пәйгамбәрне ташлар эченнән аралап ала да, балалары, паласка куеп, аны өйгә алып кайталар. Таң атканчы Хак Тәгалә сихәт һәм сәламәтлек биреп, Нух икенче көнне яңадан вәгазьгә керешә. Күп еллар буе шушы хәл дәвам итә, кыйнау-җәзалаулар көчәя, иман китерүчеләр һич тә артмый. Ахыр чиккә килеп җиткән Нух гаҗизлектән дога кыла («Камәр» сүрәсе, 10 нчы аять): «Мин җиңелдем, и Раббым, миңа ярдәм бир, алардан үч ал», – ди. Хак Тәгалә догасын кабул итеп әйтә: «Миңа золым кылучылар барысы да суга батучылар булырлар, минем ярдәмем белән бер көймә ясa», – ди.

Көймә әзер булгач, Нух иман китергәннәрнең барчасын, шул җөмләдән хатынын, өч улын, килениәрен көймәгә җыя, нәселләре бетмәсен өчен барча җанварлардан, кош-кортлардан берәр парны да үз янына ала. Шуннан соң кырык көн һәм кырык төн күктән яңгыр ява, аның һәр тамчысы тегермән ташы чаклы була, җирдән ташып-ташып сулар чыга, ул иң биек тау башына кадәр менеп житә. Нух көймәсендәге җан ияләреннән башка, җир йөзендә бер генә тереклек тә калмый, суга батып гарык була. Ә җир йөзендә бүген яшәүче барлык расалар һәм халыклар Нухның су басканнан, ягъни туфаннан котылып калган уллары Хам, Сам, Яфес нәселләреннән таралганнар, ди.

Галимнәр, дөньяны су басу турындагы дини риваятьләрнең нигезендә реаль вакыйгалар ята, дип саный. Шушы хактагы махсус әдәбиятны җентекләп өйрәнгән Адлер Тимергалин язганча, Шумерда (Икесу төбәгендә – Месопотамиядә) моннан 5000-6000 еллар элек дөрестән дә гадәттән тыш көчле су басу булган. Шумер чорындагы Зиасудра дигән патшаны Нух белән тәңгәлләштерү дә бар икән. Бу сөйләгәннәр барысы да Нух пәйгамбәр заманының, чыннан да, бик борынгы булганлыгына тагын бер кат ишарәли.

СӘФӘР БЕЛӘН СӘКАР АЕРМАСЫ – БЕР НОКТА

Аңлашыла ки, бу гыйбарәгә «сәфәр» (юл йөрү) белән сәкарнең (тәмугның) аермасы бер нокта кебек кенә, ягъни бик кечкенә» дигән мәгънә салынган.

Телебездә тормыш-көнкүрештәге бик авыр, түзеп булгысыз шартларны «тәмуг газаплары» дип атау еш очрый. Әлбәттә инде, андыйлар исәбенә мөсафирларга кичерергә туры килә торган күптөрле михнәт-интегүләр дә керә. Бу хакта безнең мәкальләребез бик ачык сөйли:

Юл газабын йөргән белер.
Юл газабы – гүр газабы.
Йөрмәгән-күрмәгән – энә күзеннән үтмәгән.
Юл уравын белмәгән юлда елап утырыр.
Җитә алмаган җир тырнап елар.
Юл адашканга эт өргән тавыш былбыл тавышыннан татлырак.

Менә мондый күпсанлы мисаллардан күренгәнчә, «сәфәр» белән «сәкар»нең, газап чыганаклары буларак, аермалары чыннан да зур түгел. Әмма ни өчен ул аерма бер нокта гына? Дөрес, ноктаның «күренер-күренмәс кенә, бик кечкенә» дигән күчерелмә мәгънәсе бар барын. Ләкин канатлы гыйбарәләр туганда, аларның текстларындагы сүзләр иң башта туры мәгънәләрендә алынанлар бит.

Мондый закончалык бирелә дә саклангән икән. Элекке гарәп графикасы белән язганда, «сәфәр» белән «сәкар» аермасы – чыннан да тик бер нокта. Сузык авазларны белдерүче хәрефләр бу сүзләрдә язуда бөтенләй күрсәтелми; «с» һәм «р» хәрефләре ике сүздә дә бар; «ф» һәм «к» (къ)га килсәк, аларның да тышкы формалары (конфигурацияләре) бер үк. Бары тик беренчесенең өстенә – бер, икенчесенекенә – ике нокта куелган. Димәк, ике сүз арасындагы (төгәле: аларның гарәп графикасы белән язылышындагы) аерма нәкъ менә бер ноктадан гыйбарәт була.

Күзәтелә торган гыйбарә билгесез ерак җирләргә хәвефле сәфәргә җыенучы берәр кешене бу ниятеннән баш тартырга, үзе теләп тормышын куркыныч астына куймаска өндәп үгет-нәсихәт биргәндә кулланыла. Ул күбрәк борынгы әдәби ядкярләрдә очрый. Мәсәлән, VIII гасыр гарәп язучысы Ибн әл-Мөкаффагның бөтен дөньяга таралган һәм татар халкы тарафыннан да яратып укылган «Кәлилә вә Димнә» китабында Карга һәм Карчыга баласы турында мондый гыйбрәтле хикәят бар. Аның төп эчтәлеге түбәндәгечә:

Әти-әнисе өйдә юк вакытта бер нәни Карчыга биек оядан егыла. Шуннан очып барган бер Карга, кошчык җиргә төшмәс борын, аны тотып кала һәм, бик кызганып, үз оясына алып кайта, үз баласыдай күреп тәрбияли. Карга оясында, карга балалары арасында үссә дә, бераздан яшь Карчыга үзенең нәселдән килә торган сыйфатларын сизә башлый: аның биектән биеккәрәк, ерактан ераккарак очасы, бөтен дөньяны тамаша кыласы килә. Бу хакта ул «әнисенә» дә сөйли. Бичара Карга, сөеклесеннән аерылу сүзен ишеткәч, хәсрәтләнеп әйтә:

– И күзем нуры, балакаем! Бу нинди буш хыял тотасың вә нинди урынсыз сүз сөйләп, ялгыш уй вә ният итәсең. Сәфәр белән сәкар бер-беренә шулкадәр якындыр, аермасы бер генә ноктадыр. Әгәр сәфәргә бераз гына кара төшсә йә бер яман чебен пычратса, хәзер үк сәкар буладыр...

СӨЛӘЙМАН ҮЛДЕ, ДИЮЛӘР КОТЫЛДЫ

Бу гыйбарә, мәкаль сыйфатында, Нәкый Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыелмасында теркәлгән. Аңа «диктатор үлеп, кемнең дә булса эшенә комачау калмауга мисалдан» дигән искәрмә дә бирелгән. Инде гыйбарәнең әдәби әсәрләрдә кулланылышына килсәк, моның бер борынгы үрнәген Мәҗлисинең «Кыйссаи Сәйфелмөлек» китабында очратабыз. Анда кяфер диюләр шаһзадәсе Әсвад авызыннан мондый сүзләр әйттерелә (Казан, 1898. – Б. 43):

«Сөләйман үлде, диюләр котылды,
Аның дәверәдә күп госса (кайгы-хәсрәт) йотылды».

Ихтимал, гыйбарә Мәҗлисинең үз сүзләре булып, халык теленә ул әлеге китап аша кереп киткәндер (бу әсәр революциягә кадәр татарлар арасында бик популяр булган). Ә аның төп чыганагы – Сөләйман пәйгамбәр турындагы дини легендаларда. Коръәндәге «Сәбә» сүрәсенең 12-14 нче аятьләрендә болай диелә:

«Без җеннәрдән бер таифәне (төркемне) Сөләйманга хезмәт итәргә бирдек... Ул җеннәр, Сөләйман теләгәнчә, биек-биек өйләр ясый иделәр.

Сөләйманның, Без билгеләгән гомере беткәч, мөнбәрдә басып торганы хәлдә җанын алдык. Аның үлгәнен Аллаһ җеннәргә дә, кешеләргә дә белдермәде, мәгәр үлгән хәлдә таянып торган таягын кортлар ашап өзгәч, ул җиргә егылды... Әгәр җеннәр яшерен нәрсәне белә торган булсалар, әлбәттә, Сөләйманның үлгәнен белер иделәр һәм, аның үлгәнен белгән булсалар, әлбәттә, авыр эштә бер ел буена кыйналып эшләп ятмаслар иде. Чөнки Сөләйман, үлгәч, таягына таянып бер ел торды, җеннәр, безгә карап тора, дип, һаман эшләделәр, егылгач кына, «котылдык!» дип качтылар».

Шушы мотив борынгы татар прозасына да үтеп кергән. Нәҗип Нәккаш Исмәгыйль әзерләп дөньяга чыгарган «Гыйбрәтле хикәятләр» җыентыгында «Киләчәкне җен дә белми» исемле бер хикәят бар (Казан, 2004). Галим аны Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты мирасханәсендә (ф. 39. -№ 3274) саклана торган кулъязма буенча китерә. Ядкяр Мөхәммәдгали мулла Хәбибулла углы тарафыннан Чирүче иле (Саба төбәге) авылында дамелла Хөснетдин бине Гомәр әл-Бистәви мәдрәсәсендә 1849 елда күчереп язылган. Аның безне кызыксындырган өзеге түбәндәгечә:

«Көннәрдән бер көнне бу Сөләйман бер сырхавында үзенең зиннәтле сараенда торган вакытында, таяк таянып утырганда, җанын Хак Тәгаләгә тапшырды. Тере кеше кебек гәүдәсе тәхет өстендә утырып калды.

Вәзире Хозыр галәйһис-сәлам җеннәргә хәбәр салды, әйтте:

- Сөләйман падишаһ дөньядан аерылып торырга вәгъдә кылды, үзенең сараеннан бер елга чыкмаска ант итте. Сез электән кайсыгыз ни гамәл кылырга алынгансыз – шул гамәлне кылыгыз, – диде.

Җеннәр вә гыйфритләр, Сөләйман галәйһис-сәлам сараенның бер кечкенә тишегеннән карап, күрделәр: бик начар, кечерәйгән, таякка таянып утыра. Җеннәр җыелышып, киңәшләшеп: «Бу Сөләйман падишаһ тереме йә үлеме?» – дип, агач кортына әмер иттеләр:

– Кечкенә тишектән кереп, таягын аша! – диделәр.

Корт кереп, Сөләйман галәйһиссәламнең таягын кимерде, бер җиреннән өзде. Сөләйман галәйһиссәламнең гәүдәсе ауды, егылды. Монпан соң җеннәр һәм гыйфритләр киттеләр, Хозыр галәйһис-сәламнең әмеренә буйсынмадылар...».

Чүп өчен – кырык тартма...

Швейцариянең кайсы төбәгенә генә барма, бөтен җир ялт иткән. Бу – чүпне тәфсилләп бүлү һәм дөрес урынга түгү нәтиҗәсе. Чүпне сортларга бүлү системасы биредә иң камил дәрәҗәгә җиткерелгән. Илдә яшәүче һәркем – баймы ул, ярлымы – чүпне сортларга аерып ташларга тиеш, алайса штраф түләячәк. Биредә бөтен кешегә чисталыкта яшәү ошый, чөнки менталитетлары шундый. Шешә тапшыру буенча Швейцария дөньяда беренче урында – тараның 90 процентган артыгы пыяла эшкәртү заводларына кире әйләнеп кайта. Файдаланылган пыяланы кабул итү һәм кабат эшкәртү буенча программа 1972 елда гамәлгә кертелгән һәм хәзергә кадәр уңышлы тормышка ашырыла. Әле төрле төстәге шешәләрнең һәркайсын аерым тапшырырга кирәк. Кәгазь һәм катыргы да аерым җыела, илдәге басма продукциянең өчтән бере икенчел чимал җыю пунктларына кире кайта. Илдә сатылган батарейкаларның 60 проценты чүпкә ташланмый, ә кире тапшырыла. PET-шешәләр – аерым, иске электр җиһазлары һәм көнкүреш техникасы – аерым, төзелештәге калдыклар – аерым, лампалар – аерым, консерв банкалары (аларны башта һәркем үзе магнит прессы ярдәмендә калай итеп җәяргә тиеш) – аерым, хайван үләксәләре – аерым (моның өчен түләргә кирәк, тик аларны күмеп кую тыела), үсемлек мае калдыклары – аерым, машина мае калдыклары – аерым (үз автомобилендә майны алыштыру катгый тыела – 50 франк түләп, моны техстанциядә эшләтәләр), ризык калдыклары аерым тапшырыла. Әйе, ялкаулар чүпне сортларга бүлмәсә дә була, әмма аның һәр килограммыннан салым түләргә кирәк, һәр чүп капчыгына салым түләгәнлекне раслый торган марка ябыштырыла.5 килограмм чүп ташлау 2-3 франк тора. Шунлыктан күпчелек бөтен кирәкмәгән нәрсәне икенчел чимал кабул итү пунктларына илтә – бусы бушлай. Маркасыз ташланган чүп хуҗаларын исә махсус полиция тиз арада исәпләп чыгара һәм зур штраф сала. Хәтта файдаланылган һәр чәй төргәгенең этикеткасын – катыргы, чәй түбен – компост, пакетның үзен – кәгазь, беркеткечен – металл, ә җебен марка ябыштырылган чүп капчыгына салырга кирәк. Һәм бу – шаяру түгел, чынбарлык.

(“Tages-Anzeiger”).

Солы боткасы чирдән саклый

Диетологлар көндәлек рационга инде классикага әйләнгән солы боткасын кертергә куша. Янәсе, ул бөтен ризыктан да файдалырак. Ньюкасл университеты галиме Крис Сил, иртән ашалган бер тәлинкә солы боткасы теләсә кайсы кешенең сәламәтлеген яхшырта ала, дип ышандырмакчы була. Доктор әйтүенчә, анда файдалы азык җепселләре, магний, тимер, бакыр, В төркеме витаминнары күп, май һәм шикәр аз. Солы боткасы ашказанын тыгыз гель кебек урап ала һәм туклану хисе тудыра, шул ук вакытта файдалы бактерияләр өчен ризык булып тора, иммун системаны ныгыта, холестерин микъдарын киметә. Тикшеренү көн саен 70 грамм солы боткасы ашаудан кандагы куркыныч холестерин микъдарының 7 процентка кимүен күрсәткән. Профессор Сил әйтүенчә, солыдагы бета-глюкан – онкологик чирләрдән саклый торган сирәк табигый матдәләрдән берсе. Кайбер белгечләр солы боткасында тимернең артык күплегенә хафаланса да, бу арзанлы продукт иң кыйбатлы даруларга көндәш була ала. 14 еллык тикшеренү күрсәткәнчә, солы боткасы йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан да саклый, гомерне озайта. Әмма Британия докторлары әйтүенчә, сәламәтлек өчен никадәр файдалы булуын белсәләр дә, яшьләр солы боткасын яратып ашамый, алар аны артык гади һәм арзанга саный. Азык җитештерүчеләргә дә файдалырак түгел, бәлки табышлырак ризыкны рекламалау һәм сату кызыграк.

(“Die Welt”).

Унҗиде тапкыр үлеп терелгән

Боснияның Рогатица шәһәреннән Любомир Цебич 2003 елның 19 ноябрендә 17 тапкыр үлеп терелгән. Ул көнне 64 яшьлек Цебичны инфарктган соң аңсыз килеш хастаханәгә китерәләр. Операция бүлмәсенә керткәч үк, аның сулышы өзелә. Табибләргә дефибриллятор - йөрәк эшчәнлеген торгызу өчен тән аша көчле электр тогы үткәрә торган җайланма кулланырга туры килә. Йөрәк тибә башлый да, бераздан тагын туктый. Һәм шулай 17 тапкыр кабатлана, табибләр хәлдән тая. Нәтиҗәдә пенсионер 17 тапкыр клиник үлем кичергәннән соң исән кала. Клиник үлем ул – фанилык һәм бакыйлык арасындагы күчеш чоры, уртача 3-4 минут дәвам итә. Бу вакытта баш мие күзәнәкләренең бер өлеше юкка чыга. Любомир исә барлыгы 42 минут үлем хәлендә була, тик тоташ түгел, өзек-өзек кенә. Шунлыктан аның баш миенә зыян килми, алай гына да түгел, ул үзенең җәннәт һәм җәһәннәмне күрүен бик яхшы хәтерли һәм тәфсилләп сурәтли. Хастаханәдән чыккач, Цебич үз эченә бикләнә, аның беркем белән дә аралашасы килми. Көннәрдән бер көнне ул бернәрсә дә алмыйча өеннән чыгып китә һәм югала.

(“The Local”).



Байя Бакари: могҗизамы?

2009 елның 30 июнендә Йәмән башкаласы Санадан Комор утраулары башкаласы Морونига очучы Airbus A310 авиалайнеры, инде утырырга җыенганда, Һинд океанына барып төшә, борттагы 152 кеше (шулардан 66сы Франция гражданы) һәлак була, ә менә 13 яшьлек Байя Бакари могҗиза белән исән кала – аны һәлакәттән соң 9 сәгать үткәч акулалар мыжлап торган диңгездә самолет фюзеляжы кисәгенә тотынган килеш табалар. Парижда яшәүче кыз әнисе Газизә белән утраудагы бабасына кунакка бара торган була, алар Йәмәндә Yemenia компаниясенең 626 нчы рейсына күчеп утыра. Самолет зур тизлектә суга барып төшә, мондый очракта исән калу мөмкинлеге юк, дип санала, шунлыктан коткаручылар кызны күргәч гаҗәпкә кала. Байя берничә сәгать буе җылына алмый интегә, әмма аңында була, табибләр белән теләп аралаша. Аны Франциягә хөкүмәт самолетында тышкы эшләр министры үзе алып кайта. Хастаханәдә өч атна ята, Франция президенты Николя Саркози кызның хәлен белергә килә. Башка пассажирларның, шул исәптән әнисенең дә һәлак булуын Байяга психологлар ике атнадан соң гына әйтә. 2010 елда “Исән калучы” дигән автобиографиясен язып бастыргач, кыз матбугат чаралары белән башка аралашмый диярлек. Быел майда Парижда яңадан суд башлана, анда инде 25 яшьлек Байя Бакари шаһит буларак катнаша. Һәлак булучыларның туганнары әле һаман Yemenia компаниясеннән гаебен тануны һәм 225 мең евро күләмендә компенсация түләүне таләп итә, әмма яңа җитәкчелек әлеге һәлакәттә үзен гаепле санамый һәм акча түләүдән баш тарта. Шулай да Байя Бакари кайчан да булса гаделлек җиңәсенә һәм авиакомпаниягә җәза биреләсенә ышана.

(“Лента.ру”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

8 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Заповедники». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Татарстан без коррупции». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Рыцари вечности». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Бормалы су. З.Хәбибуллин». 6+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Илһам Шакиров турында телеочерк. 6+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.20, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Реки России». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Императрица без империи».
7.30 «Верея. Возвращение к себе».
8.10 Легенды мирового кино.
8.40 «У САМОГО СИНЕГО МОРЯ».
9.50 Цвет времени. Альбрехт Дюрер. «Меланхолия».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Гавриил Барановский. Дом торгового товарищества «Братья Елисеевы».
10.45 Academia. Николай Короновский. «Геологические катастрофы: прошлое, настоящее, прогноз».
11.30 «Владислав Старевич. Повелитель марионеток».
12.15 Цвет времени. Иван Мартос.
12.25 «ЖИЗНЬ С ОТЦОМ».
14.30 Пряничный домик. «Шумбратада».
15.05 «Археология. История с лопатой».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.10 «Забытое ремесло».
17.25 Острова. Олег Стриженов.
18.10 «Португалия. Замок слез».
18.40 Пианисты XX века. Владимир Крайнев.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 «Слава Фёдоров».
21.15 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ».
23.10 «Первые в мире».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00, 23.50 «ПЁС». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Сишәмбе

9 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Рәгыйдь - яшен яшьнәү». Рәгыйдь Халитов турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Реки России». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.45 Ленинградская симфония на берегу Невы. К 80-летию исполнения в блокадном городе.

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Царственный подросток».
7.30 «Путешествие из Дома на набережной».
8.10 Легенды мирового кино.
8.40 «ПЕРВАЯ ПЕРЧАТКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.25 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Джакомо Кваренги. Эрмитажный театр.
10.45 Academia. Николай Короновский. «Геологические катастрофы: прошлое, настоящее, прогноз».
11.30 Абсолютный слух.
12.15 «Забытое ремесло».
12.35 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ».
14.30 Пряничный домик. «Калевала».
15.05 «Археология. История с лопатой».
15.35 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
18.10 «Самара. Дом Сандры».
18.45 Пианисты XX века. Рудольф Керер.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 «Спрятанный свет слова».
21.15 «ДЕРЕВЕНСКАЯ ДЕВУШКА».
22.55 Жизнь замечательных идей. «Новая физика. Теория относительности».
23.45 Ленинградская симфония на берегу Невы. К 80-летию исполнения в блокадном городе.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00, 23.50 «ПЁС». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Чәршәмбе

10 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.30, 20.30 «Юлчы». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Бәргәләнмә күңел кошым». Әнвәр Шакиров турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30 «ВЕРЬ МНЕ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Это лечится». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Сердце стальной бабочки».
7.30 «Дом полярников».
8.10 Легенды мирового кино.
8.35 «СВИНАРКА И ПАСТУХ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Александр фон Гоген. Дом Офицерского собрания.
10.45 Academia. Александр Лисицын. «Тайна океанского дна».
11.30 Абсолютный слух.
12.15, 18.30 «Забытое ремесло».
12.35 «ДЕРЕВЕНСКАЯ ДЕВУШКА».
14.15 «Первые в мире».
14.30 Пряничный домик. «Колыванские камнерезы».
15.05 «Археология. История с лопатой».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
18.45 Пианисты XX века. Сергей Доренский.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 «Солдат из Ивановки».
21.15 «СВАХА».
23.00 Жизнь замечательных идей. «Новая физика. Радиация и радиоактивность».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00, 23.50 «ПЁС». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Пәнҗешәмбе

11 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00, 23.00 «ЛЮБОПЫТНАЯ ВАРВАРА». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Равил Харисов турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». Илсур Сафин концерты. 6+
23.05 «Кәмит Җәвит». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30, 21.00 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «ВАСИЛИСА». 12+
14.35 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Первая Мировая». 12+
16.30 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 0.40 Информационный канал. 16+

21.00 «Время».
21.45 «КУРОРТ ЦВЕТА ХАКИ». 16+
23.40 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+
23.55 «ГРОЗНЫЙ». 16+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Дикое сердце Мари, или Тысячи цветов для мамы».
7.30 «Малайзия. Остров Лангкави».
8.00 Легенды мирового кино.
8.30 «СЕМЕРО СМЕЛЫХ».
10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Николай Васильев. Санкт- Петербургская Соборная мечеть.
10.45 Academia. Игорь Мельников. «Живой лед».
11.30 Абсолютный слух.
12.15 «Забытое ремесло».
12.35 «СВАХА».
14.15 «Первые в мире».
14.30 Пряничный домик. «Сибирский ковёр».
15.05 «Археология. История с лопатой».
15.35, 23.50 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.15 «Диалоги вне времени».
17.55 Цвет времени. Эдуард Мане. «Бар в Фоли-Бержер».
18.05 «Путешествие из Дома на набережной».
18.45 Пианисты XX века. Дмитрий Башкиров.
19.45 «Библейский сюжет».
20.15 «Спокойной ночи, малыши!»
20.35 К 80-летию со дня рождения Юрия Шиллера. Острова.
21.15 «ЧЕТВЕРГ».
23.00 Жизнь замечательных идей. «Новая физика. Реликтовое излучение».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.30 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00, 23.50 «ПЁС». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+

Җомга

12 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КАЙДА СИН?» 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Күчтәнәч».
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «ЗАТЕРЯННЫЕ В ЛЕСАХ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Хәсән Сарьян турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ-2». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «НАУЧИ МЕНЯ ЖИТЬ». 16+
10.30 «ТАТЬЯНИНА НОЧЬ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПРЕДАННЫЙ САДОВНИК». 16+
15.10 «Не факт». 12+
15.40 «Первая Мировая». 12+
16.40 «Кошечки-собачки».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+
21.00 «ВЕРЬ МНЕ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 30-летие музыкального фестиваля «Белые ночи Санкт-Петербурга». 12+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ПАЛЬМА». 6+
23.25 «ЛЁД». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Пешком...»
7.00 «Другие Романовы». «Кавказский пленник».
7.30 «Купола под водой».
8.15 Легенды мирового кино.
8.45 «МАШЕНЬКА».
10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
10.15 Красуйся, град Петров! Зодчий Андрей Штакеншнейдер. Дворец Белосельских-Белозерских.
10.45 Academia. Игорь Мельников. «Живой лед».
11.30 «Юлий Файт. Трамвай в другой город».
12.20 «Забытое ремесло».
12.35 «ЧЕТВЕРГ».
14.15 «Первые в мире».
14.30 Пряничный домик. «Псковское ткачество».
15.05 «Крым. Мыс Плака».
15.35 «СЛЕДСТВИЕ ВЕДУТ ЗНАТОКИ».
17.30 Цвет времени. Жан Огюст Доминик Энгр.
17.45 «Билет в Большой».
18.25 Пианисты XX века. Николай Петров.
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Чистая правда барона Мюнхгаузена».
21.05 «МОЛОДОЙ КАРУЗО».
22.25 Линия жизни. Нина Усатова.
23.40 «НЕЗАКОНЧЕННЫЙ УЖИН».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «ПЁС». 16+
16.50 «За гранью». 16+
17.55 «ДНК». 16+
19.50 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.30 «Bel Suono». 10 лет». 12+

Шимбә

13 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 Спектакль «Яшь йөрәкләр». 12+
16.00 «Гомер- татлы мизгел». Раяз Фасихов концерты. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.20 «ДЕД, ПРИВЕТ!» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Әлфия Авзалова турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Бир кулыңны». Зәлфирә һәм Алмаз Мирзаяновлар концерты. 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Кайда сез, яшьлек елларым». Зөһрә Шәрифуллина концерты. 6+
22.00 Спектакль «Гаугалы гаилә». 12+
23.45 «Яратам». Гөлнара Габидуллина концерты. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30, 14.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
8.30 «Реки России». 12+
8.55 «ПОГОНЯ ЗА ТРЕМЯ ЗАЙЦАМИ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДЖОЙ: АМЕРИКАНКА В РУССКОМ БАЛЕТЕ». 12+
15.00 «Инвиво». 12+
15.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «1+1. НАРУШАЯ ПРАВИЛА». 16+
23.00 «КОГДА ЗОВЕТ СЕРДЦЕ 5». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «Поехали!» 12+
11.15, 12.15 «Видели видео?»
13.55 «ХРОНИКА ПИКИРУЮЩЕГО БОМБАРДИРОВЩИКА». 12+
15.25 «Алексей Маресьев. Рожденный летать». 12+
16.25 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «БИТВА ЗА БЕРЛИН». 12+
18.20 «На самом деле». 16+
19.25 «Пусть говорят». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.15 «БЕЛЫЕ НОЧИ ПОЧТАЛЬОНА АЛЕКСЕЯ ТРЯПИЦЫНА». 16+

«РОССИЯ»

5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «КОРОЛЕВА КРАСОТЫ». 12+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «НАКАЗАНИЕ БЕЗ ПРЕСТУПЛЕНИЯ». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.00 «ЦИРК».
9.30 «Обыкновенный концерт».
10.00 «Передвижники. Валентин Серов».
10.25 «НЕПОВТОРИМАЯ ВЕСНА».
11.55 Острова. Александр Столпер.
12.35 Диалоги о животных.
13.20 «Дом ученых». Евгений Рогаев.
13.50 Легендарные спектакли Мариинского. Габриэла Комлева, Татьяна Терехова, Реджепмырат Абдыев, Геннадий Селюцкий в балете Л. Минкуса «Баядерка».
15.55 «Геннадий Селюцкий. Рыцарь танца».
16.55 «Энциклопедия загадок».
17.25 «Мировая литература в зеркале Голливуда».
18.15 «МАЯК НА КРАЮ СВЕТА».
20.25 К 100-летию российского джаза. Линия жизни. Игорь Бриль.
21.20 «АЛЕШКИНА ЛЮБОВЬ».
22.45 Спектакль «Солисты Москвы».

«НТВ»

4.35 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.25 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.30 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
22.45 «Маска». 12+

Якшәмбе

14 август

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.05 «Кәмит Җәвит». 16+
6.00 «Пар алма». Илназ Бах һәм Гүзәл Идрисова концерты. 6+
8.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Туган авылым». 6+
8.45 «Эти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.10 Концерт. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «КӨТЕГЕЗ, БЕЗ КИЛӘБЕЗ». 12+
14.35 «Яратам» Гөлнара Габидуллина. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «1612». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Җырым булсын бүләгем». Ринат Мөслимов җырларыннан концерт. 6+
9.15, 22.50 «Йөрәктән-йөрәккә». 6+
10.15 «Туган авылым». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 Марат Мухин хитлары. 6+
15.15 Спектакль «Ай тотылган төндә». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 6+

«ЭФИР»

5.00 «Опыты дилетанта». 12+
5.30 «Реки России». 12+
6.30 «Не факт». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Сказочный патруль».
8.00 «Инвиво». 12+
8.30 «ВЕЧНЫЙ ОТПУСК». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «1+1. НАРУШАЯ ПРАВИЛА». 16+
15.00 «Путеводитель по вселенной». 12+
15.30 «Карамзин. Проверка временем». 12+
15.55 «ПОГОНЯ ЗА ТРЕМЯ ЗАЙЦАМИ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДЖОЙ: АМЕРИКАНКА В РУССКОМ БАЛЕТЕ». 12+
22.35 «ПУШКИН: ПОСЛЕДНЯЯ ДУЭЛЬ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.05, 6.10 «ОТЧАЯННЫЕ». 16+
6.00, 10.00, 12.00, 18.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Игорь Костолевский. Пленительное счастье». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.00 «Скелеты клана Байденов». 16+
14.55, 18.20 «БРЕЖНЕВ». 16+
19.15 «Проект Украина. История с географией». 16+
20.05 «Русский Херсон. «Мы ждали этого 30 лет». 16+
21.00 «Время».
22.35 «ПОХИЩЕНИЕ БОМБЫ». 12+

«РОССИЯ»

5.30 «СВАДЬБЫ НЕ БУДЕТ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.30 «Доктор Мясников». 12+
12.35 «КОРОЛЕВА КРАСОТЫ». 12+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 Мультфильмы.
7.50 «НЕЗАКОНЧЕННЫЙ УЖИН».
10.00 «Обыкновенный концерт».
10.30 «АЛЕШКИНА ЛЮБОВЬ».
11.55 Диалоги о животных.
12.35 Государственный академический русский народный хор имени М.Е. Пятницкого. Юбилейный концерт.
14.10 «Купола под водой».
14.55 «Цирк». Я хотела быть счастливой в СССР!»
15.35 «ЦИРК».
17.05 «Бионические полеты».
17.50 «Пешком...»
18.20 К 100-летию со дня рождения Бориса Сичкина. «Буба».
19.15 «Романтика романса».
20.10 «НЕПОВТОРИМАЯ ВЕСНА».
21.40 Большая опера.
23.20 «ЖИЗНЬ С ОТЦОМ».

«НТВ»

4.55 «ДЕЛЬТА». 16+
8.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.50 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.35 «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ». 16+
23.20 «МОЯ РЕВОЛЮЦИЯ». 16+

Уллары ана җанын суырган

Бу ел башында Чистай каласында бер-бер артлы өч хатын-кыз фаҗигале төстә вафат булды. Алар барысы да үз уллары кулыннан һәлак булды.

Раштуа бәйрәменә каршы 6 гыйнварда шул шәһәрдә яшәүче О. Мирошкина гаиләсе табигать кочагына чыга. Кышкы салкында ерак китмиләр. «Татнефть» стадионы читендәге агачлыкта учак ягалар. Бер мәлне йөгерек җил кәгазь, чүп-чар тутырылган пакетны очыртып алып китә, хуҗабикә аның артыннан юнәлә һәм шул тирәдәге икенче бер зәңгәр пакетка игътибар итә. Анысы җил-буранга бирешмичә җилферди, эчендә авыр әйбер булуы аңлашыла. Ә инде анда күз төшергәч, шатлыклы бәйрәмнең яме китә, О.Мирошкина канга баткан кеше кулларыы салынган пакетка юлыгуы турында полициягә җиткерә.

Чынлыкта кеше үтерү турындагы хәбәр була бу. Оператив хезмәткәрләр якын-тирәне әйләнеп чыга, үткән-сүткәннәр белән әңгәмә коралар, ләкин кирәкле мәгълүмат бирүче булмый, гәүдәнең калган өлешләре дә табылмый. Әмма бу эзләү-тикшерү эшләренең комга утыруын белдерми. Чөнки бер сәгать дигәндә бармак, уч төбе эзләре буенча чабып өзелгән кулларның кемнеке икәне, ягъни мәрхүмәнең ун көннән 62 яшен тутырырга тиешле Лидия Любимова булуы ачыклана. Йомшарак итеп әйткәндә, бик үк тәртиплеләрдән булмаган карчыкның кул эзләре электрон картотекага эләккән була.

Шул рәвешле, төп шикләнелүче дә калкып чыга. Эш шунда: Л. Любимова хокук саклау органнарында берничә тапкыр хөкемгә тартылган зат буларак мәгълүм улы Сергей белән тора. Әле 2021 ел азагында гына әнисен кыйнап аның сәламәтлегенә уртача дәрәҗәдәге зыян китергән 38 яшьлек ошбу сәрхушка карата җинаять эше кузгатылган була. Ярты ел элек полиция хезмәткәре белән бәйләнешкән өчен суд аңа 10 мең сумлык штраф сала, аны түләмәгәч, 100 сәгатьлек төзәтү эшләре билгеләнә, әлеге җәза да үтәлми. Моның ише юньсезлекләрне күпләп санарга мөмкин. Аларга Лидия карчыкның эчәргә хирыслыгын да өстәгәч, фаҗиганең гаиләдә килеп чыгуына икеләнергә туры калмый.

Любимовлар фатиры бикле була, ләкин бу Сергей качып йөри дигән сүз түгел. Киресенчә, шешәдәшләре белән эчеп йөри ул. Соңрак Е.Игнатьев дигән дусты аның подъездда сыра эчкәндә үзен тиздән төрмәгә утыртачаклары турында сөйләнүен искә ала. Чыннан да, исерекләрне икәүләп кибеткә таба тәпиләгәндә тотып алалар. Шулай итеп С.Любимов бик озакка төрмә сәндерәсенә эләгә.

Оперативникларның шикләнүләре беренче әңгәмәдә үк аклана, чөнки тел яшереп тормый явыз бәндә. Алар Любимов торагына кергәнче үк анда нинди мәшхәргә тап булачакларын беләләр. Кыскасы, үзенчәлекле ис чыккан фатир идәнендә кулсыз гына түгел, аякларсыз һәм башсыз гәүдә ята. Соңгысы икенче көнне шул яклардагы «Экойл» ягулык станциясе янында табыла. С.Любимовның әйтүенчә, аяклар да шул тирәгә ташлана, ләкин аларның уңын участок инспекторы Р.Дәүләтшин бары тик 12 гыйнварда хәвеф булган йорт янында очраклы рәвештә күреп ала, сул аяк бөтенләй юкка чыга, күрәсең этләр алып китә.

Суд-медицина эксперты, ошбу табылдыкларны тикшергәч, гәүдәдә 38 җәрәхәт саный, үлемнең күкрәк сөяге, бик күп кабыргалар сыну, үпкәгә зыян ясалу аркасында килүен, баш-аяк, куллар мәрхүмә үлгәннән соң өзелгән, дип белдерә. Химик экспертиза Л.Любимованың исерек булуын да күрсәтә. Аңлы рәвештә кеше үтерү очрагы буенча кузгатылган җинаять эшендә зарар күрүче итеп мәрхүмәнең 40 яшендәге кызы Н.Соловьева (исеме үзгәртелгән) билгеләнә. Нина ире, балалары белән шул ук урамда яши, сәрхуш әнисе һәм энесе белән аралашмавын, очраклы рәвештә очрашканда бер-ике сүз алмашудан узмавын белдерә, бары тик бер ай элек бертуганы кыйнагач сырхауханәгә салынган карчыкның хәлен белергә баруын һәм шуннан бирле аны күргәне булмавын әйтә. Иш-ишен таба, эчкечеләр исә үзләре кебекләр белән аралаша.

4 гыйнварда аналы-уллы Любимовлар Лидиянең шул урамда яшәүче дус хатыны янына бара. Кунаклар кыстырып килгән бер шешә көмешкәне бушаткач, хуҗабикә акча биреп, Сергейдан тагын дүрт ярты аракы алып кайттыра. Хак булса, өлкән яшьтәге ике ханым белән бер ир-ат өч-дүрт сәгать эчендә ике литр ярым хәмер эчә. Любимовлар өйләренә кайтып китә.

Калганын, башлыча, Сергей сөйләгәннәр буенча бәян итәргә туры килә. Аның әйтүенә караганда, кайтып кергәч тә әнисе начар сүзләр әйтеп кимсетә башлый, саплы таба белән кундырып та ала. Менә шуннан соң котырынып кыйный, типкәли башлый ул аны һәм авыр хәлдәге карчыкны коридор идәнендә яткан килеш калдырып йокларга түнә. Иртәнге сәгать 9да уянып аның җансыз икәнен күргәч, эчә-эчә ахмакланган бәндә балта алып килеп җинаять эзләрен яшерергә керешә, иң әүвәл, кулларны, аннан соң башны, аякларны чыгарып ташлый, ә менә капчыкка салынган гәүдәне күтәрә алмау сәбәпле бүлмәсендә калдыра. Ул гына да түгел, көпә-көндез андый зур әйберне урам буйлап күтәреп йөрергә дә курка.

Ул көнне, гадәттәгечә, эчеп уздыра. Шул исәптән, алдагы кичтә кунак булган ханым өендә дә баш төзәтеп чыга, мәетле фатирында кунганнан соң 6 гыйнварда, инде стадион тирәсендәге тикшерү-эзләү эшләре барганда да әнисенең ахирәте һәм тагын бер пенсионер белән шунда сыйланып утыра. Мәҗлес барышында Лидия турында сүз чыкмый калмый. Әниең кайда дигән сорауга аңлаешлы җавап булмагач, аннан башка килмәскә кушып куып чыгара аны хуҗабикә. Бу чакта инде Сергейны полиция эзли. Аз-маз буталса да вакыйганы эзлекле сурәтли ул, әнисен үтерүен дә таный. Бары тик андый ниятем булмады дип белдерә. Тикшерү комитетының Чистай бүлегенең өлкән тикшерүчесе Р.Гыйззәтуллин аңа аңлы рәвештә үтерүдә гаепләү белдерә. Июль аенда җинаять эше шәһәр суды каравына тапшырыла. Психиатрлар акылга камил дип тапкан ир-атны 15 елга кадәр иректән мәхрүм итү көтелә.

* * *

Моның ише кыргыйлыклар эшләгән кешеләрнең акылга тулылыгы икеле, әлбәттә. Белгечләр дә, гадәттә, аларның рухи кимчелекләре кылган гамәлләрен аңламаслык дәрәҗәдә үк түгел дип белдерә. Шундый ук явызлык эшләгән 1970 елгы Александр Крашенинников үз акылында булган дип табыла. Ә күргән-белгәннәр һәм туганнар башка төрле фикердә, бертуган энесе Вячеслав, мәсәлән, аны эчеп алгач акылын җуючы, аныңча әйтсәк,«түбәсе кыйшая» торган зат дип атый. 1950 елгы мәрхүмә карчыкны барысы да беркайчан да эчмәгән, тәртипле һәм зыянсыз иде дип бәяли.

28 февраль иртәсендә Александр Чистай полициясенә шалтыратып әнисенең үле икәнен хәбәр итә, янәшә фатирда яшәүче өлкән яшьтәге хатын-кызга мәчесен тапшыра, үзен утыртачакларын әйтә, ни өчен икәнен дә җиткерә. Суд-медицина эксперты мәрхүмәнең тәнендә биниһая күп җәрәхәтләрнең төгәл санын да әйтә алмый. Аның яңак, күкрәк сөякләре, 13 җирдән кабыргалары сыну, баш миенә, күкрәк куышлыгына кан саву, үпкәгә, умыртка баганасына зыян килү һәм бик кыска арада җан бирүен күрсәтә.

А.Крашенинников әнисен кыйнап, типкәләп үтерүен алдан ук таный, әмма үтерергә теләмәдем дип бара. Өлкән тикшерүче Р.Гыйззәтуллин аңа аңлы рәвештә сәламәтлегенә зыян китереп саксызлык белән үтерү дигән рәсми гаепләү белдерә. Александр гаебен йомшарту йөзеннән әнисенең рухи тайпылышларына басым ясый, шул ук вакытта аның зурдан кубып кабынып китәргә сәбәп булырдай гамәлләрен атый алмый. 27 февральдә иртәнге якта, тиктомалдан әбинең башына таба белән ора ул. Ләкин ул чакта, күрәсең, аек булганга, эш шуннан ары узмый. Ә менә төштән соң күрше карчыгыннан әҗәткә алынган акчага аракылы булгач, бер яртыны кичкә хәтле акрынлап чөмереп бетергәч йөгәннән ычкына 51 яшьлек абзый. Ошбу явызлыгы сәбәбен телевизор каршындагы әнисенең нәрсәдер сөйләнеп мыгырдап утыруы белән аңлата. Кыскасы, үлем хәлендәге карчыкны идәндә калдырып йокларга ята, иртәнге 7 дә торгач күптән суынган гәүдәне диванга күтәреп сала, өстенә җәймә каплый.

* * *

10 мартта Чистайда Артем Комиссаров 1956 елгы әнисе Ираиданы юк итте. 41 яшьлек ошбу ир-ат та алдарак телгә алынган ике вәхшидән аерылмый диярлек. Гомумән, ошбу очраклар бер-берсенә бик охшаш. Иң әүвәл бичара карчыкларның тормышта үз урыннарын таба алмаган эшсез, эчкече, гаиләсез уллары белән икәү яшәүләре, чынлыкта, аларны асраулары күзгә ташлана.

А.Комиссаров эчкече генә түгел, наркотиклар кулланучы буларак та исәптә тора әле. Гаиләсе белән 20 ел элек үк аерылышкан, хәзер Мәскәүдә яшәп укучы кызын тәрбияләүдә катнашмаган, шулай да аерылышкан хатыны Елена гел аралашып торган Ираида ханым белән. Сеңлесенең кызы Юлия дә даими хәбәрләшеп, килеп хәлен белешеп йөри. Алар икесе дә Артемны үтә тискәре бәяли. Юлия һәрчак исерек малаеннан тәмам туйган анасының аны башка фатирга күчереп каравын да искә ала. Ләкин сәрхуш мөстәкыйль яши алмыйча кире кайта, әнисе ашата, эчертә киендерә бит. Юлия Ираида янында ике көн элек, ягъни 8 мартта була, ә 11 мартта аңа Елена шалтыратып карчыкның телефоны җавап бирмәвен хәбәр итә. Ул гына да түгел, ошбу ханым шөбһәгә төшеп фатирына да бара, тәрәзә аша салмыш Артем белән сөйләшә, анысы әнисенең кайда икәнен белмим дип, аны куып җибәрә.

Бу хәлләр турында ишетү белән Елена да шунда ашыга. Теге сәрхуш әнисен чәнчеп үтерүе турында әйтеп тетрәндерә аны, кухняга кергәч кан эчендә яткан карчык күренә, коты алынган хатын-кыз урамга атылып тиз генә ирен чакырып китерә. Дмитрий полициягә хәбәр сала, соңрак явыз бәндәнең әнисенә 26 тапкыр пычак белән кадавы мәгълүм була.

А.Комиссаровның да гаебен кире кагып торырлык чамасы булмый. Тикшерү материалларыннан күренгәнчә, алдагы көнне ломбардка телефонын тапшырып 1000 тәңкә «акча эшли» ул һәм ошбу сәмәнгә сыра алып кайтып эчәргә керешә, әлбәттә, әни кешенең, ошбу юньсезлеккә ачуы килә һәм өйдә тавыш чыга. Әлеге низагны күршеләр дә ишетә, хуҗабикә эчә, дәваланмый, көн саен шул хәл, дип янәшә фатирда яшәүче тагын бер Ираидага зарланып алырга өлгерә.

Башлыча, күкрәк, муен һәм башка җан җирләргә кадаганга күрә карчык бик тиз үлә. Котырынган улы исә канга манчылган киемнәрен салып ташлап бүтәннәрен кия, калган сырасын эчеп бетергәч аракы алып кайта, әнисе мәете янында исергәнче эчеп йокларга ята, икенче көнне туганнан туганы Юлия килгәнче эчүен дәвам иттерә.

Өченче ананы үтерү очрагы буенча кузгатылган җинаять эшен судка тикшерүче И.Абдулгазин тапшыра. Хөкем чыгарылмаган әле, әмма аның кырыс булачагына шик юк.

Наил ВАХИТОВ.

ЦИРКТА яңа программа

Күз җитәргә бер генә ай калып барса да, җәйнең әле кызган чагы. Шәһәр халкы эсседән бакчаларга, су буйларына кача.

Хәер, Казанда да нәкъ шәһәр үзәгендә кызу кояштан яшеренеп тору өчен бер мөмкинлек ачылды. Моның өчен Казан циркына «Боз сулышы» дип исемләнгән яңа программага гына килергә кирәк. Цирк аренасының бозга әйләнүен тагын кайчан һәм кайда күрәчәксез әле? Артистлар да, программа да үзебезнеке түгел, Мәскәүдән Цветной бульвардагы Никулин циркыныкы. Безгә килгәнче, утызлап артист өчен өч йөзләп костюм тегеп, утызлап илне йөреп чыкканнар. Бөтенесе тимераякта шуса да, цирк сәнгатенең бөтен жанрларын күрергә мөмкин булачак. Хайваннардан маймыл һәм маэмайларны гына алып килгәннәр. Алар әлегә тимераякта шумый. Гап-гади тимераякны гына азсынып, бериш артистлар алтмыш сантиметр озынлыктагысында номер куйган. Ике сәгать дәвам иткән программаның билет бәясе 700 сумнан алып 1800 сумга кадәр. Бәяләр «тешләсә» дә, Никулин циркының директоры, сәнгать җитәкчесе, Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре Наталья Абрамова журналистларга программаның бик тыгыз төзелгәнен, аренадагы вакыйгаларның җитез алмашынганын әйтеп кызыктырды.

Тамашачы күргәнче каләм әһелләре Мәскәү артистлары башкаруында берничә номерны карап тә өлгерде. Костюмнары искиткеч матур. Тимераякта шуулары гына җитмәгән, купол астында баш әйләнерлек биеклектә әллә нинди гомер күрмәгән трюклар ясыйлар да, аска төшеп, берни булмагандай, кабат аккошлар йөзгән кебек, шуып китәләр. Цирк һәм фигуралы шууны бергә берләштерүне кайсы акыллы башы уйлап тапкандыр – билгесез, әмма замана балаларын шаккатырам дисәң, әнә шулай сәнгать һәм спорт төрләрен бер-берсенә кушарга һәм тагын әллә нәрсәләр уйлап табарга туры килә. Безнең Казан циркы кушыпалып кайчан үз программаларын иҗат итә башлаячагы мәгълүм булмаса да, яңа гына директор итеп билгеләнгән Эльмира Булатова циркны Казанның брендына әйләндерәчәкләрен вәгъдә итеп эчкә җылы кerткән иде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 5.08.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2764

16+